Безнең
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
МИРАС
03
март 2022
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

МӨХӘММӘДХАФИЗ БАЙ ХӘБИБУЛЛИН ӨЧЕНЧЕ ХАТЫНЫ СӘЛИМӘ ҺӘМ КЫЗЛАРЫ БЕЛӘН

Татар карбызны ник ярата?
(Алтын Урдада бакчачылык)
4 бит

Тимершаһ бай – татарның ит «короле», бозыклык белән көрәш һәм милли оркестр
24 бит

سوداسینك تاریخی
محمدجان بنیامین اوغلی علییف ورثه‌لرینك فیرماسی.
عزیزجان علییف.
33

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең Мирас

12 +

03
(339)
март 2022

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рузәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Галимҗан Ибраһимов

ТАРИХИ МИРАС

4 Татар карбызны ник ярата? *Л.Гобәйдуллин*
7 Киев Русемы, әллә татар-төрки Киев каһанлыгымы? *А.Чанышев*
10 Әхмәд бай. *Р.Фәхреддин*
16 Данис Шакиров: «Эшмәкәрлек – татар авылының нигезе һәм киләчәге»
18 «Бозау тиресенә язылган кәгазьләр булган». *М.Госманов*
24 Татар бүреге
26 Рөстәм Шәфигуллин: «Бүрек татарны затлы итеп күрсәтергә тиеш!»
30 Тимершаһ бай – татарның ит «короле», бозыклык белән көрәш һәм милли оркестр. *Р.Шәрафиева, Л.Гобәйдуллин*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

33 Мөхәммәтҗан Галиев һәм татарның бердәнбер читек фирмасы. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
36 Тау ягы. *В.Данилов*

ӘДӘБИ МИРАС

41 Мәүла Колый: өйрәнелү тарихы һәм иҗаты турында кайбер фикерләр. *Х.Миңнегулов*
49 Мәүла Колый. *М.Садыйков*
50 «Хатын әйтте: мин кылырмын чарасын». *Р.Мәрданов*
53 Берләшкәннәр сыйфаты. *М.Колый*

ТАТАР ГАМЕ

56 Илһам Кашапов: «Авыл туризмы тарихыбызны саклый»
62 Питрәч археологиясе. *А.Борһанов*
66 Питрәч районының нумизматика ядкярләре. *А.Бугарчев, О.Степанов*
68 «Нәчә кусаң, үткән гомер янә булмас»
70 Татар халкының легендар улы. *Р.Сәгъди*
79 «Безнең мирас» котлый!

ДИНИ МИРАС

80 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
86 Ислам. Дини сүзлек
87 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*
88 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

90 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
92 Игелекле эшкуар Эдуард хаҗи Ганиев ядкяре
98 Айдар иле яки Татарның Жан Габены. *Л.Лерон*
106 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

108 «Фазыл чишмәсе» җыры

ТАБИГЫЙ ЯДКЯРЛӘР

110 Артыш

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Март*

Заказ №О-0537. Тираж – 3370 данә. Формат 70х100 1/16
Басарга кул куелды: 25.02.2022. Чыгу көне: 03.03.2022.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Мөхәммәдхафиз бай Хәбибуллин өченче хатыны Сәлимә һәм кызлары белән

Миллият бинасының нигез ташларыннан иң ныклысы тел икәнлеге дә — ике сүз булырга мөмкин түгел хакыйкатьләрдән.

Галимҗан Ибраһимов

Галимҗан Ибраһимов замандашы Шәһит Әхмәдиев белән. 1920 нче еллар башы. Фотокүчермә

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ
(12.03.1887-21.01.1938)

Мәктәп белем бирү белән генә калырга тиеш түгел; баланың зиһенен ачу, аклын тугъры (фәнни) уйлау юлына төшерү дә аның төп бурычларыннан.

***

Бер халыкның яшәргә теләве белән икенчеләренең аны җотарга уйлавыннан туган көрәшләрнең иң төплесе – мәктәптән, мәктәптә (исә) ана теле укытып-укытмаудан башлана.

***

Бер телдә чыккан китапларны – әдәбиятны зурлар да укый... Ләкин сабыйлыкта салынган тел җәүһәрләре белән зурайгач уку арасында йир белән күк арасы кадәрле аерма бар.

***

Сабыйның рухы, ни бирсәң, шуны алучан; ни салсаң, шуны үзенең гомерлек хәзинәсе итеп урынлаштыручан. Бирелгән нәрсәләр милли тәрбиягә нигез булсын өчен, аңа, иң элек, үз анасының теле билгеле бер ысул белән йөрәгенә ярып салынырга тиеш: бала иң элек үз халкының хәрефләрен күрсен; кечкенә куллары иң элек үз хәрефләре белән үз ана теленең сүзләрен язсын! Һәрнәрсәне җотып алырга әзер торган сабый йөрәгендә болар, каты мәгъдәнгә (металл) үткен корыч белән казып язылган кебек, мәңге бетмәслек тирән эз салачаклар һәм шул беренче нигез булачак.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Татар карбызны ник ярата?

(Алтын Урдада бакчачылык)

Ленар Гобәйдуллин

Ханны тәхеткә утырту. Фарсы кульязмасыннан миниатюра. 1330 нчы еллар тирәсе. Арткы пландагы бакчага игътибар итегез.

Күпләр Алтын Урдада яшәгән бабайларыбызны күчмәннәр, атлы җайдак һәм яугирләр булган дип кенә күзаллый. Әмма алар бик оста бакчачылар да булган икән. Бу заманда бакчачылык шәһәр мәдәниятенең аерылгысыз өлешен тәшкил иткән. Сәйф Сараиның 1394 елда язылган «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәренә генә игътибар итик:

«Сөһәйл әйтте: «Нигә гөлләр җыясың?
Үзең – гөл, кайсы гөл тиңдәш сиңа соң!»

Әлбәттә, биредә сүз хан сарайлары янындагы гүзәл гөлбакча хакында бара. Борынгы татар әдипләре гыйшык-мәхәббәт сюжетларын матур бакчаларда корган. Ә менә Алтын Урда шагыйре Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ендә сүз авыл бакчасы турында бара:

«Имеш, шаһзадәгә хезмәтче углан
Җимеш чәлгән, кереп авыл багыннан».

Борынгы бабаларыбыз йогынтысында рус телендә «бахча», «бахчи», «бакша», ягъни бакча сүзе барлыкка килгән һәм ул «сад»ның синонимы буларак хәзерге көндә дә кулланыла. Мәсәлән: «бахчевые культуры»... Ә сад сүзе руска борынгы исланд теленнән (sót – «сажа», садится) кергән икән. «Огород» сүзе исә тавык урманга кереп качмасын өчен территорияне киртәләп куюны гына аңлаткан. Гомумән, Борынгы Русь дәүләтендә бакчачылык булдымы икән? Әйтик, О.Б.Сокольская «История садово-паркового искусства» исемле бик яхшы китабында Русьта мәҗүси йолаларны башкара торган изге урыннар булуы турында гына әйтә. А.Э.Регель исә, русларга бакчачылыкны грек-византия монахлары алып килгән, ди. Бу очракта бакчаларны нигездә монастырь тирәләрендә генә булган дип уйларга мөмкин. Ә менә «Огурец» (борынгы грекчадан – agourus) сүзе рус язма чыганакларында XVI нчы гасырдан гына очрый. Рус галимнәре кәбестәнең дә Руська читтән кергәнлеге турында яза. Әмма мәшһүр галим Рифкать Әхмәтҗанов борынгы бабайларыбыз «кәбестә»не (диалектларда – капыста, кәпестә, капста) латин яки итальяннардан турыдан-туры алган дип әйтә.

Татар теленең 14 нче йөздәге иң затлы ядкяре «Codex Cumanicus» – «Коман мәҗмугасы»нда апельсин (әфлисун), груша, алма, персик (шәфталу), гранат (анар, нардан), абрикос (өрек), слива (караҗимеш), инжир, виноград, чия, хөрмә, имбир, лимон, кавын, кыяр, шалкан, чөгендер, кәбестә, кабак, суган, сарымсак, шпинат, петрушка, салат, укроп кебек бакчачылык атамалары китерелә. Димәк, алар барысы да безнең кыпчак бабаларыбызга таныш булган.

«Өй артындагы бакчадан / Өзеп алдым бер йөзем, шул...» – дип җырлана татар халык җырында. Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрек» сүзлегендә виноградка бәйле «тарка» – әче йөзем, «бәнзи» – җыелмыйча тәлгәштә калып кипкән йөзем, «симән» – виноград согы, «җәхшак» – киптерелгән йөзем терминнары бирелә. Шулай ук борынгылар йөземнән ясала торган ракия, бренди кебек алкогольле эчемлекләр белән яхшы таныш булган. Алтын Урда буенча сәяхәт итүче Гильом де Рубрук Төньяк-көнчыгыш Кавказда виноград бакчалары булуы турында әйтә. Кавказдан тыш, Кырым, Тамань, Хорезм, Болгар төбәкләре дә виноградчылык үзәге булган. Йөзем дала шартларында да бик яхшы уңыш биргән. Археологлар кыпчакларда һәм Актүбә буйларында махсус сугару участоклары да булганын ачыклады. Хан ярлыкларында исә чиркәүләрнең виноград бакчалары буенда урнашуы турында әйтелә. Гадәттә, йөземне киптергәннәр яки шәраб ясаганнар.

Алтын Урдада ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгәч, хәмер эчүгә чик куела. Сәяхәтче Марко Поло татарларның шәраб эчмәве турында яза.

Урта Идел буена виноград үстерү эше, мөгаен, Кавказ һәм Урта Азиядән килгәндер. Румыния һәм Россиядә виноградның тарихи «Болгар», «Тартара», «Татарский» һәм «Татарочка» сортлары үстерелә. Ә хәзерге Татарстан шартларында аның унга якын сорты җимеш бирә икән. Татар егетләре тарафыннан яңа сортлар булдырыла, аларны сынау буенча тәҗрибәләр үткәрелә, виноградтан ясалган «Эмиз» дигән хәләл эчемлек базарга чыгарыла.

Гарәп сәяхәтчесе әл-Гомәри: «Аларда (Алтын Урдада) виноград, гранат, айва, алма, груша, абрикос, персик һәм чикләвек үсә. Кавынны аеруча нык яраталар һәм аның тагы да сарырак төрен ашыйлар. Ул аларда ел дәвамында саклана һәм кирәк вакытта табында була. Бик тә баллы һәм тәмле, моннан тыш, бик арзан да. Кайберәүләр аннан сок һәм хәлвә ясый. Шәһәрдә гәрәнкә (эре шалкан), шалкан, кәбестә һәм башка бик күп яшелчә үстерелә», – дип язып калдырган. Алтын Урда халкы арахис (җир чикләвеге), фундук (бакча чикләвеге), урман чикләвеге, фисташка (пестә), миндаль кебек чикләвекләрне үзләре яратып ашап кына калмаган, экспортка да чыгарган.

Ибне Баттута Хорезм шәһәрендә булып: «Мондый карбыз дөньяның ни шәркында, ни гарбендә юк. Аның кабыгы яшел, эче кып-кызыл. Моннан тыш, бик тә баллы һәм каты эчле. Аны кояшта киптереп, кәрҗиннәргә салып, җир читенә – Һиндстан һәм Кытайга чаклы алып баралар. Киптерелгән җиләк-җимеш арасында шуннан да яхшысы юк», – дип, үзенең хис-кичерешләрен җиткерә.

Шунысы кызык: Россиядә карбыз үстерә торган иң зур компания – «Агросоюз Романовский»ның рәсми сайтында: «На территории России арбузы были завезены в 12-14 столетии татарами», – дип язылган. Карбызны Европа илләре һәм Россиягә Алтын Урда татарлары алып килүе бернинди дә шик уятмый. Хәзерге вакытта да борынгы татар шәһәрләре – Әстерхан белән Оренбург – Россиянең иң эре «карбыз үзәкләре». Карбыз үстерү Әстерхан татарларының гомер бакый яраткан шөгыле булды. Бу төбәктәге археологик казу эшләре вакытында да Алтын Урда чорына нисбәтле кабак, кавын һәм карбыз орлыклары күпләп табылган. Ә менә Урта Идел буе татарлары карбызны соңгы елларда гына яратып үстерә башлады.

Карбыз татарлар арасында ни өчен шулай популяр булган соң? Әлбәттә, урта гасырдагы татар яугире карбызны үзе белән йөртмәгән. Әмма, җае туры килү белән, кылыч белән урталай ярып, согын эчеп, сусавын баскан һәм аның составындагы тиз үзләштерелә торган углевод белән тәненә көч-сихәт алган.

Алмагач. Урта Идел буен бу төр агачтан башка, гомумән, күз алдына китереп булмый. Тау ягы һәм Кама аръягы татарлары аны аеруча яратып үстерә. Карагыз, алмагач турында телебездә күпме мәкаль һәм әйтем бар: «Алма агачыннан ерак төшми»; «Алмагачта – әкәлә, имән агачында алма үсми»; «Алманың яхшысын корт ашар», «Бер черек алма бөтен йөкне черетә». Бу чагыштыруларның берсе дә очраклы гына барлыкка килмәгән, чөнки алмагач татар җирендә бик борынгыдан үсә. Археологик казу эшләре вакытында да борынгы болгар җирләрендә алма, груша, чия һәм сливаларның орлыклары күпләп табылган. Болгар шәһәрләре урынында кыргый алмагачларны әле дә очратырга мөмкин икән.

Ризаэддин Фәхреддин 1899 елда басылып чыккан «Сәлимә, яки Гыйффәт» исемле әсәрендә казан татарлары турында: «Алма, әфлисун, лимон, кавын, карбыз кебек тиз бозылучан җиләк-җимеш белән алыш-биреш кылырга болардан башка беркемнең дә кыюлыгы җитми», – дип язып калдырган. Бүген исә базарда үзбәк, азәрбайҗан һәм таҗикларның гына җиләк-җимеш сатуын күрәбез. Ә кайчандыр бу сәүдә тулысы белән татарлар кулында булып, аларның төп кәсеп чыганагына әйләнгән. Татар егетләре җиләк-җимеш сатар өчен Себернең ерак шәһәрләренә – Красноярск һәм Иркутскиларга кадәр барып чыккан. ■

безнең мирас №3 март 2022

Киев Русемы, әллә татар-төрки Киев каһанлыгымы?

Айрат Чанышев

Татарларның Россия дәүләтен төзүгә керткән өлешләре рәсми тарих фәнендә, сәясәттә, массакүләм мәгълүмат чараларында бик искә алынмый. Шул исәптән бабаларыбызның Киев Русен, Россияне төзүгә, русларның дан-дәрәҗәсен, санын арттыруга керткән өлешләре дә читтә кала.

***

Шуны да искәртик: безнең фикеребезчә, татар-төрки дип язу дөресрәк һәм хакыйкатькә якынрак. Беренчедән, татар төшенчәсе төрки төшенчәсеннән ким дигәндә 750 елга борынгырак. Балканнан алып Океаниягә кадәр җәелгән Чыңгыз империясе күктөркиләренең (төркетләрнең) Төрки каһанлыгыннан ким дигәндә җиде тапкыр зуррак. Инкыйлабка кадәр тюркология фәне булмаган, галимнәр татароведение фәнен генә белгәннәр. Ә тюркология терминын, татарның бөеклегеннән куркып, Сталин әйләнешкә кертеп җибәрә, совет галимнәре аны бар планетага тарата. Шуны да онытмыйк: дөнья буенча сибелгән төрки кавемнәр олуг, бөек татар халкының нибары бер өлеше генә!

***

Киев Русе халкының күп өлеше татар-төркиләрне тәшкил иткән. Зама-

Авар сугышчысы.
Фото kdet.ru сайтыннан алынды.

нында ул Авар каһанлыгыннан аерылып чыккан һәм элгәре Киев каһанлыгы дип атап йөртелгән. Шуны да искәртик: Аурупа елъязмаларында «Киев Русе» дигән атаманы күрмәссез. Бар чыганакларда да – «Киев каһанлыгы». Киев дәүләтендә, борынгы татар традициясен дәвам итеп, каһан идарә иткән.

Киевлеләрнең аварлардан аерылып чыгу процессына да аңлатма биреп узу кирәк. Чикләре хәзерге Франциядән алып Дон елгасына кадәр булган Авар каһанлыгы, франклар һәм башкаларның даими һөҗүмнәре нәтиҗәсендә, берничә татар-төрки дәүләтенә таркала. Мәмләкәтнең көнчыгышында, Карпат-Дон аралыгында – Киев каһанлыгы, Азак (Азов), Кара диңгез буйларында Бөек Болгар дәүләте барлыкка килә. Ә Авар каһанлыгы үзе исә, атаклы Аттиланың көнбатышка данлы походыннан соң, Ауропада яшәп калган борынгы һуннар дәүләте, ягъни Бөек Һун империясенең дәвамчысы була. Ул хәзерге Венгрия, Австрия, Швейцария, Чехия, Словакия, өлешчә Германия, Польша һәм Украинаны, Россиянең Украинага чиктәш өлкәләрен, Румыния, Бөек Болгар һәм Төньяк Македония җирләрен колачлаган. Кызганыч ки, 300 ел буе Ауропаның иң зур мәмләкәте булган, континент тарихында чамасыз зур роль уйнаган, ике гасыр Византиядән ясак түләтеп торган Авар каһанлыгы турында тарих дәреслекләрендә искә алынмый диярлек.

Авар дәүләтенең Киев каһанлыгы буларак аерылып чыккан өлеше, берникадәр вакыттан соң, татар-төрки Хәзәр каһанлыгына буйсынырга мәҗбүр була, аның бер олысы булып исәпләнә башлый. Киев кенәзләре 965 елда Святославның Хәзәр каһанлыгына оештырган хәрби походына кадәр бу илгә ясак түләп тора. Киев каһанлыгы, хәзәрләрдән бәйсезлек алып, мөстәкыйль дәүләткә әйләнеп, өлешчә славянлашкач та, аның тарихын көньяктагы күршеләре, татар-төрки бәҗәнәк, кыпчак, бродник, карабүрек (черные клобуки) кавемнәреннән башка күз алдына китереп булмый. Алар бу ил үсешенә, ул чорлардагы рус кенәзлекләре үсешенә дә зур йогынты ясаганнар. Рус-совет тарихчысы, академик М.Н.Покровский үзенең «Русская история с древнейших времен» дип аталган хезмәтендә: *«Киев Русеның славянлыгы турында, гомумән, бернинди сүз дә булырга мөмкин түгел. Ул скандинавлар хакимлеге астындагы фин-угырлар һәм татар-төркиләр дәүләте булган. Славяннар булган очракта да, алар хәзерге Украинаның көнбатышында, аз санда гына булганнар»,* – дип яза. Совет тарих фәненә нигез салучыларның берсе булган бу мәшһүр академик хәзерге русларны руслашкан фин-угырлар һәм татар-төркиләр дип исәпли. Атаклы «Словарь живого великорусского языка» авторы В.И.Даль да шундый ук фикердә тора. Гомумән алганда, русларның, шул җәһәттән хәзерге украин һәм белорусларның XVIII гасырга кадәрге үткән юлы затлы татар тарихының бер сәхифәсе генә.

Күренекле гарәп сәяхәтчесе, галим әл-Гарнәтинең XII гасырда Киев шәһәрендә булуы күпләргә мәгълүм. Ул анда күп сандагы бәҗәнәкләр булуын, аларның ислам динендә икәнлеген, кайбер дини йолаларны дөрес башкармауларын язып калдырган. Мәсәлән, әл-Гарнәти, Гуркирмәндәге (Киевтәге кияүләр кирмәнендә) мөэминнәрнең җомга намазын белмәүләрен искәртеп: *«Мин аларны җомга намазына, анда хөтбә укырга өйрәттем»,* – дип әйтә. Аннары ул бу калада багдадлыларны да очрата, башка милләт кешеләрен дә күрә, әмма шәһәрдә рус яки славяннар яшәве турында бер мәртәбә дә искә алмый.

«

Бу гамәл дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү максаты белән, илгә чит-ят фикер үтеп кереп, фетнә кубармасын өчен махсус эшләнгән.

Авар атының сбруе.
Рәсем М.И.Артамонов китабыннан (1962 ел) алынды.

Киев каһанлыгының соңыннан славянлашкан татар-төрки дәүләте булуына янә бер дәлил китерик. Киев каһанлыгы белән бәйле иң борынгы чыганак – анда яшәгән бер яһүднең икенче яһүдкә язган хаты. Яһүд (иврит) телендәге әлеге чыганак X гасырга карый. Әмма хатның астына нindидер бер түрә саф татар-төрки телдә рун язуы белән: *«Мин моны укып чыктым»,* – дип, тамгасын салган. Димәк, ул вакытта ук инде Киев каһанлыгында почта (ям) хезмәте булган. Илгә җибәрелгән хатларны төрле түрәләр укып-тикшереп торырга тиеш булган һәм, хатны иясенә тапшырырга яраганын аңлатып, резолюция салган. Бу гамәл дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү максаты белән, илгә чит-ят фикер үтеп кереп, фетнә кубармасын өчен махсус эшләнгән. Күренә ки, ул заманда Киев каһанлыгының күпчелек халкы славян яки рус түгел, ә татар-төрки булган. Дәүләттә рун алфавиты кулланылган. ■

Әхмәд бай

(1837-1906)

Ризаэддин бине Фәхреддин

Русия мөселманнары файдасы өчен ярым миллион сум микъдарында вакыф калдырмыш мәшһүр сәүдәгәр Әхмәд бай хакында язылмыш бер әсәрдер.

Әхмәд бай

مرحوم احمد بای .



« وقت » مطبعه‌سی اورنبورغده .

Әхмәд бай Каргалы шәһәрендә дөньяга килә. Башка тумалары белән бәрабәр аталарыннан фәкыйрь хәлдә ятим буларак калулары сәбәбеннән, дөньяның күп мәшәкатьләрен күргән, хәтта ки кара эшләр эшләп йөргән вә көненә 12 тиенгә ялланып кизәк вә кирпеч суккан.

Соңрадан бервакыт ничек булса да биш сум акча хасил итеп, Оренбург шәһәренә килә, кырыктартмачылык сәүдәсенә керешкән... Ошбу кәсебе аз-азлап булса да алга китеп, көннәрнең берендә ат-арба алган. Әхмәд, үзенең ат-арбасын җигеп, татлы тамыр вә күкташларын салып, казакъ арасына чыгып киткән. Казакълар илендә: «Акча сатам, нә бирәсез? – дип, сәүдә кылып, әйбер алмашып йөргән. Үзенең тырышлыгы вә казакъ халкының садәлеге, шул җирләргә бу вакытларда немец вә яһүдиләрнең аяк басмаганлыкларыннан яхшы дәүләт (байлык) хасил иткән. Моннан соң туганнары белән Оренбург шәһәренә күчеп киләләр. Шулай сәүдә кылып, олуг байлыкка ирешәләр. Утыз биш ел бергә сәүдә иткәннән соң, 1896 елда Әхмәд хаҗи, Габделгани хаҗи вә Мәхмүд – өч агай-эне дүрт миллион сум дәүләтне бүлешәләр.

Әхмәд бай 1879 елда хаҗ кылды вә, Мәдинәгә барып, Рәсүлулла мәчетенә зиярәт итте. Россиянең бөек шәһәрләрендә сәүдә итеп йөрегәннән соң, шул ният белән Германия вә Англия мәмләкәтләренә дә сәяхәт итте. Туганнары белән мал бүлешкәннән соң, Казан шәһәренә күчеп китте вә шунда 1906 елның 10 декабрендә дөньядан үтте. Вафат булган көнендә якынча бер миллион да алты йөз мең сумлык мирасы калды. Васыятендә билгеләнгән сумманы чыгарганнан соң, калган өлеше туганы Мәхмүд Хөсәенов белән хатыны Гайшә Габделгаләм кызы арасында бүленде. Аллаһы Тәгалә гафу итсен вә гаепләрен кичерсен.

Сабыйлык вакыты вә тәрбиясе

Әхмәд бай сабый вакытында бик шук вә шаян булып, тәүге тәрбиясен анасы Хәмидә карчыктан алган. Соңра үз мәхәлләләренең мөәзиненә йөреп, дүрт-биш кыш гомер уздырган. Вә берничә Һәфтияк шәриф туздырган булса да, укырга вә язарга өйрәнә алмаган. Баеганнан соң вексель вә чек кебек кәгазьләргә, үз исеменнән язылган хатларга имза куярга кирәк булганлыктан, кара савытына батып чыкканнан соң кәгазь өстеннән үтеп киткән кара таракан аякларының эзенә охшашлы бер рәвештә имза кылырга өйрәнгән иде. Фәкать русча имзасы мөселманча булган имзасына күрә байтак артыктыр. Дүрт кыш мәктәпкә йөреп тә үз имзасын куя белмәгәнен бу заман яшьләре, ихтимал, арттыруга юрарлар. Фәкать монда арттыру юктыр. Хәтта үзе дә мәдрәсәләр эшен яхшылату хакында сүз чыккан мәҗлесләрдә: *«Мин биш сум акча белән дүрт миллион мая хасил иттем. Инде минем хакымда аңгыра, зиһенсез, ялкау, иҗдиһатсыз дип әйтүче булырмы? Шулай булса да, дүрт кыш укып, исемемне язарга вә укырга өйрәнә алмадым. Буның сәбәбе минем ялкаулыгым вә иҗтиһатсызлыгымнан түгел, бәлки, башка бернәрсәдер»,* – дип һәрвакыт сөйләр иде.

Кәсеп вә сәүдәсе

Казакъ халкының садәлеге вә Идел елгасыннан ары локомотив үтмәгәнлеге Әхмәд байның дәүләт табуына бер сәбәп булуында шик юктыр. Моның белән бәрабәр: *«Тырыш адәмгә Аллаһы Тәгалә ярдәм бирәдер, кеше булдырган эшне булдырырга минем дә кулымнан килергә тиешле»,* – дип ышануының да олы нәтиҗәсе булмыштыр. Шулвакыт мөселманнарның йөрәкләре җитмәслек

Әминә Мәхмүд кызы Хөсәенова. 1922 ел

рәвештә сәүдәләр кылуы вә фабрикалар эшләтүе мәзкүр ышануының нәтиҗәсе булса кирәк.

Үзеннән мал алган немец вә яһүдләрне күргәндә: *«Болар бездән алган нәрсәләрне Европа базарында күп файдалар бәрабәренә сата булсалар кирәк. Шундый базарлар белән турыдан-туры үзебез мөнәсәбәт итсәк вә маклерсыз мөгамәлә кылсак, тагы да артыграк файда киләчәктер»,* – дип, Европа базарларына йөреп, сәүдә конторалары ачып карады. Әхмәд бай көнчыгыш тарафына яраклы булган фәлсәфә вә тәҗрибә көнбатыш тарафында яраклы булмаганын үз күзе белән күреп белде. Ошбу хакта бәхәс иткән бер мәкаләсендә мөхтәрәм Йосыф әфәнде Акчура болай ди: *«Яһүди вә немецлардан бер төркем Оренбург шәһәренә вә аның тирәсенә килеп, эчәк җыярга керештеләр вә моны чит мәмләкәтләргә җибәреп тордылар. Әхмәд бай исә эчәкләрне, ни өчен җыелуын вә ни җирләргә җибәрелгәнен белмәгәне хәлдә, шул яһүд вә немецлардан күрмәкче, алар чыгарган базар хисабы белән эчәк җыярга кереште. Үзенең сәүдәгә осталыгы сәбәбеннән эчәкне очсызга алганга, яһүд вә немецларга сатып, байтак файда күрә иде. Соңра эчәкләрнең ни өчен җыелганлыгын вә кай җирләргә киткәнен өйрәнде. Ошбу вакыт немец вә яһүдләрнең маклерлыкларыннан котылып, эчәкне немец вә яһүдләрне йөретә торган олы комиссион исеменә үзе җибәрер булды. Соңра боларның арадашлыгыннан да котылмак фикеренә килеп, турыдан-туры сәүдә ачу нияте белән, 1893 елда Берлин шәһәренә олы партия эчәк китереп, сәүдәханә ачты. Мал күп, акча күп, җитәрлек кадәр акыл вә фикер бар. Әмма Әхмәд бай ул җирнең телен белмәс, сәүдә вә тормыш ысуллары белән таныш түгел иде. Шулай итеп, ошбу хәлләр Әхмәд байны Берлинда яһүдиләр ярдәменә мохтаҗ кылды. Вә ул Россия гражданы булган бер яһүдине үз хезмәтенә алды. Малны очсыз алу юлларын белгәнлектән, Әхмәд бай ошбу сәүдәханәсеннән зарар итмәде. Ошбу вакытта Әхмәд бай ике мәртәбә Берлин шәһәренә килмештер. Ләкин биш елдан соң, 1898дә сәүдәханәне бөтенләй япты вә эшләрен туктатты.*

Сәүдә эшләренең иң мөшкел вә иң яшереннәрен тәҗрибәсе белән белгән Әхмәд байның ошбу сәүдәханәсен ябуына вә эшне туктатуына төп сәбәп – белемсезлек иде. Әгәр дә Әхмәд бай турыдан-туры немец эчәкчеләре белән сөйләшергә вә бу турыда алар белән тәрҗемәчесез аңлашырга сәләтле булса

иде, ихтимал, сәүдәханәсен ябачак җирдә тагын артык тәрәккъый кылдырыр (яшәтер) иде».

Икътисади сәләте

Яшьлегендә күп зәхмәтләр күреп, хәтта ки читләрнең авыр хезмәтләренә ялланып эшләгәне сәбәбеннән булса кирәк, Әхмәд бай мал кадерен белер, урынсыз җиргә бер тиен дә сарыф итмәс өчен тырышыр иде. «Мал мине тапмый, бәлки, мин аны табам» яки «Кеше малы түгел, үзем тапкан мал» сүзләрен Әхмәд бай гомерендә бер кабат булса да әйтмәде. Сәфәргә чыкканда азыгын йортыннан хәзерләп чыгар, пароход залларында халыклар сыйланып йөргәннәрендә, бу үзенең күмәч вә итен ашап канәгать итәр иде. Зур бер эш мәҗбүр итмәгәндә, юлда беренче дәрәҗәдә түгел, бәлки, икенче дәрәҗәле урыннарда йөрер. Арбачылар белән дә озак сатулашканнан соң гына утырыр. Хатларын күп вакытта шул тарафка йөрүче белән җибәрер, андый кеше булмаганда гына почтага бирер иде. Мондый хәлләрне янында йөрүчеләрнең күпләреннән ишеттек.

Хөсәен Мәхмүд улы Хөсәенов. Оренбург. 1911 ел

«Хатыннар ихтыярына куйсаң, көннең салкынлык-җылылыгына күрә түгел, бәлки, үз кәефләренә карап мичкә ягалар. Шуның өчен, һәркөн суыклык дәрәҗәсе белән бу көн фәлән кисәк ягарга тиешле дип санатып яктырам»,– дигәнен ишеттем. Әхмәд бай һәрвакыт: *«Мал белән тәмугъдан котылып оҗмахка кереп буладыр, малны кадерсез кылырга вә урынсыз тотарга ярамас»*, – яки: – *Акчаның һәр тиене Аллаһы Тәгаләнеке, минем кулымда әманәт буларак кына торыр. Аллаһы Тәгалә риза булмаслык җирләргә бер тиен бирмәм»,* – дияр иде. Яшьләргә вә бай балаларына булган нәсихәте дә һәрвакыт: «Акча арыслан авызындадыр, җегет булсагыз, шуннан алыгыз», – дияр иде. Ошбу сәбәптән Әхмәд бай хәтта ярым тиенгә кадәр дикъкать итәр булган. Һәрнәрсәнең яхшысын карап, арзан алу иҗтиһадында булганга, аның белән эш йөртү авыр булмыштыр.

Халыклар аш-су, кунак сыйлау хакында бер-бере белән ярышкан вакытларында, Әхмәд бай үзенең иң хөрмәтле кунакларына: *«Үз тегермәнебезнең эше»,*

– дип, тары боткасы пешереп ашатыр икән. Моның максаты халыкны чама белеп яшәүгә өндәү булса кирәк. Казан байлары арасында булган корсакка табынучылар, шундый сыйлауга канәгать итмәүләреннән, Әхмәд байның ашларын мәсхәрә кылып, урыс газеталарына яздырдылар.

Мал кадерен белүе сәбәбеннән, хаҗилар тарафыннан бугазланмыш корбан малының тиреләрен җыеп, кыйммәт хаклары белән сату вә берәр төрле изге юлларга сарыф итү чараларын эзләп вә фикерләп йөргән. Шул хакта бик күп адәмнәрнең уйларына салган була. Соңгы вакытларда Төркия хөкүмәтенең ошбу әрәм ителә торган тиреләргә күзе төшеп, акчага әйләндерә башлаганын сөйләделәр.

Динлелеге вә әхлагы

Әхмәд бай намаз үтәрлек кадәр сүрәләр вә догаларны күңелдән белеп, шуларны дөрес укыр, дин хөкемнәре турында мәхәббәтле вә ныклы булып, сәфәр вә тормышында намазларны вакытында үтәр вә казага калдырмас иде. Белмәгән нәрсәләрен өйрәнүдән оялмас, кылган изгелекләрен, башкаларны кызыктырып, шуны эшләтү теләге генә булмаса, белдермәс вә сөйләмәс иде. Динле, һөнәрле вә эшлекле, халык өчен файдалы адәмнәрне сөяр вә кирәк кадәр аларга ярдәм итәр иде.

Динендә йомшаклык күрсәтүче, намаз укымаучы адәмнәрне вә, гомумән, ялкаулар, акча кадерен белми торган яшь байлар, ач күзле вә үз вазыйфаларын җиренә җиткермәгән муллалар аның каршында очсыз бәһа белән йөридер иде.

Барлык ислам байларында булган олылык вә горурлыктан Әхмәд бай сәламәт иде. Өстендә – бәрән эчле ак тун, башында биш-алты сумлык бүрек булган хәлдә, иптәшебез белән безне түрдә утыртып, үзе кучер янында безгә каршы утырган хәлдә, Оренбург урамында күп мәртәбә йөрде. Һәркем белән сөйләшер вә сорашыр, кешегә һич тә ким күз белән карамас иде.

Казакъ арасында йөргән вакытында өстендә чикмән булганы хәлдә, чыбыркысын биленә кыстырып, арбасы янында янәшә йөрүләрен, юл буена үлән йолкып атына ашата баруларын вә, тәмам аргач, арбасында булган тартмалар, әрҗәләр өстенә менеп йоклауларын сөйләр вә бу йокыларның ләззәтләрен сагыныр иде.

«

Дөньяда булган бик күп яхшы эш вә бик күп хурлыкның сәбәбе мал вә байлык икәне мәгълүмдер.

Изге эшләре

Дөньяда булган бик күп яхшы эш вә бик күп хурлыкның сәбәбе мал вә байлык икәне мәгълүмдер. Безнең Әхмәд байның бөтен тоткан юлы вә максаты – мөселман фәкыйрьләренең балаларын укыту иде.

Әхмәд бай мал кадерен белгәне вә бер тиенне буш җиргә сарыф итмәгәне кебек, Хак Собханә вә Тәгалә ризалыгы өмид ителгән урыннарга вә изге юлларга сарыф итәр өчен омтыла иде. Моның кебек эшләр өчен кесәсе ачык вә кулы да югары торыр иде.

Әхмәд бай башкаларга мәңгелек вә гомерле, файдасы да дәвамлы булган изге эшләргә мәхәббәт кылыр, төзегән биналарның күркәм булуыннан бигрәк, чыдамлы булуына игътибар итәр иде. Үзе тарафыннан соңгы вакытларда бина

иттерелмеш мәктәп вә мәдрәсәләрнең һәрбере гадәти ташлардан салынмыштыр.

Борынгы байлар мәчет вә мәдрәсәләрне күбрәк базарлы авыллар вә җәмгыятьләр күп булачак җирләргә төзеп тә, шул мәчет вә мәдрәсәләрнең ялгыз үз исемнәренә генә караганлыкларын таләп итүләре мәгълүмдер. Әмма Әхмәд бай бергәләшеп хәл итү ниятендә булыр иде. Шул сәбәптән мәчет вә мәктәп бина иттеручеләргә ярдәмләшер, үз тарафыннан төзелгән корылмаларга башкаларның ярдәм кылуларын яратыр вә, гомумән, изгелек эшләрне җәмагать белән эшләүне хуп күрер иде. Шуның өчендер ки, мәчет вә мәктәп салыр өчен ярдәм сорап барган авыл картларына, хәл-әхвәлне сорашып бетергәннән соң корылма коруны тиеш тапса: *«Ярар, мин каралты корырмын, фәкать ком, балчык, агач вә таш кебек әсбабны үзегез чыгарып ташырсыз»,* – дияр вә халыкларның көчләре җитәчәк нәрсәләрне үзләреннән эшләтер өчен тырышыр иде.

«Бай, тырышлыгыгыз аркасында мәчетебез тәмам булды, фәкать намазлыгы юк, бик килешсез рәвешчә торадыр. Инде мәрхәмәт итеп намазлык та бирегез, шаять мәхрүм кылмассыз», – дип, намазлык сораган бер муллага ул: *«Хәзрәт! Мин бөтен изгелекне үземә генә кочып алу дәрәҗәсендә комсыз адәм түгел. Мәчет төзү тәмам булган икән, гүзәл эш. Инде намазлыкны авылның карчыклары вә хатыннары җыелышып җәйсеннәр. Бу мәчеткә аларның да маллары вә кул хезмәтләре катышсын! Намазлык та бирсәм, ихтимал: «Инде, бай, намазыбызны да укып бир!» – дип килүегездән куркам. Шуның өчен намазлык бирмим. Ихатасын да үзең тоттыр, фәлән кадәр байлыгың барлыгы миңа мәгълүм»,* – дип әйтә.

«Казан шәһәрендә торган ун ел вакытында һәрберенең чыгымы өч мең вә аннан артыграк булган егерме мәчет вә мәдрәсә бина итте, кырык кадәр мәктәпнең мөгаллимнәренә вазыйфалар түләп, ике йөз кадәр мәктәп өчен кирәкле китаплар биреп торды.

Казан шәһәрендә торган ун ел вакытында һәрберенең чыгымы өч мең вә аннан артыграк булган егерме мәчет вә мәдрәсә бина итте, кырык кадәр мәктәпнең мөгаллимнәренә вазыйфалар түләп, ике йөз кадәр мәктәп өчен кирәкле китаплар биреп торды.

Мәкәрҗә ярминкәсе мәчетенең имамы торыр вә балалар укыр өчен дип төзелгән кырык мең сум кыйммәтендә булган вакыф йорты Әхмәд бай иҗтиһады белән мәйданга чыкты вә моның өчен үзе уникe мең сум бирмештер.

Уфа шәһәрендә булган «Госмания» мәдрәсәсенә бер мең сум иганә иткән вә Казан шәһәрендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе файдасы өчен утыз мең сум чыгым тоткан. Мәкәрҗә ярминкәсе бистәсендә булган Лапаштин номерларын вә Оренбург шәһәрендә үз мәдрәсәсе «Хөсәения» өчен, Мәкәрҗәдәге «Хөсәенов утары»н тоту өчен зур чыгымнар кирәк була. Болардан башка, өч йөз егерме мең сум төрле урыннарда бина, идарәләр тоту өчен вакыф ителмештер. Шул җөмләдән егерме биш мең сумы Оренбург шәһәрендә булган мөселманнарның «Җәмгыяте хәйриясе»нә билгеләнгән.

Текстны басмага ***Райсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

Данис Шакиров: «Эшмәкәрлек – татар авылының нигезе һәм киләчәге»

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм эшкуар Эдуард Ганиев VI Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены вакытында. 14 март, 2017 ел

Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены быел (ул 17-18 мартка тәгаенләнде) унынчы мәртәбә уздырыла. Анда илебезнең 50дән артык төбәгеннән 500 эшкуар катнашачак. Хәзерге көндә Россиядә 4200 татар авылы бар. Шуларның 2500е – Татарстанда, калганнары – чит төбәкләрдә. Россия Федерациясендәге татар авыллары башка милләтләрнекеннән аерылып тора. Халкыбыз тырыш-уңган һәм эшлекле. Ул нык капка, төзек йорттан ук күренеп тора. Эшмәкәрлек – татар авылының нигезе һәм киләчәге. Әлеге тырыш милләттәшләребез ярдәме белән, татар авылының милли мәгарифе һәм мәдәнияте, гореф-гадәтләре, йолалары саклана, социаль объектлар төзелә. Чуашстанның Тукай, Урмай һәм Шыгырдан, Самараның Гали һәм Камышлы, Пенза өлкәсенең Әләзән авыллары, Мордовиянең Әзүркәләре… Кайсы гына төбәкне искә алма, үрнәк итеп күрсәтерлек, һәркайсында горурланырлык татар авыллары бар. Әлбәттә, аның нигезендә милли тормыш, дин һәм эшмәкәрлекнең бергә үрелеп баруы ята.

Әгәр дә без XIX гасыр-XX гасыр башы татар тарихын күзәтәбез икән, мәгърифәтчеләр, эшмәкәрләр һәм хәйриячеләрнең мәдрәсәләр салганын, газета-журналлар чыгарганын, милли мәгарифне дә булдырганын беләбез. Безгә бүген дә, әлеге традицияне яңартып, хәзерге эшмәкәрләргә үзләренең шушы изге эшне дәвам итүчеләр икәнлекләрен төшендерергә кирәк. Россиядә «Татар эшкуарлары

бизнес-клубы» уңышлы эшләп килә. Бу – Татар конгрессының иң уңышлы проектларыннан берсе. Аның үз мохите, традициясе бар. Быелгы җыенга җир кешеләре, җир милкен, төбәк проблемаларын аңлаган, авыл һәм аның милли мәдәнияте үсешенә зур өлешен керткән эшмәкәрләр киләчәк. Бөтендөнья татар конгрессы – Россиядә бердәнбер татар авыллары эшкуарларын туплый торган мәйдан.

Данис Шакиров һәм Ләбиб Лерон

Һәр чорның үз шәхесләре бар. Милли җанлы авыл эшкуары дигәндә, бакыйлыкка күчкән Эдуард Әнвәр улы Ганиевне мисал итеп китерер идем. Гомерен халкыбызның милли һәм дини мәнфәгатьләрен яклауга багышлаган, матди ихтыяҗ беренче чиратта торырга тиеш түгел икәнлеген бөтен дөньяга аңлаткан шәхес ул. XIX гасыр- XX гасыр башындагы игелекле татар байларының дәвамчысы булды Эдуард хаҗи. Башкортстанның Туймазы районындагы Төмәнәк авылында яшәүче, Бөтенроссия Татар авыллары ассоциациясе рәисе Фәнир Галимов та – халкыбызга уңышлы хезмәт итүчеләрнең берсе. Шул төбәктә уза торган барлык татар чараларын – Ык буе Сабан туйларын, «Җырлыйк әле» фестивальләрен уздыруда, мәдәният коллективларын туплауда, көндәлек тормышта милли сәнгатебезне пропагандалауда аның башкарган эшләре бихисап. Ул – Бөтенроссиядәге татар авылларының үсешенә үзенең идеологик фикерләре белән үрнәк булып торырлык шәхес. Мордовия Республикасында «Татар эшкуарлары клубы» да яхшы гына эшләп килә. Дистәдән артык ир-ат бу төбәктә социаль объектлар төзүгә һәм авыллар үсешенә үзләренең зур өлешен кертә. Ә иң мөһиме – яшь буынга үзебезнең мирасыбызны, сәнгатебезне, гореф-гадәтләребезне җиткерүдә бәһасе булмаган эшләр башкара алар. «Авылым тавышлары» татар җыры конкурсы үзе генә дә ни тора! Әлеге нигез Мордовия өлкәсенең Ләмберә районындагы Аксун авылында быел Бөтенроссия авыл Сабан туен уздырырга мөмкинлек бирә. 300 елдан артык тарихы булган данлыклы татар авылы ул! Россия төбәкләрендә татар тарихын өйрәнү мәсьәләсе дә актуаль. Бу өлкәдә дә авыл эшкуарлары – безнең төп таянычыбыз.

Күп авылларда мәхәллә системасы яхшы гына эшләп килә. Алар бар ихтыяҗларын үзләре, җирле хакимият белән килешеп, комплексы хәл итә. Ульяновск өлкәсендә татар эшкуарларының «Сембер» клубы бар, Сарытау өлкәсендә дә татар эшкуарлары бизнес-клубы оешып килә. Бу мисаллар авыл эшкуарлары хәрәкәтенең алга таба үсеше турында сөйли. Әйткәнемчә, әлеге җыен матди ихтыяҗ өчен түгел, ә авыл үсешенә үзләренең саллы өлешен керткән шәхесләр өчен бер мәйдан. Бу – Татар конгрессында иң өстенлекле эш юнәлеше.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров сөйләгәннәрне журналга ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

«Бозау тиресенә язылган кәгазьләр булган»[1]

Миркасыйм Госманов

Миркасыйм Госманов

Быелдан башлап Татарстан территориясен регуляр рәвештә археографик планда тикшерергә булдым. План шулайрак: Тау ягыннан башлап, төньякка үрләп, Казан артына күчү, аннан әкренләп көнчыгышка таба чыгу. Бу перспектив план... Ә хәзергә, дөресрәге, быелга, Чүпрәле, Буа, Тәтеш һәм Апас районнарын йөреп чыгарга ниятләдем. Кыштан кайгыра торгач, машина да бирделәр. Җиңел ГАЗ-69. Дүрт кеше: мин, беренче курсны бетергән студентлардан Мөхәммәди Мөхәммәтшин[2], Җәүдәт Тәрҗеманов[3] һәм шофер Ренат Сиражетдинов. Әзерлек әллә ни зур түгел. Шулай да шактый күп адреслар алдым... Ярар, күз күрер.

[1] VIII археографик экспедиция көндәлегеннән кыскартып тәкъдим ителә.
[2] Мөхәммәди Мөшәрәф улы Мөхәммәтшин (1945-2016) – Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, туган ягына кайта, Әлмәт районында укытучы, мәктәп директоры булып эшли, 1975 елдан Чаллы шәһәрендә яши.
[3] Җәүдәт Харис улы Дәрзаман (Дәрзаманов) (1945-2019) – күренекле шагыйрь, прозаик, журналист.

3.07.1968.

Иртәнге 9да машина белән Казаннан чыгып киттек. Көн бүген чак кына болытлы һәм салкын җилле иде. Паром белән Югары Ослангa үтеп, Буа тарафына юл тоттык. Юл әшәке... Көндезге өчләрдә Буа шәһәренә җиттек. Сасы гына, тузанлы-пычрак кына бер шәһәр кисәге...

Ашханәгә кереп, тамак ялгап алгач, Райбашкармага кереп, документларны рәтләдем. Аннары Вахит Хаковның каенатасы Фәтхелислам абзый Гарифуллинга кереп, бер чәйләп, сөйләшеп алгач, Вахитны эзләп, Күзби (Средние Лащи) авылына килдек. Тик Вахит өендә булмады. Без Килдуразга киттек. Колхоз рәисе Фәрит Әбүзаровка кереп сөйләшеп, фатирга урнаштык. Авыл зур гына. Ләкин бүген бик арылган. Беркая да чыкмабыз...

4.07.1968.

Төн бик җилле иде, начар йокланды. Иртүк Күзбигә киттек. Юлда Вахит очрады. Аның авылына кереп, бөтен әйләнә-тирә авылларның адресын алып, аннан Әхмәт авылына Вазыйх Ибәтуллинга килдек. Ул өендә юк иде. Яңа Чәчкапка барып, үзен алып кайттык. Ул почтальон булып эшли икән. Кульязмаларын карадык. Охо! Табыш! Бер төптә «Тәварихы Болгария» белән «Нәһҗел-Фәрадис» (1 баб)! Менә шәп! Дөрес, икесе дә 19 нчы йөз күчермәсе, ләкин төзек. Тагын бер шигырьләр мәҗмугасы.

Күзбигә килеп, Вахит Хаковны алып, Өчмунча авылына киттек. Анда Шакир Мөхәммәтшин дигән бабайга кереп, бер җыентык алдык: төркичә борынгы телле поэма һәм фарсыча бер хикәяләр җыентыгы, шигъри парчалар белән. Тагын Күзбигә кайттык.

Вахитларда төшлек ясап алган арада, егетләр бер кульязма табып кайттылар, эчендә «Рәүнак әл-ислам» бар. Баш өлешендәге шигъри әсәрләре дә шактый кызык булырга тиеш тел ягыннан. Кичен яңадан Килдуразга кайттык.

8.07.1968.

Черкен авылына килдек. Кәлимуллина Гөлсем дигән бер әбигә кереп (Бакый Урманченың җиңгәсе), чормасына менеп, 10-15 кульязма алып төштек. Барысы да юриспруденция һәм сарыф буенча диярлек. Барысын да алырбыз... Малайлар да эзләп йөриләр.

Насыйбуллин Салих абзый дигән кешеләргә фатирга урнаштык. Әлеге Гөлсем әбидән алып кайткан әйберләрне караштырдым. Нигездә, фикһ әсәрләре. Бер җыентыкта Нәваи шигырьләреннән дә үрнәкләр бар. Урта Азия күчермәсе. Гомумән, бу коллекция начар түгел...

Бик арылган. Кичен өйдә яттык, хәтта әтәч холыклы егетләр дә... Көн җилле. Тузан. Җир яңгырга сусаган.

9.07.1968.

Төнне бик начар үткәрдем: кандала!.. 3-4 сәгать йоклап булдымы икән...

Егетләр авыл кыдырып киттеләр. Мин машинаны паркка илтеп, аккумуляторны карарга калдырдым, җәяүләп фатирга кайттым. Юлда ике бабай белән сөйләшеп утырдым. Кызык хәл: тарихларын Болгарга, ә Болгар тарихын исә Хисаметдин Мөслими сафсатасына бәйләп аңлаталар. Тәкә сакаллы, чепчә күзле бабайның безнең якларга Мөхәммәднең (с.г.в.) үз чорында ук сәхабәләре килүенә бер дә шиге юк. Безнең бу Күл Черкене авылына 1300 елдан артык!

Көн бик бөркү, әшәке иде. Фатирга кайтып яттым...

Тел ягыннан бу як шунысы белән игътибарга лаек: халык үзен татар дип исәпли, телендә мишәр элементлары шактый. Бигрәк тә ү-әү формасында: сәүгән, әү һ.б. Ләкин грамматик яктан тел төзек кенә. Көчәйттергеч кисәкчә булып «каты» сүзе йөри: «каты яхшы». Нәнием = җаным дигән мәгънәдә.

Вазыйхларда шәпләп мунча кердек. Үзебезчә кунак булдык. Мескен, ихлас күңелдән каударланып, безне кунак итте. Фатирга кич белән генә кайттык.

Иртәгә берничә өйдәге әбиләргә кереп булырмы икән? Яңгыр буласы, ахры. Печәнлеккә менеп ятармын...

10.07.1968.

Бүген бу авылдан китәбез. Каенлык, Казма авылларына сугылып чыккач, Норлат ягына күчәрбез. Яңгырдан соң көн матур, һава саф иде. Юл да тузансыз. Каенлык авылына килдек. Өйләргә кереп йөри башладык. Менә «Йосыф китабы»ның бер нөсхәсе. Яхшы язулы, тик, кызганычка каршы, дефектлы гына... Малайлар да бер шәп кенә әйбер тапканнар: Нәваи «Диваны»! Кызганычка каршы, бу да дефектлы, ләкин бик калын. Их, башы-ахыры булса икән... Шулай да 250гә якын кәгазьле калын кулъязма. Кулъязманы Хәдичә Гыйльметдинова дигән әбидән алганнар.

Карап утырам: бу авыл ярыйсы гына матур җиргә җайлашкан, тау култыгында. Урманы да ерак түгел...

Кичен егетләр бер бәетләр китабы алып кайттылар. Ярарлык. Сәйфуллина Бибинур дигән бер әбигә фатирга кердек. Берүзе генә. Тар гына...

11.07.1968.

Уф, Аллаһ, таң атып, торыр вакыт та җитте! Ә такыр идәндә аунаудан чокыр җир – төз, төз җир исә чокыр булды!.. Әлеге кандала төне дә болай газаплы булмаган иде. Юк, бүген үк бу авылдан шылырга кирәк...

Кайтышлый Күл Черкененә кереп, Мингазова Рабига ападан ике ярым дистә кулъязмалар алып чыктым. Ул китаплар аның әтисе Габделхәким мулладан калган булган. Ярар, табыш сан ягыннан бераз ишәйде. Әйтүләренә караганда, бу зур китапханәнең бер бәләкәй ертыгы гына. Хуҗа әби кызы Динә үзе үк бик күп китапларны яндырган булган. Алар арасында «Аң», «Йолдыз» төпләмәләре дә булган... Эш үткән шул. Шулай да, бу да бер зур китапханә ертыгы булуы белән бик әһәмиятле!

Малайлар, Норлатта көне буе йөреп, бернәрсә дә таба алмаганнар... Наратбаш авылына китәргә кирәк булыр. Монда калырга артык язмасын: Бибинур әбинең сасы идәнендә тагын бер төн аунаудан мәгънә юк. Наратбашта бригадир – Булатов, партоешма секретаре – Газизов Хәлил. Килдек. Бригадир юк, ә теге Газизов дигәне шыр исерек. Шулай да безне бер фатирга урнаштырды. Төн яхшы узды. Тик карт әби, кызының (анысы 40та, бер күзе сукыр, өстәвенә, котырган зәһәр...) караватын күзәтеп, төне буе йокламады.

12.07.1968.

Малайлар берничә адрес буенча киттеләр. Мин кайбер кулъязмаларны карар өчен калдым. Ләкин, үзе эзләп, Низамиев Борһанетдин[4] абзый дигән кеше килде.

---

[4] Дөресрәге – Борһан Низамов. М.Госмановның шәхси архивында Б.Низамовтан 1968-1972 нче елларда җибәрелгән 7 хат саклана.



Археографик көндәлек сәхифәләре

Бераз сөйләшеп утыргач, чакырып, өенә алып китте. Аның мәгълүматы: элек Нәратбаш 230 йортлы зур авыл булып, революциядән соң икегә бүленә. Бу авылда, без йоклап торганчы, имештер, китаплар җыеп яндыручылар килгән, дигән хәбәр таралып, иртәнге якта барлык әбиләр шамаил-фәләннәренә хәтле яшереп өлгергән булганнар... Киттек Буага, аннан Толымбайга.

Балчыклы юлның шактыен узып, Яңа Тинчәле авылына килдек. Бездәге студент Роберт Закиров шушы авылдан. Авыл шактый зур. 400дән артык йорт. Иске Тинчәле юлда калды.

Робертның әнисе Әминә апаларга туктадык. Бик яхшы каршылады. Көн дә бераз ачыла төште сыман. Бүген кич ял, чөнки минем дә, Җәүдәтнең дә бераз кәефләребез юграк. Әллә ничек эсселе-суыклы булып тора. Аяклар туңа, билем дә сызлый. Егылмасам ярар иде.

13.07.1968.

Төн бик борчулы узды. Чир – чир инде. Көн һаман болытлы. Идарәгә барып, азык-төлек яздырып кайттык. Егетләр белән чыгып киттек. Умартачы Вәлимөхәммәт Бакировка килдек. Сөйләвенә караганда, бу авылга 400 ел тирәсе булыр. Ул шәҗәрәләргә нигезләнеп сөйли. Кулларда шәҗәрәләр булган, аның хакында Нурми Ильясов белергә тиеш.

Вахитов Тәуфыйк[5] абзыйда иске кульязмалар күп булырга тиеш. Зиратта күп булырга тиеш. Миңлемөхәммәт абзыйда бер XIX гасыр кульязмасын (гарәпчә, дини) карадык.

[5] 1969 елның 18 ноябрендә язылган хатта Т.Вахитов иске китапларны һәм кульязмаларны почта аша посылка белән җибәрүе турында хәбәр итә. Хат М.Госмановның шәхси архивында саклана.

«Авыл тарихы:

Бу авылга элек 25 хуҗалык килеп утырган. Халык үрчегән. Җир җитми. Авылдан Әбүбәкер (Бәкер) исемле кеше, приговор язып, 25 хуҗадан башкаларыннан тамга салдырып, Әби патшага бара. Әби патша җир бүлергә риза булмый. Шулай да Бәкер, авылга кайтып, патша риза булды, дип, коткы тарата. Әлеге 25 семья кешеләре кул куеп җибәрә. Патша җирне бүлеп бирергә риза була, имеш. Бу җир бүленгәннән соң, авылда җир өчен сугыш та булгалап ала. Кешеләр дә үлгәлиләр».

Кишмаев Сәгыйть дигән кешегә килеп, аның атасы күчереп язган Тинчәле авылы тарихын карадык. Бик кызык, бик әһәмиятле әсәр. Эләктерергә кирәк. Бу тарихны күчереп язучы Җамалетдин Кишмаев.

Өйгә кайткач, китапны шактый җентекләп карап чыктым. «Тинчәле авылы тарихы»н язучы Касыйм Бикколов булган, ә Җамалетдин Кишмаев исә аны күчереп алган. Бу бик әһәмиятле региональ тарих. Әмма кульязманың 1905-1935 нче елларны эченә алган «елъязма»сы, Җамалетдинның көндәлеге дә бик-бик әһәмиятле. Шушы елларда авыл халкы кичергән хәлләр бик шәп сурәтләнгән...

Кыскасы, бу табыш – табышларның табышы! Бу Касыйм Бикколов шушы авылның укымышлы мулласы булган.

Кичен егетләр бер-ике кульязма алып кайттылар.

14.07.1968.

Тәүфыйк Вахитов дигән актив кына мәчет карты килде. Аңа ияреп, йортларга кереп йөри башладык. Төрле-төрле өзекләр булса да, кульязмалардан әллә нәрсә очрамый. Зиратка кереп карадык. Касыйм Бикколовның каберендә бер кечкенә генә таш. 1937 елны үлгән. Туган елы юк. Авыр елларны Касыйм мулланың китапларын үз кулы белән яндырган бер картны күрдек... Шактый озак вакыт йорттан-йортка кереп йөрдек. Мәгънә бик начар бүген...

Егетләр чыгып киткәннәр иде, Шәмсетдинов Хәлилрәхман дигән кешедән «Яңа Тинчәле авылы тарихы»ның тагын бер нөсхәсен алып кайттылар (кечкенә укучы дәфтәрендә, 20-30 нчы еллардагы кәгазьдә). Кызганычка каршы, бераз дефектлырак. Шулай да ике нөсхәне чагыштырыр өчен бик шәп булды! Молодец, егетләр! Тагын 1950 нче елларда күчерелгән бер өзек бар. «Яңа Тинчәле авылы кайчан утырган?» дигән бүлек. Кыскасы, авыл тарихы әсәре табылды, критик нөсхә эшләр өчен нигез бар...

Иртәгә китәргә тиешбез. Нәтиҗә: җирле тарих буенча бу авылда материал бик яхшы булды...

18.07.1968.

Олы Тархан авылына килдек. Тарханның бер ягын элек «керәшен» дип йөрткәннәр. Димәк, элек ул як чукындырылып, аннан кире күчкән булырга тиеш.

Фатирга урнашкач, машинада Идел буена төшеп киттек. Бик матур бер урынга килеп юындык, кер юдык, кызындык, коендык. Көн матур, һава саф иде! Рәхәт! Шул ук җирдә балыкчылар да бар иде, балык шулпасы да ашадык. Егетләр дә бик канәгать булдылар.

Кичен егетләр бер әйләнеп кайтып, берничә әһәмиятсез генә әйбер алып кайттылар. Ә мин Габитов Вәли дигән пенсионер укытучыга бардым. Сөйләвенә караганда, элек бу Олы Тарханда бик иске шәҗәрәләр һәм хәтта бозау тиресенә

язылган кәгазьләр булган, имеш. Ләкин хәзер эзләренә төшәрлек түгел. Ул минем адресымны алып калды: материаллар табып китерәм дип. Карарбыз. Алардан чыгып, Габдулла Дәминев дигән кешегә бардым. Ул яшь чагында берничә пьеса бастырган һәм җүн генә шигырьләр язган, соңрак «төшеп» калган һәм укытучы булып киткән кеше икән, хәзер пенсиядә[6]. Атеистик темага мәкаләләр язгалый, шигырь язуын да дәвам итә. Кичрәк кенә «мәҗлес» өстенә килдем, ләкин авызыма алмадым. Хуҗа бераз айныганчыга хәтле утырдым, бары шуннан соң гына үз максатымны аңлаттым. Иртәгә очрашып, берничә җиргә барырга вәгъдәләштек.

Болардан элек Төхфәтов Кәрим дигән бер бабайга кергән идем, «мулла» кисәге, куркуыннан бернәрсә дә күрсәтмәде. Шулай итеп, бүгенгә бик чамалы. Ләкин өметне өзмим әле...

19.07.1968.

Иртәнге якта колхоз үзәгенә – Бакырчыга барып, азык-төлек мәсьәләсен хәл иткәч, Габдулла абзый Дәминев белән әби-бабайларны кыдыра киттек. Озак йөрдек, ләкин искитәрлек дигәндәй бернәрсә дә тапмадык. Дөрес, Хөсәенова Мәхмүзә дигән бер әбидән фарсыча Коръән тәфсире алдым – язылышы, хатты һәм кыяфәте белән гаҗәп шәп әйбер!

Төштән соң өйдә китаплар карап яттым. Егетләрнең табып кайткан әйберләре арасында бернәрсә дә юк. Гомумән, бу авыл көткәндәгечә булмады: бик күп голәма йорты туздырылу өстенә, урамнарның күбесе янып көлгә дә әверелгән булган. Һәр йортта диярлек: «Янды шул алар», – дигән җавапны күп ишетергә туры килде.

Элек бу авылда керәшеннәр дә булган. Ләкин ул керәшеннәр ике динне дә тотканнар – үлгән кешегә элек мөселманча җеназа укып, аннары попны чакырып, христианча мәрасим ясый торган булганнар. Абдулла абзыйның сөйләвенә караганда, иң соңгы поплар 1905 нче еллар тирәсендә булган. Моңар хәтле Нимәт дигән бер кеше әтисен күмгән чакта, «только с попом хоронить!» дигән әмер буенча, туфрак салып торган попны кабергә егып, аны муенына хәтле күмәләр. Шуннан соң поп авылга килмәс була...

Село Монастырскоедагы (Тәтеш районы) Павел Васильевич (Бесок – кушаматы) – шушы кешедә өч телле көтепханә булган. Заманында Горький белән таныш булган, аннары чиркәү талавы өчен сөргендә дә булган. Бу кешенең карчыгы әле дә исән булырга тиеш. Ә Бесокның үлүенә 2-3 ел булгандыр...

Егетләр берничә әйбер алып кайтканнар. Бер-ике гарәпчә китап, XVII-XVIII гасырда күчерелгән. Әһәмиятле генә булырга охшый... Менә бер «Фәүзел-нәҗат» кулъязмасы һәм аның азагы: *«Ошбу китап мартның егерме өченче көнендә – кече җомга көнендә аш вакытында тәмам булды. Язгучы Фәхреддин Биккол дия беләсезләр, хәер-дога кыласызлар. Ошбу китапны Яңы Чәчкап авылының дамелла Бикмулла мәдрәсәсендә яздым. Мән Фәхреддин Түбән Наратбашының Биккол угылы».*

Менә шулай, «аш вакыты да» бар, әмма елы юк. Мондый колофон күп кенә очрый...

*Көндәлекне басмага **Диләрә Госманова** һәм **Ильяс Мөстәкыймов** әзерләде.* ■

---

[6] Күренекле татар җырчысы Руслан Габдулла улы Дәминевнең әтисе.

Татар бүреге

Бүрек сүзе, тел галимнәренең фикеренчә, бөркәү, каплау сүзләреннән килеп чыккан. Төрки халыкларда да бу сүз уртак тамырлы. Монгол телендә **borkur** (биредәге «о» һәм «u» хәрефләре өстендә ике нокта бар) сүзе *калпак, конус* мәгънәләренә ия. Алтай төркиләре әле дә бүрек һәм эшләпәне **борүк** («о» хәрефе өстендә ике нокта бар) дип атап йөртә.

Затлы кеш, сусар тиреләре белән камалган бүрекләребезне ханнарыбыз асылташлар белән бизәлгән алтын челтәрле очламга киертеп кигәннәр. Мәскәү Кремлендә урнашкан Корал палатасында сакланучы **«Казан бүреге»** (XVI гасыр) моңа бер дәлил.

XIX гасырларда бер төрек бүреген **иманлы бүрек** дип тә йөрткәннәр. Бу атама җәнлек тиресе белән камалган җылы бүреккә бирелгән. *Имансыз бүрек* дип эче мехлы, тышы камасыз, кырпусыз тирән бүрекне атаганнар.

Тәвәккәл бүрек дигән бүрегебез дә булган. Ул – мех эчле, тышы хәтфә яки постаудан 15-20 сантиметр биеклектәге гөмбәз сыман формада тегелгән. Дәлил итеп Н.Исәнбәт әсәреннән өзек китерәбез: *«Мин, туганай, **тәвәккәл бүрек**не кырын киеп алып, шул Шәрифәгә өйләнергә булып торам инде».*

Тарихи «Казан бүреге» (1553)

Камчат бүрек дигән баш киеме турында да еш искә алалар. Анысын, нигездә, шәһәрдә бай тормышта яшәүче өлкән буын киеп йөргән. Ә Урал буенда яшәүчеләр төлке тиресеннән тегелгән төлке бүрек кигәннәр. Камчат бүрек диюгә, Ока-Сура елгасы арасындагы территориядә яшәүче олы яшьтәге хатын-кызлар күз алдына килеп баса: алар да шундый баш киеменнән йөргән.

XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында кара һәм соры каракүлдән тегелгән Мәскәү бүреге шәһәр кешеләрендә киң тарала. Андый **каракүл башлыкларны** Идел-Урал татарлары бик яратып кигән.

*(Язма «Татар халкы традицияләрен саклау һәм үстерү «Татар ядкярләре» шәхси учреждениесе (җитәкчесе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Фәнзилә Җәүһәрова**) һәм Татарстанның халык язучысы **Рабит Батулла** белән берлектә әзерләнде.)*



Каракүл бүрек кигән татар кешесе

Мулланур Вахитовның (1885-1918) әтисе Муллаҗан

Татар бүреге кигән Мулланур Вахитов (уртада) Н.Вахитов (уңда) һәм А.Маликов белән – Мәскәүдән Казанга китәр алдыннан. 1 август, 1918 ел

Поляк гаскәрендәге Татар полкы сугышчысы. XVIII гасыр ахыры. ***Рәссам Тадеуш Корзон рәсеме***

Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла гаиләсе. 1990 нчы еллар уртасы

Наполеон чорында поляк гаскәрендә хезмәт иткән татар сугышчысының баш киеме. Бүрек өч өлештән – күзеректән (козероктан), чалмадан һәм ай-йолдыз сурәте төшерелгән кивердән торган. XVIII гасыр ахыры ■

Видеоязманың QR-коды

Рөстәм Шәфигуллин: «Бүрек татарны затлы итеп күрсәтергә тиеш!»

Татар бүреге ничек тегелә?
Әлеге сорауга җавапны Рөстәм Шәфигуллин остаханәсендә төшерелгән видеоязмадан таба аласыз.

– Рөстәм әфәнде, бүрек тегү һөнәренә кайда өйрәндегез?

– Әтием Казан шәһәрендә танылган сәгать төзәтү остасы иде. Әмма, үзгәртеп кору елларында, СССРда җитештерелә торган сәгатьләрне Кытайның электрон сәгатьләре алмаштырды. Шулай итеп, кешеләр, сәгатьләрне төзәттермичә,

яңаны сатып ала башлады. Әтием алдында: «Нәрсә эшләргә? Нинди хезмәткә керешергә?» – дигән сораулар туа. Гаиләне тәрбияләргә, тормышны алып барырга кирәк... Белгәнегезчә, татарлар кул кушырып утыра торган халык түгел! Әтием энесе белән үзлегеннән бүрек тегү кәсебен үзләштерде. 1990 нчы елларда мех фабрикалары акрынлап ябылды, шул ук вакытта милли әйберләр белән кызыксыну башланды. Ул заманда Татарстанда хәзерге кебек затлы каракүл мехлар юк иде әле. Әтием бүрекләрне байбак, су күсесе, төлке, хәтта бозау белән ат тиресеннән дә текте. Сирәк кенә нерпа, чәшке мехлары да була иде. Соңыннан чәшке бүрекләрнең модасы бетте. Әтием өйдә эшли иде. Шулай итеп, мин бу һөнәргә кечкенәдән өйрәнеп үстем һәм 16 яшемдә беренче бүрекне тектем. Һөнәри осталыкны арттыру өчен, әти мине Минскидагы остаханәгә җибәрде. Шунда бер ай цехта яшәп һәм эшләп, колакчын бүрекләр тегәргә өйрәндем. Бирердә бик тәҗрибәле, совет чорыннан ук эшләүче атаклы белгечләр бар иде. Казанга кайтып, тарих китапларын укый торгач, бүрекне, аеруча каракүл бүрекләрне борынгы бабаларыбыз яратып кигәнен белдем һәм әтиемнең эшен дәвам иттем.

– Тирене читтән кайтартасыз, бездә үрчетелә торган сарыкларныкы ярамыймы?

– Колакчын бүрекләр тегәр өчен бездә җитештерелгән тиреләр дә ярый. Әмма каракүл бүрек өчен өч айлык яшь бәрән тиреләрен Үзбәкстаннан һәм Молдовадан сатып алабыз. Шундый ук тиреләр Төньяк Кавказда да бар. Безнең якта үскән бәрән тиреләре гади бүрекләр өчен генә ярый, ә каракүл формалашсын өчен, аерым токым сарыклар һәм җылы климат кирәк. Салкын климатта тире калын була һәм ул нәфис бүрекләр өчен яраксыз. Яхшы, затлы, матур бүрекләр килеп чыксын өчен, мехның да өлгергән һәм сыйфатлы булуы мөһим. Тире начар булса – зур проблема. Шуңа күрә, аны үзебезгә барып карап алырга кирәк. Бер тире якынча 3 мең сум чамасы торса, аеруча затлы тиреләрнең бәясе 10 мең сумнан артып китә. Татарстанда иске туннардан да бүрек тегүчеләр бар, әмма миңа мехның яңа һәм яхшы сыйфатлы булуы шарт.

– Белүебезчә, калыпларны ясар өчен дә аерым талант кирәк...

– Калыплар – бүрек эшендә иң мөһим әйбер. Бүрекнең башка таман килүе өчен, калыплар төгәл эшләнгән булырга тиеш. Аларның күбесе миңа әтидән калды. «Бер калыпны ясар өчен бер атна чамасы вакыт үтә», – дип сөйли иде ул. Ул аларны үзе ясамады, ә махсус осталардан сатып алды. Күрүегезчә, алар тоташ бүрәнә түгел, ә бер-берсенә ябыштырып эшләнгән аерым такта кисәкләреннән гыйбарәт. Бүрек эше өчен кирәкле эш коралларының, кайчыларның, чүкечләрнең күбесе әтиемнән калды. Әти эшнең барлык этабын да диярлек кулдан башкара иде. Соңгы елларда заманча тегү машиналары сатып алдым. Хәзер исә бүрекнең почмакларын тегү эше генә кулдан башкарыла.

– Тире остаханәгә килеп кергәннән соң иң беренче эш нидән гыйбарәт?

– Иң әүвәл – сортларга аерабыз, папахага һәм колакчын бүреккә яраклы мехларны барлыйбыз. Эчке ягын эшләгәндә заманча синтепон материалларны файдаланам. Аларны Новосибирскидан махсус кайтартам. Формага китерер өчен элегрәк җилем файдаланылса, хәзер исә каты материалларны тиешле үлчәмгә туры китереп, катыргы ясыйбыз. Шуннан соң тегү процессы башлана.

– Сезнең бүрек башка төрки халыкларныкыннан нәрсәсе белән аерыла?

– Дагестанлыларның бүреге биек, ә татарныкы кәләпүш кебек тәбәнәк. Казакъларныкының өстендә бизәкле тукыма материал урын алса, безнеке тулысынча мехтан тегелә һәм җылырак.

«Рөстәм Шәфыйгулин
Татарстан

– Сатып алучыларыгыз кемнәр?

– Офицерлар, полковниклар «папаха» һәм «ушанка»ларны күпләп сорый. Алар, биегрәк итеп, калынрак тиредән эшләнә. Бүрекләрне әле яңа гына Новосибирскига җибәрдем. Кире кайтаручылар юк, яхшы фикерләр калдыралар, чөнки һәр бүрекне җиренә җиткереп, намус белән тегәм. Хәтта Казакъстаннан да заказлар була. Белгәнегезчә, бу һөнәр буенча аларның үзләрендә дә осталар җитәрлек, әмма алар безнекен югарырак бәяли.

Милли әйберләр, шул исәптән каракүл бүрекләр белән кызыксыну елдан-ел арта бара. Шагыйрь Ләбиб Леронга рәхмәт! Аның тырышлыгы белән, күп кенә татар зыялылары татар бүреге – каракүл бүрек кия башлады.

Татар конгрессы оештырган төрле күргәзмә һәм Сабан туйлары вакытында да сатып алучыларыбыз бар. Соңгы елларда бүрек тегү эшенә кайбер үзгәрешләр дә керттек. Әйтик, аеруча авыл бабайлары зиратта йөргәндә салкын була, дип, колакны каплый торган махсус тукыма белән тектерә башлады. Бүрекне әтиләргә, бабайларга бүләк итеп сатып алучыларның артуы бигрәк тә сөендерә. Каракүл бүрекләр яшь егетләрне затлы һәм эшлекле итеп күрсәтә. Шулай ук миллилекне, милли киемне, гореф-гадәтләрне саклау да мөһим.

Бүрек тегүне мин көндәлек эш буларак түгел, ә хобби, күңел тынычлыгы өчен кирәкле шөгыль буларак кабул итәм. Бу эштә ашыгырга кирәкми. Иң мөһиме – бүрекнең сыйфаты һәм матурлыгы. Бүрек татарны затлы итеп күрсәтергә тиеш!

Әңгәмәдәш – ***Ленар Гобәйдуллин*** ■

Бүрек тегү остасы Рөстәм Шәфигуллинга сорауларыгыз туса, шәхси аккаунтына керә аласыз.

Тимершаһ бай – татарның ит «короле», бозыклык белән көрәш һәм милли оркестр

تیمرشاه بن صلوات‌الله صالاۋیوف.

تیمرشاه افندی صالاۋیوف قزان غوبیرناسی زویه اویازی شوشیرمه‌قریه‌سنده ١٨٧٥ نچی‌یل مارط ١٩ نده دنیاغه کیلگان. ١٨٨١ نچی یلده مارط آینده قزان شهرینه کیله‌رك ١٨٨٢ سنه‌ده استاذ محترم داملا شهاب‌الدین المرجانی حضرتلرینك مدرسه‌سینه کروب درس باشلامش. مذکور مدرسه‌ده ١٠ یل علوم دینیه‌نی تحصیل صوڭنده ١٨٩٢ نچی سنه‌ده قزانسکی تاتارسکی اوچیتلسکی اشقولاغه کرمش. ١٨٩٦ نچی یلده مذکور اشقولانی بیوك مکافات ایله تمام ایدوب (کورص بتروب) چقمش صوڭره قزانده ٢ نچی غارا-دسکوی ناچالنی اوچیلشچه‌ده هم عثمانفسکی مدرسه‌نك روسسکی کلاصنده اوچیتل تعیین ایدیلوب خدمتنی گوزه‌ل صورتده ادا ایتمش.

١٨٩٨ نچی یلده خیراتی ایله مشهور وهمتلی بایلرمزدن مرحوم احمد بای حسینف‌نك قزانده‌غی باش کانتورینه کاسسیر (خزینه‌دار) بولوب کرمش وبر یل خدمت ایتدی. شول آز مدت اچنده بیوك خدمتلر کوستردیکی اوچون ١٨٩٩ نچی یلدن اعتباراً مدرسهٔ حسینیه‌نك وقف یورطلرینه مدیر تعیین ایتلمش ومکارجه یارمینکاسنده‌گی احمد باینك بارچه یورطلرن اداره قیلا باشلامش. اوستینه یوکله‌تلمش خدمتنی ١٩٠٥ نچی یلغه قدر قصورسز ادا ایتدی. اوشبو خدمتی دوامی اچنده ١٩٠١ نچی یلده مرحوم احمد باینك تقدیری ایله مرحوم‌نك اهلیه‌سی عائشه خانم یورطنده اوزندن مسلمانلرغه مخصوص آشخانه آچوب مکمل صورتده اوچ سنه دوام ایتدی. ١٩٠٢ نچی یلده مکارجه‌ده مشهور اورالسکی پادۋوریه‌ده زور خارچه‌ونه ونومیرلر آچوب ینه اوچ سنه یخشی آلوب باردی. ١٩٠٤ نچی یلده تیمرشاه افندی اوزی اداره قیلدیغی مرحوم احمد باینك وقف یورطینه کورشی، اوّلده روس قولنده برنچی درجه زور غاستینسه ومسکرات کبی بوزقلقلر اورنی اولان "دۋوخسۋیتنی غاستینسه" نی مرحوم احمد باینك پولنی وگلاۋنی اوپراۋلایوشچیی صابرجان افندی باکیرف ایله شریك اولاره‌ق آلوب غاستینسه‌نك اوّلگی بوزوقلقلرن تمام بتروب عموماً مسلمانلر آراسنده باشلاب برنچی مرتبه باشقه‌لرغه نمونه اولورلق یاوروپا اصولنده قوخنه‌لی هم تمامیله یاوروپا نومیرلرندن آیرغیسز مکمل بیوك بر مسافرخانه وغاستینسه وجودکه کیتردی. فوق العاده پاك وغایت ترتیبلی وزینتلی صورتده وحفظ صحت قاعده‌لرینه آیرم دقت ایده‌رك یولغه صالدی. ٤ یل قدر غاستینسه‌نی کمال ترتیب ایله آلوب کیلگاندن صوڭ هر ایکاوسینك کامل رضالغی

تیمرشاه بن صلوات‌الله صالاۋیوف.

Тимершаһ бине Салаватулла Соловьев

***Тимершаһ Саллави (Соловьев-Шушерминский,** 1875-1947), атаклы татар эшкуары булу өстенә, язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, «Госмания» һәм «Хөсәения» мәдрәсәләре мөгаллиме, Зариф Бәшириләр белән «Чүкеч» журналын, Хөсәен һәм Хәдичә Ямашевлар белән «Урал» газетасын чыгаручы шәхес тә була. Яшьлегендә Харис Фәйзи (композитор Җәүдәт Фәйзинең әтисе), Исхак Казаков (рәссам Хаҗиморат Казаковның әтисе), Сергей Ключаревлар белән бергә (композитор Александр Ключаревның әтисе) Әхмәд байга хезмәт итә. «Русия сәүдәсе» журналының 1912 елгы 1 нче санында (16-17 нче битләр) Тимершаһ бай хакында кызыклы гына мәкалә басылган. Аны сезнең игътибарга да тәкъдим итәбез.*

Тимершаһ бине Салаватулла Соловьев Казан губернасының Зөя өязендәге Шуширмә карьясендә 1875 ел март 19ында дөньяга килгән. 1881 елда март аенда Казан шәһәренә киләрәк, 1882 елда остаз мөхтәрәм дамелла Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең мәдрәсәсенә кереп дәрес башламыш. Мәзкүр мәдрәсәдә 10 ел голүме динияне тәхсил соңында, 1892 елда Казанский татарский учительский школага кермеш. 1896 елда мәзкүр школаны бөек мөкяфат *(бүләкләр)* илә тәмам итеп *(курс бетереп)*, чыкмыш соңра Казанда 2 нче Городской начальный училищеда

һәм Госмановский мәдрәсәнең русский классында учитель тәгаен ителеп, хезмәтне гүзәл сурәттә әда итмеш *(үтәде)*.

1898 елда хәйраты *(изге эшләре)* илә мәшһүр вә һиммәтле байларымыздан мәрхүм Әхмәт бай Хөсәеновның Казандагы баш кантурына кассир *(хәзинәдар)* булып кермеш вә бер ел хезмәт итмеш. Шул аз мөддәт *(вакыт)* эчендә бөек хезмәтләр күрсәттеге өчен, 1899 елдан игътибарән *(башлап)* мәдрәсәи Хөсәениянең вакыф йортларына мөдир тәгаен ителмеш *(билгеләнде)* вә Әхмәт байның Мәкәрҗә ярминкәсендәге барча йортларын идарә кыла башламыш.

Өстенә йөкләтелмеш хезмәтне 1905 елга кадәр косурсыз *(кимчелексез)* әда итте *(үтәде)*. Ошбу хезмәтне дәвамы эчендә 1901 елда мәрхүм Әхмәт байның тәкъдиме илә мәрхүмнең әһлиясе Гайшә ханым йортында үзеннән мөселманнарга махсус ашханә ачып, мөкәммәл сурәттә өч ел дәвам итте. 1902 елда Мәкәрҗәдә мәшһүр Орски подворьеда зур харчевня вә нумерлар ачып, янә өч ел яхшы алып барды. 1904 елда Тимершаһ әфәнде үзе идарә кылдыгы мәрхүм Әхмәт байның вакыф йортына күрше, әүвәлдә рус кулында беренче дәрәҗә зур гостиница вә мөскират *(исертә торган)* кеби бозыклыклар урыны булган «Двухсветный гостиница»ны мәрхүм Әхмәт байның полный вә главный управляющие Сабирҗан әфәнде Бакиров илә шәрик *(катнашучы)* уларак алып, гостиницаның әүвәлге бозыклыкларын тәмам бетереп, гомумән, мөселманнар арасында башлап беренче мәртәбә, башкаларга нәмунә улырлык Яуропа ысулында кухнялы һәм тәмам илә Яуропа нумерларыннан аергысыз мөкәммәл *(камил, җитеш)* бөек бер мөсафирханә вә гостиница вөҗүдкә *(барлыкка)* китерде. Фәүкылгадә *(гадәттән тыш)* пакь вә гаять тәртипле, вә зиннәтле сурәттә, вә хифзысыйххәт *(сәламәтлекне саклау)* кагыйдәләренә аерым дикъкать итәрәк юлга салды. Гостиницаны 4 ел кадәр кәмаль тәртип илә алып килгәннән соң һәр икәвесенең камил ризалыгы вә килешүләре илә, «Двухсветный гостиница» Тимершаһ әфәнденең кәнди *(үзенең)* кулына вә берүзенең милкенә күчте. Залына, беренче мәртәбә уларак, мөселман милли оркестры куйды. Шул көннән башлап Мәкәрҗәгә килмеш мөселман әһалисе, бозыклык урыннарына бармыйча, аяк-башлары илә хозур урында милли музыка оркестры төрле милли концертлар вә башка мөселманнарның мәшһүр җырчылары тарафыннан җырланмыш моңнарын тыңларга вә буш вакытларын хозур вә кәефле үткәрүгә муафыйк булдылар. Гостиницаның залы 500 кешелек улып, ярминкә вакытында бөтен тәүлек буенча сату итә, мөселман вә башка милләт сәүдәгәрләре илә һәрвакыт тулы улдыгы кеби, 50дән зиядә *(артык)* булган нумер-

Ярминкә мәчете язгы ташу вакытында

Мәкәрҗә ярминкәсе урыны язгы ташу вакытында

лары һәм дөньяның төрле тарафыннан җыелдыгы мөселман сәүдәгәрләре илә туптулыдыр.

Нинди генә улса да бер сәүдә кыла торган зат Мәкәрҗәдә берәр кеше илә күрешәсе яки сәүдә эше илә вә сөйләшәсе улса, дөньяның һәр әтрафыннан җыелдыгы сәүдә вә тиҗарәт сахипләрен *(сәүдәгәрләрне)* тиз вакыт эчендә фәкать «Двухсветный гостиница»да күрә алачак. Анда Сибириядән, Кавказдан, Кырымнан, Әфганстаннан, Иранан, Бохара вә Хивадан, Кытайдан вә башка чит мәмләкәтләрдән килгән сәүдәгәрләр, фабрикантлар, тиречеләр, мануфактурчылар вә башкалар һәрвакыт булып торадыр. Анда һәрвакыт тәҗрибәле поварлар кулында хәзерләнгән яхшы вә ләззәтле ашлар гаять нәфис сурәттә бик тиз бирелә вә башка соралган мәшруг *(шәригать кушкан)* нәрсәләрнең берсеннән дә туктатылмый әда ителә. Хезмәтчеләренең, хосусан *(аеруча)* официант вә швейцар вә рассыльныйларының пөхтә, чиста вә җитезлегенең ниһаять дәрәҗәдәлеген әйтми китү мөмкин түгелдер. Анда телефон, көтепханә, парикмахерлар, рассыльныйлар, модный тегүчеләр, газета-журналлар, нумерлар өчен ванналар вә башка уңайлылыкларга аеруча дикъкать ителгән. Зал, нумер вә башка урыннары һәммәсе электрик илә мөкәммәл яктыртыладыр. Һәр җәһәттән уңайлылыгы илә мәшһүр бу гостиницаның биржевой залында чиксез күп сәүдәгәрләр бер-берсен күреп эш кылалар.

Мәрхүм Әхмәт бай Хөсәенов җәнаплары вафат иткәннән соң, аның Нижнийда булган ит сәүдәсе Тимершаһ әфәнде кулына күчте. Андагы ит сәүдәләренең иң зурларыннан берсе – Тимершаһ әфәнденең ит сәүдәсе вә ит кибетләредер. 1910 елда Мәкәрҗә сәүдәгәрләре бертавыштан Тимершаһ әфәндене рядской староста сайладылар. 1911 елда ярмарочный уполномоченный *(гласный)* сайладылар.

Мәрхүм Әхмәт байның вафатыннан соң, бөтен Русия әһле ислам тиҗарләренең *(сәүдәгәрләренең)* карары илә, Мәкәрҗәдә ярмарочный мәсҗедкә попечитель сайланып, губернский правление вә губернатор хәзрәтләре тарафыннан утвердить ителде. Шул утверждениега мөбни *(нигезләнеп)*, мәсҗеднең хозяйственный эшләре вә мәрхүм Әхмәт байның вакыф эшләре Тимершаһ әфәнде Соловьев тәхет нәзаратындадыр *(идарәсендәдер)*.

Текстны басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *һәм* ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Мөхәммәтҗан Галиев һәм татарның бердәнбер читек фирмасы

مسلمانلر آراسنده چیتك، کاوش هم باش کییملری سوداسینك تاریخی.

محمدجان بنیامین اوغلی علییف ورثه‌لرینك فیرماسی.

اوقوچیلر تاریخدن بر آز خبردار بولسونلر اوچون بو اورنده مسلمانلر آراسنده آزیا فورماسی ایله چیتك کاوش اشله‌نه باشلاو طوغریسنده بر ایکی سوز سویله‌ب کیتونی معقول کوردك. قزانده آزیا آیاق کییملری حاضرله‌وده ایك زور شهرت کسب ایتکان فیرما، محمدجان بنیامین اوغلی علییفنك وآنك وفاتی صوڭنده آنك وارثلرینك‌در.

کیره‌ك علییف فیرماسینك اولسون کیره‌ك باشقه کشیلرنك اولسون آزیا آیاق کییملری حاضرله‌و اوچون مخصوص فابریك وزاڤودلری یوقدر. بونلرنك هرقایوسی‌ده ماتیریياللرنی هنر اییه‌لرینه حاضرله‌ب بیروب ایولرنده اشله‌ته‌لر. تیرینی ایله‌ولر، بویاولر، کیسولر، تگولر وآنلرنی چیگوار هر قایوسی ماستیرلر وماستریتسه‌لرنك ایولرنده اشله‌نه‌در. فیرمالر اوز ماستروسکویلرنده فقط کوننی کیسوب کنه بیره‌لر. آنلرنی چیگو اشلرن خاتونلر

بولماغان. اول زمانلرده قزانلیلر (حاضرگی کونده بوگادیلنیلرده‌گی قارتلر کیه طورغان باشماقلر ره‌وشنده‌گی) چارقلر کییوب یورگانلر.

بخار نمونه‌سی ایله اشله‌نه طورغان چیتکلر قرق یل قدر اوّلگی حالنده دوام ایتوب کیلگان. بونده هیچ بر تورلی‌ده اوزگارش فلان بولماغان، بیك ساده هم طوپاس ره‌وشده اشله‌نوب کیلگان. فقط ۱۸۳۰ نچی یللرده‌غنه بو بابده بر آز اوزگارشلر هم ترقی علامتلری کورینه باشلاغان. مذکور یللرده خاتون قز چیتکلرن بیزه‌و اوچون تورلی توسده‌گی ماموق جبلری ایله قایی باشلاغانلر. ٤٠ نچی یللرده تورلی توسده‌گی کونلردن بیزه‌کله‌ب اشله‌ب، یفه‌ك، کموش هم آلتون جبلر ایله قایی باشلاغانلر.

۱۸۵۹ نچی یلدن باشلاب مصطفی افندینك بار اشلری محمدجان افندی علییف قولینه کوچکان. اشنی اوز قولینه آلغاندن

عزیزجان علییف.

Мөхәммәтҗан байның лаеклы дәвамчысы Газизҗан Галиев

Мөхәммәтҗан Ибнеәмин улы Галиев *(1832-1908) – Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре, эшкуар, Казан мөселман хәйрия җәмгыятен оештыручыларның берсе, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә нигез салучы, атаклы татар муллалары Галимҗан Баруди, Салихҗан һәм Габдерахман Галиевларның әтисе.*

«Русия сәүдәсе» журналының 1912 елгы 1 нче санында Мөхәммәтҗан байның читек фирмасы турында кызыклы гына мәкалә басылып чыга. Бу вакытта аның эшен улы Газизҗан Галиев дәвам иткәне мәгълүм. Игътибарыгызга әлеге мәкаләне тәкъдим итәбез.

Укучылар тарихыннан хәбәрдар булсыннар өчен, бу урында мөселманнар арасында Азия формасы илә читек-кәвеш эшләнә башлау тугрысында бер-ике сүз сөйләп китүне мәгъкуль *(урынлы)* күрдек. Казанда Азия аяк киемнәре хәзерләүдә иң зур шөһрәт кәсеп иткән фирма Мөхәммәтҗан Ибнеәмин угылы Галиевныкы вә аның вафаты соңында аның варисларыныкыдыр.

Кирәк, Галиев фирмасының улсын, кирәк, башка кешеләрнең улсын, Азия аяк киемнәре хәзерләү өчен махсус фабрик-заводлары юктыр. Бунларның һәркаюсы

да материалларны һөнәр ияләренә хәзерләп биреп өйләрендә эшләтәләр. Тирене иләүләр, буяулар, кисүләр, тегүләр вә анларны чигүләр – һәркаюсы мастерлар вә мастерицаларның өйләрендә эшләнәдер. Фирмалар үз мастерскойларында фәкать күнне кисеп кенә бирәләр. Анларны чигү эшләрен хатыннар эшлиләр, аннан калганнарын, мәсәлән, тегү, киерү, табанча салу вә гайре эшләрне ир мастерлар эшлиләр.

Бу нәүгъ *(төр)* аяк киемнәренә азиатский исеме бирелү бунларның үрнәкләре иң әүвәл Азиядән китерелгәнлектәндер. 1790 нчы елларда Казанда мәшһүр җөрмукчылардан[1] Мостафа Фәйзуллин исемендә бер адәм үзенең бәгъзе бер йомышлары илә Оренбург губернасы Каргалы бистәсенә барган. Анда Азия ысулында Бохарада эшләнгән читек вә кәвешләрдән нәмунә өчен берәр данәсен сатып алып, Казанга китергән. Казанга кайткач, ошбу сатып алган читек вә кәвешләргә охшатып ир вә хатын-кыз читек вә кәвешләре эшләтә башлаган. Аңа ияреп башка кешеләр дә шуңа охшатып читекләр эшли башлаганнар. 1790 нчы елларга кадәр Казанда читек һәм кәвеш дигән нәрсәләр булмаган. Ул заманнарда казанлылар чарыклар[2] *(хәзерге көндә богодельнялардагы картлар кия торган башмаклар рәвешендәге)* киеп йөргәннәр.

Бохара нәмунәсе илә эшләнә торган читекләр кырык ел кадәр әүвәлге хәлендә дәвам итеп килгән. Бунда һичбер төрле дә үзгәреш-фәлән булмаган, бик садә *(гади)* һәм тупас рәвештә эшләнеп килгән. Фәкать 1830 нчы елларда гына бу бапта бераз үзгәрешләр һәм тәрәкъкый галәмәтләре күренә башлаган. Мәзкүр елларда хатын-кыз читекләрен бизәү өчен төрле төстәге мамык җепләре илә кайый башлаганнар. 1840 нчы елларда төрле төстәге күннәрдән бизәкләп эшләп, ефәк, көмеш һәм алтын җепләр илә кайый башлаганнар.

1859 елдан башлап Мостафа әфәнденең бар эшләре Мөхәммәтҗан әфәнде Галиев кулына күчкән. Эшне үз кулына алганнан соң, Мөхәммәтҗан әфәнде эшне юлга салу, яхшылату һәм халык каршында мәгъкулиятькә кертү өчен бик зур иҗтиһадлар кылган һәм аны бөтен Русия мөселманнары гыйндында *(каршында)* мәгъкулиятькә кертерлек дәрәҗәгә җиткергән. Ул бу бапта бик күп фикерләр сарыф итеп, бик матур аяк киемнәре, гаять дәрәҗәдә матур вә гүзәл ияр мендәрләре[3], мебель тышлыклары, Яуропа ысулында ир вә хатын-кыз туфлиләре вә гайреләр вөҗүдкә *(барлыкка)* китергән. Аның вөҗүдкә китергән нәрсәләре һәр җирдә хуш күрелгәнлектән, мөштәри (сатып алучы) вә талиплары арткан.

Мәзкүр фирмага эшләренең гүзәллеге өчен Русия вә заграница выставкаларында зур мөкяфәтләр *(бүләкләр)*, алтын-көмеш медальләр вә мәдехнамәләр *(мактау кәгазьләре)* бирелмештер.

Мөхәммәтҗан әфәнденең үзе сәламәт заманнарында ук 120 кадәр гаилә аңа хезмәт итеп, аяк киемнәре хәзерләү илә мәшгуль булганнар. Һөнәрмәндләрнең әксәре *(күпчелеге)* мөселманнардан гыйбарәттер. Бу фирмага эшләүче кешеләрнең бәгъзеләре – Казанда, бәгъзеләре – Казанга тоташ бистәләрдә, калганнары әтрафтагы карьяларда *(авылларда)* икамәт кылалар *(яшиләр)*. Шәһәр вә аңа тоташ бистәләрдә эшләүче мастер вә мастерицалар ел әйләнәсендә бер дә туктаусыз эшләрендә дәвам итәләр. Карьяларда исә беренче октябрьдән башлап апрельгә кадәр һәм эштән бушанган заманнарда эшлиләр. Аяк киемнәрен каючы һәм чигүче хатын-кызлар көненә 30 тиеннән башлап 80 тиенгә кадәр; тегүче, кисүче һәм табанча салучы мастерлар көненә 60 тиеннән бер сум егерме тиенгә кадәр *(соңгы еллар-*

[1] Җөрмук – шнур белән бәйләп киелә торган аяк киеме.
[2] Чарык – күн аслы, тула кунычлы аяк киеме.
[3] Ияр мендәре – ат яки ишәк сыртына атланып утырыр өчен махсус җайланма, япма, мендәр.

Казанда милли аяк киемнәре белән сәүдә итә торган кибет. XX гасыр башы

да артыграк) хезмәт хакы төшерә алалар. Соңра шуны да әйтеп китәргә кирәк, бу һөнәр эшче халык өчен шул җәһәттән дә файдалыдыр ки, аны эшләү өчен зур көч сарыф итү лазем *(кирәк)* түгелдер. Шул сәбәптән бу хезмәт илә йорт башы булган ата вә аналар мәшгуль булган шикелле, яңа үсеп килә торган яшьләр дә мәшгуль булып акча төшерә аладыр. Бу хезмәт гаилә әгъзаларын башка фабрикның эшләре шикелле йорт хезмәтеннән дә мәнгы кылмыйдыр *(туктатмый)*.

Азия аяк киемнәре өчен һәртөрле күннәр истигъмаль ителәдер *(кулланыла)*. Мәсәлән, табанча өчен үгез тиресеннән эшләнгән хлебный һәм болгар күннәре, йөзлек өчен рус, Ташкент һәм Персия кәҗәләре; рус, Урда бәрәннәре, шегрень, сәхтиян, лакланган рус, француз һәм америка күннәре, Ташкент вә Бохарада эшләнгән саурыйлар *(ат куне)* истигъмаль ителәдер. Шулай ук төрле башмак вә туфлиләр хәтфә, манчисәр *(манчестер – киҗе-мамык тукыманың бер төре)* вә атласлардан эшләнә. Җефәк, мамык һәм җитен җепләре, мишура һәм көмеш җепләр вә канительләр илә чигелә һәм каюладыр.

Азия аяк киемнәре хәзерләү өчен лазем булган матдәләрне мәзкүр фирма турыдан-туры беренче кулдан аладыр. Буннан ун-унбиш еллар мөкаддәмдә *(элек)* Русиядә малны үткәрү бик читен хәлгә калган иде. Шул вакытларда да гәрчә малны арзанга төшереп матди җәһәттән икътисад кылырга мөмкин булса да, Мөхәммәтҗан әфәнде, һичберсенә дә илтифат итмичә, эшне әүвәлге хәлендә дәвам иттерде. Ул вакытларда сәүдәсеннән файда күрә алмаганлыгын белсә дә, соңгы егерме биш ел эчендә фәкыйрь хезмәткәр вә эшчеләргә даим эш биреп, тамакларын туйдырып килде. Мәзкүр фирма 1859 елда башланмыш вә бу көнгә кадәр үзенең тәрәккыйендә дәвам итмәктәдер.

Мөхәммәтҗан әфәнденең вафатыннан соңра аның мәхдүмнәре эш башына кичеп, аталарының фирмасын дәвам иттерергә керештеләр. Мөхәммәтҗан әфәнденең угыллары мулла Галимҗан, Газизҗан *(мөдир)*, мулла Салихҗан һәм мулла Габдерахман тәҗрибә күргән, моктәдир *(көчле, сәләтле, бай)* адәмнәр булдыкларыннан, фирманың илле елдан бирле килгән игътибарын югалтмадылар. Бәлки, билгакес *(киресенчә)* иҗтиһад итеп, эшнең тәрәккыйе өчен тырыштылар. Хәзерге көндә бу фирма Казандагы читек-кәвеш фирмаларының беренчеләреннән хисап ителмәктәдер.

Фирманың баш сәүдәсе Казанда Общественный корпуста 35, 36 һәм 38 нче номерларда, шөгъбәләре *(бүлекләре)* Оренбург вилаяте Троицки шәһәрендә Бакировлар рәтендә һәм Уфада. Ярминкәләрдә: Нижний ярминкәсендә, мәсҗед каршысында, Эрбет һәм башка ярминкәләрдәдер.

Текстны басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *һәм* ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Тау ягы

Вячеслав Данилов, төбәк белгече

Хуҗа Хәсән урта мәктәбе укучылары «Татарстан Республикасының Тау ягы татар керәшеннәре музее»на килгән кунакларны каршы алган мизгел

Татарстан Республикасының Тау ягы... Илебезнең Тау ягы...

Бу сүзтезмә Бөек Идел Болгарстаны чорында ук татар кешесенең теленә кереп калган. Идел буенда урнашкан борынгы дәүләтебезнең чикләре, Ука һәм Сүрә елгаларыннан башлап Җигүле тауларына кадәр сузылган һәм, хәзерге Татарстан Республикасыннан тыш, үз эченә хәзерге Мордовиянең Көнчыгышы Чуашстан, Мари Иле, Нижгар, Ульяновск, Самара һәм Ырынбур (Оренбург) өлкәләренең бай-так җирләрен сыйдырган. Аның башкаласы – Болгар шәһәре – Иделнең сул ягын-да, Чулман елгасы тамагыннан бераз астарак урнашкан. Мәркәз тарафыннан ка-рап, Иделнең уң як ярын болгар-татарлар шул вакытлардан бирле үк Тау ягы дип атаган. Чыннан да, әлеге яр буе тулаем таулардан һәм калкулыклардан гыйбарәт.

Бөек Идел Болгарстаны ислам динен 922 елда рәсми рәвештә кабул итә һәм ул ислам дөньясының иң төньяк форпостына әйләнә. Болгар Иле Борынгы Киев дәүләте белән тыгыз дипломатик һәм сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштыра; 985 елда

ике арада дуслык, хезмәттәшлек һәм үзара ярдәмләшү турында килешү төзелә. «Безнең ошбу солых колмак батып, таш су өстенә йөзеп чыккан очракта гына бозылыр», – диелә анда.

Болгарлар – хәзерге татарларның ерак бабалары – Киев кенәзе Владимирны да ислам диненә күчәргә үгетли. Әмма славян халкының бәйрәм-мәҗлескә, «утлы су»га мөкиббән булуын истә тотып, кенәз әлеге тәкъдимнән баш тарта һәм нәсара динен 988 елда дәүләт дәрәҗәсендә кабул итә. Дөрес, бу хәл ике халык, ике ил арасындагы мөнәсәбәтләргә зыян-зәүрәт китерми.

1230 елда Җаек ярында Әфганстан, Фарсы Иле, Кафтаудан кайтышлый, Чыңгыз хан яугирләре тәүге мәртәбә болгарлар белән бәрелешә. Җиңелү белмәс гаскәр тар-мар ителеп, Бату хан болгарларның да шактый нык булуына инана һәм болар белән орышканчы яхшы ук әзерләнергә кирәклеген аңлый. Бату гаскәре, алты елдан соң кире кайтып, Идел Болгарстанын яулап ала. Соңрак бу җирләр Алтын Урдага кушыла. Әмма болгарлар яңа дәүләттә дә азмы-күпме автономиягә ирешә: әйтик, дошманнардан саклану өчен, аларга мөстәкыйль рәвештә хәрби операцияләр үткәрү хокукы бирелә. Киев дәүләте зәгыйфьләнеп, Тверь һәм Владимир кенәзлекләре нигезендә татарлар ярдәме белән оешкан Мәскәү шәһәре һәм Мәскәү дәүләте ныгый башлагач, Идел Болгарстаны белән мөнәсәбәтләр катлаулана. Мәскәү кенәзләре әледән-әле Болгарга һәм аның халкына каршы яу чаба. XIV гасырның икенче яртысында Алтын Урданың үзендә дә хәлләр мөшкелләнә. Хакимияткә килү өчен, туган-тумача, агай-эне канга-кан килешеп бетә. Бу чорда урыс кенәзләренең Болгарстанга бәреп керү очраклары бермәбер арта. Нәтиҗәдә, автономияле төбәкнең икътисады какшый. 1390 нчы елларда Аксак Тимер Алтын Урдага берничә мәртәбә һөҗүм итә, бик күп шәһәрләрне, шул исәптән илнең мәркәзе Сарайны да җимереп ташлый.

1392 елда исә Аксак Тимер Идел Болгарстанына каршы яу чаба, юл уңаенда очраган барча шәһәрләрне һәм авылларны җир белән тигезли, барча халыкны – хатын-кызларны, балаларны, карт-корыны аермыйча – кылычтан үткәрә. Шушы чорда борынгы бабаларыбыз – Тау ягы халкы – дошман чирүеннән качып, хәзерге Олы Чынлы, Олы Задорновка авылларыннан елганың аръягына – Болгарга юл тота. Соңрак, Аксак Тимер гаскәре анда да бәреп кергәч, алар Чулман буйлап Чистай тирәсенә күтәрелә һәм, елга аша Лаеш төбәгенә юнәлеп, яңадан Тау ягына (әмма яңа җирләргә) чыга.

Шул рәвешле, 1392-1400 нче елларда Хәсән, Мәлик, Корбанбаш (яисә Кырганбаш) бабайлар Хуҗа Хәсән, Мәлки, Иске Кырбаш (Түбән Кырбаш – Кырганбаш) авылларын нигезли. Корбанбаш үзе, күрәсең, монда тукталып калмый, ул, тагы да арырак китеп, Гөбенә елгасын кичеп, тагын бер Кырбаш исемле авылга нигез сала. Бераздан авылның монысын Иске Буа дип атый башлыйлар. Бирегә хәзерге Яшел Үзән төбәгендә ага торган Әрә елгасы буеннан (Әрә авылы тирәсеннән) килеп төпләнәләр, күрәсең. Мәскәү генеалогия лабораториясе 2018 елда уздырган тикшерену нәтиҗәләре шуны раслый.

Аксак Тимер көлгә әйләндергән җирләрдә бераздан Олуг Мөхәммәд хан Алтын Урдадан мөстәкыйль Казан дәүләтен оештыра. (Олуг Мөхәммәд – энесе Кече Мөхәммәд тарафыннан Сарай тәхетеннән куылган Алтын Урда ханы.)

Казан ханлыгы чорында да Иделнең уң яры Тау ягы дип аталуын дәвам итә. Бу төбәк тарихчылар, археологлар һәм башка галимнәр тарафыннан бөтенләй өйрәнелмәгән диярлек. Моннан югыйсә Кырым, Киев дәүләте, Урта Азия, Фарсы Иле, Әстерхан, Кафтау, Төркия якларыннан килүче дипломатик, хәрби һәм сәүдә

юллары узган. Мәскәү дәүләтенең аерым кенәзләре оештырган яулар, соңрак Степан Разин һәм Емельян Пугачев яулары да шушы туфрактан (җирләрдән) үткән. Бу якта бихисап сак постлары торган, калачык-кирмәннәр корылган. Әйтик, Гөбенә белән Зөя елгалары кушылган урында – хәзерге Кайбыч районының Шуширмә авылы янында – Япанчы шәһәрлеге булуы мәгълүм. Аннан бераз читтәрәк, хәзерге Яшел Үзән районында (Төньяк Норлат зонасы) фаҗигасе һәм каһарманлыгы белән дан тоткан Өтәк авылы урнашкан. Мәскәү һәм Казан гаскәрләре арасындагы төп бәрелешләр шушы урынга туры килгән.

Шунысын да искәртергә кирәк: Олуг Мөхәммәд хан гаять акыллы, төпле, гадел һәм киң күңелле илбашы була. Ул, кенәзнең хыянәтенә карамастан, Василий IIне әллә ничә тапкыр афәттән йолып кала. Олуг Мөхәммәд чорында ханлыкта урыс торaклары барлыкка килә, шул исәптән Зөя елгасы буенда Макарий монастыре төзелә. Аның кул астындагы Казан ханлыгы куәтле һәм гайрәтле дәүләткә әйләнә.

Шунысы да игътибарга лаек: Зөя Иделгә капма-каршы якка ага; бу җәһәттән аңа дөньяда тиңнәр юк, ул – кирегә ага торган бердәнбер кушылдык. Зөя шәһәрлеге 1551 елда нибары бер ай эчендә төзелә. Аңарчы кирмәннең диварлары, монастырьлар кыш буе (яшерен рәвештә) Углич урманнарында әзерләнә. Шунда беренче кат җыелгач, бүрәнәләргә номер сугыла, аннары аларны сүтеп, сал-сал итеп, Идел буйлап агызалар. Ул вакытта Зөя төзеләсе җирләр Казан ханлыгына керә әле. Шомлы хәбәр ирешүгә, Тау ягына караган 8 авылның гаярь егетләре, берләшеп, Зөя кирмәненә һөҗүм ясый. Әмма көчләр тигез булмый шул, урыс гаскәрләре аларны тар-мар итә.

1552 елның язында Мәскәү дәүләтенең Явыз Иван һәм урысларга сатылган татарларның Касыйм ханы Шаһ Гали җитәкчелегендәге төп көчләре Алатыр шәһәренә җитә, аннан туп-туры Яклы елгасына (хәзерге Сембер шәһәре янына) чыга. Шуннан соң әлеге гаскәр көн саен 25әр чакрым үтеп, әүвәл Чынлы, соңрак Карлы елгаларына якынлаша. Монда урыс гаскәре, күрше-тирә авыллары халкын да чакырып, зурлап мәҗлес оештыра: аларны үз ягына аударырга, Казанга каршы яу чабарга күндерергә тырыша. Бу вакытта берничә торак пункт (Зөягә һөҗүм иткән егетләрнең туган авыллары – хәзерге Башчы, Студенец, Кырык Садак һ.б.) чукындырыла да дигән мәгълүмат бар. Дөрес, аннары алар барысы да ислам диненә кире кайта.

Урыс гаскәре, ары таба Бола һәм Бия елгаларын кичеп, Өтәк авылы янында ыстан кора. Сугышчылар, бирeдә хәл җыйганнан соң, киңәш-табыш итешеп, Зөя каласына юл тота. Анда берничә көн булгач та, Казанга таба кузгалып, Андрей Курбский, Петр Серебряный, Бәхтияр Зәзуллин һәм башка воеводаларга кушылып, Казанны камауда катнаша.

Тарихи документлар да, тере туфрак та Явыз Иван узган урыннар турындагы хатирәне саклый. Бола һәм Бия елгалары буенда, Чәтбаш, Көлкәш, Кабык Күпере авыллары янында сынган ук, кылыч, көбә кисәкләре әле узган гасырның җитмешенче елларына кадәр табыла килде.

Чыганакларда урыс воеводаларының да, Казанны яклаучы каһарманнарның да исемнәре еш телгә алына. Мәсәлән, Атаклы Япанчы морза белән бергә баскыннарга каршы Тау ягы тумасы Хуҗа (урыс чыганакларында – Козья) би дә көрәшә. Билгеле, мондый материаллар җентекләп өйрәнүне сорый. «Кайбыч районының Хуҗа Хәсән авылын да нәкъ шушы Хуҗа би нигезләмәдеме икән?» – дигән фараз бар. Аның улы Күгеш, оныклары Күгәй, Айдар һәм Ислам Яшел Үзән районындагы шундый ук исемле авылларга нигез салган булырга мөмкин. Һәрхәлдә, зиратла-

Вячеслав Данилов музей экспозициясе белән таныштыра. (Экспонатларның кайберләрен шушы музейда гына очратырга мөмкин.)

рындагы кабер ташлары әлеге авылларның борынгылыгын дәлилли. Бабайларның сөйләвенчә, Күгеш авылы кешеләре Хуҗа Хәсән каберен зиярәт кылырга килеп йөри.

Мәскәүдән Польша-Литва илбасарлары куылып, тәхеткә Романовлар династиясе утыргач, урыс булмаган халыкларны чукындыру яңа көч ала. Шул максатны күздә тотып, 1731 елның 23 августында Зөядә «Яңа чукындыру канцеляриясе» оештырыла, соңрак ул «Яңа чукындыру конторасы» итеп үзгәртелә. Аның беренче җитәкчесе итеп Алексей Раифский билгеләнә. Әлеге конторага чиксез вәкаләтләр бирелә. Хуҗа Хәсән авылының ике кешесе Петр I патшага тылмач булып хезмәт итә, 1736 елда андый тылмачлар «Яңа чукындыру конторасы»нда да барлыкка килә. Императрица Анна Иоанновна 1740 елның 11 сентябрендә «Об отправлении архимандрита с некоторым числом священнослужителей в разные губернии для обучения новокрещеных христианскому закону и о преимуществах новообращенным дарованных» исемле Указны имзалый. Шул көннән алып, контораны аерата Аксак Каратун җитәкләгән чорда, Казан төбәгендә чукындыру эше коточкыч колач җәя. Кансыз дини сәясәт тантана иткән елларда, бу афәттән котылырга теләп, Тау ягы халкы, нигезе-йорты белән кубып, Зөядән арырак төбәкләргә күченү җаен карый. Чит-ят җирләргә урнашканда алар кендек каны тамган, җан җылысы сеңгән газиз авылларының исемен саклап калырга тырыша, нәтиҗәдә хәзерге Буа, Апас, Чуашстанның Ялчык һәм Батыр районнарында «иске» исемле яңа торак пунктлар барлыкка килә: Норлат (сүз уңаеннан, бу авыл 1961 елга кадәр район үзәге булып тора, нигезләүчесе – Норлат атлы кеше), Кайбыч, Яңа Чәчкап, Кырбаш, Хуҗа Хәсән – Күкшәм, Сориле, Бик-Үти һ.б. Бик күп татарлар Уралга һәм Уралның аръягына таба юнәлә.

1920 елда, Татарстан Республикасы оешканда, аның составына Тау ягының бик аз өлеше генә кертелә. Бүгенге көндә бу территория Яшел Үзән (Норлат зонасы), Югары Ослан, Кайбыч, Апас, Кама Тамагы, Тәтеш, Буа һәм Чүпрәле районнарын колачлый.

Татарстанның Тау ягы 10 000 квадрат километр мәйданга җәелгән, анда 265 000 кеше (бу – республикабыз халкының 12 проценты дигән сүз) яши. Монда зур шәһәрләр дә, индустриаль үзәкләр дә юк. Аңа да карамастан, безнең як илебезгә һәм милләтебезгә бихисап данлыклы уллар һәм кызлар биргән. Алар арасында Советлар Союзы, Россия һәм Татарстан министрлары, җәмәгать эшлеклеләре, әдипләр, композиторлар, галимнәр, архитекторлар, рәссамнар, җырчылар, гаскәриләр һ.б. бар. Кайбыч районының Хуҗа Хәсән авылында урнашкан «Татарстан Республикасының Тау ягы татар керәшеннәре музее»нда күренекле якташларыбыз турында бик күп мәгълүмат тупланган. Кайберләрен генә аерым атап үтик:

1) Кыям Абрамов (1897 елда Буа районының Иске Тинчәле авылында туган) – Татарстан Халык Комиссарлары Советы рәисе;

2) Петр Дементьев (1907 елда Чүпрәле районының Алешкин Саплык авылында туган) – СССР авиация сәнәгате министры;

3) Латыйф Хәмиди (1906 елда Кайбыч районының Ябалак авылында туган) – күренекле композитор, башка бик күп әсәрләр белән бергә, Казакъстан ССР Дәүләт гимны авторы да;

4) Капитонов Иван Калистратович (1965 елда Кайбыч районының Хуҗа Хәсән авылында туган) – Россия Федерациясенең атказанган рәссамы;

5) Каюм Насыйри (1825 елда Яшел Үзән районының Югары Шырдан авылында туган) – күренекле әдип, галим, мәгърифәтче;

6) Зариф Бәшири (1888 елда Кайбыч районының Чүти авылында туган) – әдип, педагог;

7) Гаврилов Филипп Гаврилович (1859 елда Кайбыч районының Хуҗа Хәсән авылында туган) – Түмер волосте старшинасы; татар керәшеннәре яшәгән 7 авылны Мәлки волостена берләштереп, 1920 елда Чуашстан составыннан Татарстанга күчерә.

Шулай ук бу төбәк әдипләр – Афзал Шамов, Шәүкәт Галиев, Ринат Харис, Юныс Сафиуллин, Рәдиф Сәгъди, Аманулла (Әмир Камалиев) һәм Фирдәвес Зарифның, актриса Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның, татарлардан беренче профессиональ режиссер, актер Газиз Айдарскийның (Сара Садыйкованың ире), күренекле галимнәр – Мөхәммәтхан Фазлуллин һәм Гомәр Саттаровның, композиторлар – Сара Садыйкова һәм Арыслан Батыршинның, артистлар – Фәхри Насретдинов, Рафаэль Ильясов, Фердинанд Сәлахов, Лена Бичарина һәм Лидия Әхмәтованың, Татарстанның халык артисты Рәшит Сабировның, композитор һәм җырчы Фирзәр Мортазинның, Коми Республикасының мәдәният министры Надежда Боброваның, атаклы ат карагы Шәкүр Рәхимовның һ.б.ның туган ягы да әле.

Кабатлап әйтәм: әлеге төбәкне яхшылап өйрәнәсе иде. Мәскәү-Пекин автомагистрален төзүчеләр әле күптән түгел очраклы рәвештә Аккуҗа һәм Мәми авыллары янында бик борынгы зиратка тап булды. Ни дигән сүз бу? Мондагы тарихи пласт бик тирәнгә китә, димәк. Аны өйрәнер өчен тиешле база да бар – Хуҗа Хәсән авылында эшләп килгән «Татарстан Республикасының Тау ягы татар керәшеннәре музее». Шушы йорт белгечләр белән тәэмин ителеп, аңа дәүләт музее яисә Татарстан милли музееның филиалы статусы бирелсә, бу мәсьәләдә эш шактый алга китә алыр иде. Тарихчыларга, археологларга һәм башка галимнәргә Тау ягын яхшылап өйрәнер өчен әйбәт мәйданчык булыр иде ул.

Ахыр чиктә Мәдәният министрлыгы да, Татарстан Президенты исеменә музейга рәсми статус бирүне сорап хат язган 36 галим, әдип һәм башка мәртәбәле затларның җан авазына колак салыр, безнең фикердәшебезгә, теләктәшебезгә әйләнер дип ышанасы килә. ■

Мәүла Колый: өйрәнелү тарихы һәм иҗаты турында кайбер фикерләр

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы



I

Бу исем татарча белгән, укыган, аеруча татар мәктәбендә белем алган күпчелек милләттәшләребезгә билгеле бер дәрәҗәдә таныш. Инде соңгы йөз еллап вакыт эчендә аның әсәрләре дәреслек-хрестоматияләрдә, антология-энциклопедияләрдә, газета-журналларда, җыентыкларда басылып килә. Аерым китаплары да бар. Академик хезмәтләрдә, әдәбият тарихы китапларында бу затның әдәби иҗаты хакында саллы гына язмалар да дөнья күргән.

Мәүла Колый «хикмәтләре» (ул үз шигырьләрен, нигездә, шул исем белән атый) шагыйрь яшәгән һәм иҗат иткән 17 нче йөздә дә, аннан соң да халыкта шактый киң таралыш таба. Аларның төрле төбәкләрдә, төрле елларда күчерелгән кульъязмалары еш табылып торуы әнә шул хакта сөйли. Әмма, элеккеге дәверләрнең шактый гына каләм әһелләре кебек, аның исеме, эшчәнлеге дә фәнгә соңрак кына мәгълүм булды. Шагыйрь хакында матбугатта тәүге мәгълүматлар, нигездә, узган гасырның 20 нче елларында дөнья күрде. Әлмәт-Бөгелмә төбәкләрендәге атаклы Туйкиннар нәселенең күренекле бер вәкиле, әдип, галим Фазыл Туйкә (1887-1938) 1925 елда Зәй-Каратай авылында гомер кичерүче Гайшә Мөхәммәдиеваның шәхси китапханәсендә Мәүла Колыйның бер җыентыгына тап була. Шагыйрьнең 97 шигырен (хикмәтен) туплаган, 1855 нче елларда күчерелгән бу кульъязма Гайшә ханымга Әлмәт районының Сөләй авылында яшәгән әтисе Мөхәммәди Вилдан угылыннан күчкән була. Фазыл Туйкә үзенең мөһим табышы турында «Кызыл Татарстан» газетасында (6.04.1926) һәм «Безнең юл» журналында (1928. – №9) язмаларын да бастыра, Мәүла Колый җыентыгының күчермәсен Казандагы Гыйльми Үзәккә дә җибәрә. Шуның нигезендә күренекле галим Габдерахман Сәгъди «Вестник научного общества татароведения» (1927, июль) һәм «Мәгариф» (1927. – №4) журналларында үзенең язмаларын бастыра, шагыйрьнең аерым хикмәтләрен дә (880 шигъри юлын) укучыларга тәкъдим итә.

Алга таба Мәүла Колый әсәрләренең башка күчермәләре дә гыйльми әйләнешкә кертелә башлый. Мәсәлән, 50 нче еллар ахырында Шакир Абилов Ленинградтагы Көнчыгышны өйрәнү институты фондында шагыйрьнең берничә хикмәтенә тап була. 1974 елда Башкортстанның Бакалы районындагы Камай авылында яшәүче милләттәшебез Зөһрә Галләмова Уфа галимнәренә Мәүла Колыйның чагыштырмача тулы кульъязма җыентыгын тапшыра. Анда шагыйрьнең 74 хикмәте теркәлгән. Фәндә «Камай нөсхәсе» дип йөртелгән бу мәҗмуга хакында Гайсә Хөсәенов язмалары да бар [3:5].

Шунысын да әйтик: галимнәр Мәүла Колый әсәрләренең автографлары, ягъни шагыйрьнең үз кулы белән язылган нөсхәләре барлыгын искәртмиләр. Мәгълүм ки, күчерү барышында кайвакыт төп текстка теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрешләр, өстәмәләр дә кертелә. Аерым очракларда авторның әсәрләренә, җыентыгына икенчеләренең әсәрләре дә кертеп җибәрелә. Бу хәл Мәүла Колыйга мөнәсәбәтле язмаларда да күзгә ташлана. Моның аерым мисалларын Раиф Мәрданов үзенең «Мәүла Колый иҗатыннан» исемле язмасында шактый гына факт-мәгълүматлар нигезендә яктырта [1: 53-59]. Янә шунысын да искә төшерик: бу галимебез XVII гасыр шагыйренең моңа кадәр фәнгә бөтенләй билгеле булмаган лиро-эпик характердагы ике әсәрен үзенең туган төбәгендә – Әгерҗе районының Яңа Акхуҗа авылында табып, «Казан утлары» битләре аша (1996. – №10. – 159-171 б.) киң катлам укучыларга ирештерде. Алар «Береккәннәр сыйфаты» һәм «Хәләл нәфъка (ризык. – Х.М.) эстәгәннәр сыйфаты» дип исемләнгән.

Мәүла Колый әсәрләре, гомумән, Урта гасыр сүз сәнгатенә хас булган динисуфыйчылык рухы белән сугарылган. Бу төр әдәбият исә Совет чорында, аеруча атеизмга өстенлек бирелгән 20-40 нчы елларда хупланмады. Шул сәбәпле Мәүла Колый хикмәтләренә дә тәнкыйди караш яшәде. «Шәхес культы» фаш ителгәннән соң, аеруча «Хрущев җепшеклеге» чорында элеккеге мираска, шул исәптән хикмәтләр авторына да игътибар артты. Узган гасыр урталарында дөнья күргән «Татар поэзиясе антологиясе»нең татарча һәм урысча басмаларында Мәүла Колыйга шактый урын бирелә. 1963 елда нәшер ителгән «Борынгы татар әдәбияты»

китабында Хәй Хисмәтуллин тарафыннан язылган бүлектә шагыйрь хакында мөһим генә факт-мәгълүматлар китерелә, күзәтүләр бәян ителә, 16 хикмәте дә урнаштырыла [2: 480-503].

Узган гасырның урталарында һәм икенче яртысында Мәүла Колый мирасын өйрәнүгә Шакир ага Абилов та сизелерлек өлеш кертте. Аның, мәсәлән, 1958 елда «Совет әдәбияты» журналының 11 нче санында басылган «Шагыйрьнең исеме Мәүла Колыймы, әллә Меллаголмы?» исемле язмасы җәмәгатьчелек тарафыннан зур кызыксыну белән кабул ителгән иде. «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томындагы (1984) «Мәүла Колый иҗаты» турындагы бүлекнең дә төп өлеше Шакир ага тарафыннан язылган [3: 366-380].

2001 елда Мәсгуд Гайнетдинов «Иман» нәшриятында Мәүла Колыйның 97 хикмәтен бастырып чыгарды [3]. Кереш мәкаләдә (3-11 б.) шагыйрь хакында җитди һәм мөһим фикерләр әйтелә. М.Гайнетдинов Мәүла Колый иҗатын югары бәяли, аны татар әдәбияты тарихының «терәк баганаларыннан берсе» дип атый (5 б.).

Шагыйрьнең иҗат мирасын барлауда, текстологик һәм, гомумән, гыйльми өйрәнүдә Раиф Мәрдановның эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Аның, мәсәлән, «Мәүла Колый поэмалары…» дип исемләнгән китабы [5] үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Мәүла Колыйны гыйльми тикшеренүчеләр арасында Чистай егете Камил Дәүләтшин (1935-2013), әлбәттә, төп урынны били. Әүвәл Казанда укыган, эшләгән, 1972 елдан гомеренең ахырына кадәр Башкорт университетында татар әдәбиятын укыткан бу мөхтәрәм затның эшчәнлеге өчен комплекслылык хас. Ул Мәүла Колый иҗатын һәм текстологик, һәм идея-эстетик, һәм методик яктан өйрәнде, аның иҗат мирасын пропагандалауга зур өлеш кертте. Камил Дәүләтшинның Хатип ага Госман җитәкчелегендә язылып, 1971 нче елда якланган «17 нче йөз шагыйре Мәүла Колый иҗаты» дигән кандидатлык диссертациясе [6] фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан бик тә уңай кабул ителгән иде. Алга таба К.Дәүләтшин Мәүла Колый буенча күпсанлы гыйльми-методик мәкаләләр, хезмәтләр бастырды, шагыйрь әсәрләрен гавамга җиткерүдә нәтиҗәле эшләде. Мәсәлән, «Мирас» журналының 2001-2002 нче еллардагы дистәләгән санында (№5, 6, 7, 8, 9, 11) Мәүла Колый хикмәтләре нәшер ителә.

Алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томындагы Мәүла Колый турындагы бүлекнең бер өлеше [3: 280-285], ә инде 8 томлыкның икенче җилдендәге [7: 241-266] шагыйрь хакындагы тулы бүлек К.Дәүләтшин тарафыннан язылган. Ул Мәүла Колыйның иҗат мирасын урыс телле укучыларга җиткерү юнәлешендә дә уңышлы гына эш-гамәлләр кылды. Мәсәлән, «Средневековая татарская литература (VIII-XVIII вв.)» хезмәтенең «Мәүла Колый» бүлеге аның тарафыннан язылган [8: 163-176].

К.Дәүләтшин гомеренең ахыргы елларында Уфада «XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый» исемле китап әзерләп бастырды (2010. – 400 б.). «Уку кулланмасы» дип тәкъдим ителгән бу җыентык галимнең озак еллар буе алып барган эш-гамәлләренең үзенә күрә бер җыйнама хисабы кебек тә кабул ителә. Китапның тәүге бүлегендә шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты шактый тулы яктыртыла. Анда Мәүла Колыйны өйрәнүдәге соңгы яңалыклар да искә алына. Шагыйрьнең татар әдәбиятында тоткан урыны, традицияләре дә читләтеп үтелми. 46-209 битләрдә хәзерге татар язуында Мәүла Колыйның 104 хикмәте тиешле сүзлек-аңлатмалар белән укучыларга тәкъдим ителгән. Җыентыкта шулай ук Мәүла

Колыйның Раиф Мәрданов тапкан ике поэмасы да урнаштырылган (202-228 б.). Китапның бер бүлегендә «Мәүла Колый хикмәтләренең поэтикасы һәм тел үзенчәлекләре» яктыртыла (229-240 б.) Монография авторы «Сүзлек» бүлегендә шагыйрь әсәрләрендә очраган авыр аңлаешлы сүзләргә аңлатмалар да бирә. «Кулланылган әдәбият исемлеге» дә шактый бай һәм файдалы. 2010 елда дөнья күргән бу китапның янә бик тә мөһим бер өлеше бар. Анда «Мәүла Колыйның Зәй-Каратайда табылган һәм Камай (Бакалы районы. – Х.М.) авылыннан алынган кулъязма җыентыкларда тупланган хикмәтләр факсимилесе» бирелгән. Гарәп язулы бу кулъязма текстларның копия-күчермәсе китапның 295-398 нче битләрен алып тора. Кыскасы, 2010 елгы Уфа җыентыгы, бер яктан, Мәүла Колый иҗатын өйрәнүнең шактый тулы, җыйнама бер хезмәте булса, икенче яктан, шагыйрь әсәрләренең чагыштырмача тулы бер басмасы да. Мәүла Колый мирасын тулырак белергә, тирәнрәк өйрәнергә теләгән һәр каләм әһеленә бу китап белән танышу, һичшиксез, зарури. Кызганыч ки, ул 100 данәдә генә нәшер ителгән. Аны Казанда кабат бастыру соралып тора.

***

Бу юлларның авторы да инде озак еллар буе Мәүла Колый иҗатын өйрәнүдә, пропагандалауда даими катнашып килә. Мәгълүм ки, без фәкыйрегез инде ярты гасырдан артык Казан университетында «Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбияты» курсын укытып килә. Билгеле булганча, вуз мөгаллиме, фәндә тупланган факт-мәгълүматларны, казанышларны студентларга җиткерү белән бергә, үзе дә үз курсы буенча теге яки бу дәрәҗәдә гыйльми күзәтүләр, тикшерүләр алып бара. Без дә нәкъ шул рухта эш иттек. Мәүла Колый турындагы белгәннәребезне, фикер-күзәтүләребезне студентларга, укытучыларга, киң җәмәгатьчелеккә җиткереп бардык. Шунысы мөһим: безнең күп кенә уй-фикерләребез публика тарафыннан хуплау тапты. бу тармакта эшләүчеләр тарафыннан кабул да ителде, үзләштерелде. Мәүла Колыйга мөнәсәбәтле дистәләгән курс, диплом эшләре дә яздырылды; төрле конференция-семинарларда доклад-чыгышлар ясавымны да хәтерлим. Ни үкенеч, шагыйрь турындагы фикер-күзәтүләребезнең төп өлеше кәгазьгә төшерелмичә калган. Шулай да азрак булса да кайбер күзәтү-язмалар да бар. Алар, нигездә, безнең аерым монографияләрдә [«Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур» (К., 2014), «Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей» (К., 2017)] һәм кайбер башка хезмәтләрдә очрый. Бу урында «Татар энциклопедиясе»нең һәм русча, һәм татарча басмаларында Мәүла Колый хакындагы күләмле генә мәкаләнең дә безнең тарафтан язылуын [10: 6-7; 11: 102-103] искә төшерү дә гөнаһ булмастыр.

Билгеле булгача, совет чоры мәктәпләрендә Борынгы һәм Урта гасырлар чоры татар әдәбияты, шул исәптән Мәүла Колый иҗаты да юньләп өйрәнелмәде. СССР таркалгач, үзгәртеп корулар, милли хәрәкәт дулкынында элекке рухи мирас белән кызыксыну гаять көчәйде. Шул объектив ихтыяҗны күздә тотып, татар әдәбиятыннан яңа программалар төзелде, бөтенләй яңа рухтагы дәреслекләр язылды. Югары сыйныфларда әдәбият тарихы курсында безнең элеккеге сүз сәнгатенә зур урын бирелде, мәктәпләрдәге әдәбият курсы шактый күләмдә әдәбият тарихының гыйльми дәрәҗәсенә якынайды. Татар мәктәпләренең, гимназияләренең IX сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педучилищелар, лицей-көллиятләр өчен дәреслек язу һәм хрестоматия төзү Ш.Садретдинов белән без фәкыйрегезгә йөкләнде. Аларның XIX гасырга кадәрге өлеше Хатыйп Йосыф

угылы тарафыннан әзерләнде. Бу дәреслек һәм хрестоматияләрнең беренче басмалары 1994, 1995 нче елларда дөнья күргән иде. Алдагы елларда алар 30ар, 35әр мең тираж белән күп мәртәбәләр кат-кат басылды [12: 183-191; 13:136-143]. Хрестоматиядә Мәүла Колыйның 7 хикмәте, «Береккәннәр сыйфаты» поэмасыннан өзек тә урнаштырылган. Дәреслектә шагыйрьнең тормыш юлы, иҗат мирасы, әсәрләренең идея-эстетик, жанр үзенчәлекләре бәян ителә. Биредәге текст дәреслек авторының Мәүла Колый хакындагы күзаллауларын, шәхси уй-фикерләрен чагыштырмача тулы яктырта. Гавамга да шагыйрь күбрәк дәреслектәге шушы текст аша таныш. 2021 елның 9 декабрендә Питрәчтә төбәкне өйрәнүчеләрнең Мәүла Колыйга багышланган фәнни-гамәли конференциясе булган иде. Андагы күп кенә доклад-чыгышларның нигезендә дәреслектәге, «Татар энциклопедиясе»ндәге шагыйрь хакында язмаларның ятуы күзгә ташланды.

Рус мәктәбенең 10 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен Х.Й.Миңнегулов һәм Н.С.Гыймадиева тарафыннан язылган дәреслек-хрестоматиядә дә [14: 93-97] Мәүла Колый иҗатына, әсәрләренә урын бирелә. Аның тәүге басмасы 1996 елда дөнья күргән иде. Шуннан соңгы вакыт аралыгында ул зур тиражлар белән күп тапкырлар нәшер ителде.

II

Моңа кадәрге бүлекчәдә без, нигездә, Мәүла Колыйның өйрәнелү тарихы хакында кыскача гына сүз йөрттек. Алга таба инде шагыйрь әсәрләренең эчтәлеге, идея-сәнгати, тел-стиль үзенчәлекләре, жанр табигатьләре хакында фикер йөртү соралып тора. Әмма без аңлы рәвештә әлеге табигый мантыйкны сакламаска булдык. Ни өчен? Чөнки бу мәсьәләләр әдәбият тарихының академик басмаларында, без язган дәреслек-хрестоматияләрдә шактый тулы яктыртыла. Әлеге төр басмаларны табып уку һич тә кыенлык сорамый. Шуңа күрә без язмабызның бу өлешендә шагыйрь хакында кайбер фикер-күзәтүләрне бәян итү белән генә чикләнергә уйлыйбыз.

Элеккеге дәверләрнең күп кенә каләм әһелләре кебек, Мәүла Колыйның тәрҗемәи хәле турында да махсус язмалар юк дәрәҗәсендә. Төп чыганак – шагыйрьнең үз әсәрләре. Ни аяныч, без хәзергә Мәүла Колыйның хәтта тугануылгән елларын да белмибез. Шагыйрь шул чорның күренекле шәхесе «Мелла Мамай»ны үзенең остазы дип саный, аны зурлап махсус хикмәт тә иҗат итә [9: 31-53]. Мәгълүм ки, бу зат – Казан төбәге кешесе. Автор аның «хаҗ йулында» вафат булуын да искә төшерә.

Шагыйрь алга таба кайларда яшәгән соң? Бер хикмәтендә аның мондый юллары бар:

...Мөхиб (якын. – Х.М.) дуслар, бу хикмәтне әймеш көндә
Сиксән сигез ирде тарих ул көн мең дә.
Әйтелде Шәһри Болгар кәндләрендә,
Гасый (гөнаһлы. – Х.М.), җаһи Мәүла Колый сүзли, дуслар [9: 53].

Бу уңайдан бер вакыйга да искә төшә. Узган гасырның 90 нчы елларында Венера Алтынбаева исемле журналист «Татарстан» радиосыннан урыс телендә күренекле шәхесләргә багышланган «Минувшего неугасимый свет» исемле тапшырулар циклы алып бара иде. Миңа да дистәдән артык андый тапшыруларда катнашырга туры килде. Шуларның берсе Мәүла Колыйга багышланган

Х.Миңнегулов үзенең элеккеге студентлары белән.
Питрәч. 9 декабрь, 2021 ел

иде. Мин ярты сәгатьләп бу шагыйрь хакында сөйләдем. Артистлар аның аерым шигырьләрен дә укыды. Икенче көнне өйдә телефон шалтырый. Трубканы алам. «Мин, – ди шалтыратучы,– Әкъдәс абыең Борһанов. Кичәге тапшыруны тыңладым. Бик әйбәт булды. Бу уңайдан бер мәгълүматны да җиткерәм: Мәүла Колый – минем ерак бабаларымның берсе». Мин бу хакта белми идем. Мәгълүм ки, Әкъдәс Борһанов (1920-2018) – чыгышы белән Лениногорск районының Сарабиккол авылы кешесе, тарих фәннәре докторы, профессор, күренекле зат [Питрәчтәге конференциядә аның кызы, социология фәннәре докторы Лариса Борһанова да онлайн форматта чыгыш ясады. (Бәлкем, бу гаиләдә ерак бабалары Мәүла Колый хакында хәзерге фәнгә билгесез факт-мәгълүматлар, материаллар бардыр?]

Билгеле булганча, шагыйрь яшәгән еллар – халкыбыз тарихының гаять авыр, катлаулы, фаҗигале дәвере. Күп гасырлар буе дәүләтләр тоткан татар кавеме үзенең бәйсезлеген югалта, колониаль изелүгә, көчләп чукындырылуларга дучар ителә. Баш күтәрүләрнең һәммәсе рәхимсез бастырыла. Әби-бабаларыбызның байтак өлеше яшәгән җирләреннән күчеп-качып китәргә мәҗбүр ителә. Мәчет-мәдрәсәләр җимерелә, матди һәм мәдәни байлыклар талана, юк ителә. Иҗат әһелләренең зур өлеше кырыла, качып-посып яшәргә мәҗбүр була. Мәүла Колый нәкъ әнә шундый шартларда гомер кичерә, аңа күп мәртәбәләр күченергә, төрле җирләрдә яшәргә туры килә. Күп кенә зыялылар кебек, аның да төп таянычы – ислам дине, халкының теле, гореф-гадәтләре, рухи байлыгы.

Совет чорында, шул чор идеологиясенә нисбәтән, Мәүла Колый хикмәтләрендәге дини-суфыйчылык идеяләре еш кына тәнкыйтьләнде, шагыйрь иҗатында дөньяви мотивларны эзләү, күпертү тенденциоз төс алды. Әйтерсең, дини суфыйчылык кешеләр өчен тәмам дошман, зарарлы. Чынлыкта исә бу төр карашлар, идеяләр шул чор яшәеше, рухы белән табигый керешкән, дөньявилыкны, динилекне бер-берсеннән аеру мөмкин дә түгел.

Мәүла Колый шул кыен чорларда адәм балалары, аларның рухлары турында кайгырта, кешеләрне битарафлыктан, ваемсызлыктан, өметсезлектән арындырырга, аларга яшәү өмете, дәрте бирергә омтыла. Аның хикмәтләре яшәешнең тулы бер кодексы кебек. Автор адәм балаларының тереклеге, асыл табигате өчен хас-зарури булган төп төшенчәләрне хикмәтләренең үзәге, «арка сөяге» итә. Болар гаҗәеп күптөрле: белем-мәгърифәтле, һөнәрле булу, түземлелек, ата-ананы хөрмәт итү, кечеләргә, авыр хәлдә калучыларга ярдәм күрсәтү, иманга тугрылык, ихласлылык, сабырлык, шәфкатьлелек, юмартлык h.б. Автор яшәешнең бу төр асыл төшенчәләрен үз укучыларына, тыңлаучыларына ныграк җиткерү, күңелләренә сеңдерү өчен еш кына капма-каршы куе, антитеза алымын бик теләп куллана. Шагыйрь эчүчелекне, зина кылуны, монафикълыкны, хәрам мал җанлылыкны, комсызлыкны… кискен тәнкыйтьли. Ул үзе яктырткан, язган төшенчәләрне күңел казанында кайнатып, бәгыре аша уздырып, үз шәхесенә бәйләп бирә. Мәүла Колый еш кына үз хикмәтләрен үз-үзенә дәшү белән төгәлли. Урта гасырның күп кенә шагыйрьләре кебек, тәрбияне үзеңнән башларга, күңелеңне пакьләргә, кылган гөнаһларыңнан тәүбә кылырга чакыра.

Халкыбыз элек-электән үк күбрәк утрак тормышта яшәгән, игенчелек аның төп кәсебе булган. Бу хакта Мәүла Колыйның бик тә тирән мәгънәле хикмәте дә бар. Анда игенчелекнең «хуш һөнәр», «галәмара изге атлы», «бөек эш» булуы искәртелә. Аның фикеренчә, иген иккән кешенең урыны җәннәттә.

Автор колониаль изелү шартларында тәмам юкка чыга башлаган рухи кыйммәтләрне саклап калырга, аларны чордашларына, киләчәк буыннарга тапшырырга омтыла, татар язма телен гавамга аңлаешлы, үтемле итүдә дә уңышлы адымнар ясый.

Мәгълүм ки, Борынгы һәм Урта гасыр әдәбияты, гомумән, синкретик характерда. Каләм әһелләре, саф сәнгати, эстетик максатлар белән бергә, чорның, яшәешнең фәлсәфи асылы, фәне, мәгърифәт-мәдәнияте турында да фикерләрен бәян итәргә омтылалар. Бу сыйфат Мәүла Колый хикмәтләре өчен дә хас. Ул кешенең каршылылыклы табигатен борынгы заманнардан ук яшәп килүче дүрт элементтан – ут, су, һава, туфрак берлегеннән торган тәгълимат нигезендә аңлата. Мәүла Колый хикмәтләрендә кеше һәм табигать берлеге, вакыт агышы, үлемнең котылгысызлыгы h.б. мәсьәләләр турында да мөһим генә күзәтү-фикерләр бар.

Автор үзенең күпчелек шигырьләрен юкка гына хикмәт дип атамаган. Чыннан да, аның язмалары тирән мәгънәле, афористик яңгырашлы, серле-хикмәтле хәзинә кебек.

***

Мәүла Колыйның тырышлыгы, иҗади эшчәнлеге нәтиҗәсендә безнең күп кенә рухи кыйммәтләребез саклап калына, баетыла һәм алдагы буыннарга тапшырыла. Аның традицияләре алга таба Габди, Габдерәхим Утыз Имәни, Таҗеддин Ялчыгол, Шәмседдин Зәки һәм башка бик күп әдипләребез тарафыннан дәвам иттерелә, үстерелә. Мәүла Колыйның хикмәт-поэмалары караңгы, авыр елларны балкытып тора. Аларда бүгенге көнебезгә, яшәешебезгә дә аваздаш яклар, гыйбрәтле мисаллар шактый күп.

Әйткәнебезчә, 2021 елның 9 декабрендә Питрәчтә Татарстан Фәннәр академиясе, Бөтендөнья татар конгрессы, Питрәч район хакимияте… тарафыннан оештырылган фәнни-гамәли конференциянең үзәгендә Мәүла Колый шәхесе, иҗаты проблемалары торды. Анда Татарстанның төрле район-шәһәрләреннән, Казаннан

галимнәр, җирле төбәкне өйрәнүчеләр, укытучылар, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты. Катнашучылар арасында «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Шамил Садыйков, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, билгеле тарихчылар Нурулла Гариф, Марсель Гарипов һәм башкалар бар иде. «Татарстан төбәкне өйрәнү җәмгыяте» рәисе Альберт Борһанов бу чараны үткәрүдә башлап йөрүче, хакимият башлыгы Илһам Кашапов командасы белән берлектә төп оештыручы булды. Конференциядә Хатыйп Йосыф угылы да катнашты, пленар һәм секция утырышларында доклад-чыгышлар ясады. 2022 елның апрелендә Питрәчтә Мәүла Колыйга багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясен уздыру планлаштырыла. 9 декабрьдәге чара алдагы конференциягә үзенә күрә бер җитди хәзерлек гамәле дә булды. Питрәчлеләр үз якташлары Мәүла Колыйны яхшылап өйрәнергә, аның исемен мәңгеләштерергә, әсәрләрен пропагандаларга ашкынып торалар. (Бәлкем, Питрәч хакимияте шагыйрь әсәрләренең тулы җыентыгын бастырып таратуны да үз өстенә алыр?!) Уңышлар телик үзләренә!

Файдаланылган әдәбият

1. «Татар археографиясе» сериясе: 27 нче китап. Шигъри ядкярләр / Төзүчесе – Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – 252 б.

2. Борынгы татар әдәбияты. – Казан, 1963. – 581 б.

3. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. I том. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1984. – 567 б.

4. Мәүла Колый. Хикмәтләр / Төзүчесе – Мәсгуд Гайнетдин. – Казан: «Иман» нәшр., 2010. – 136 б.

5. «Татар археографиясе» сериясе. 1 нче китап. Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты», «Хәләл нәфака эстәгәннәр сыйфаты» / Төзүчесе – Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2008. – 88 б.; Икенче басма., 2011. – 88 б.

6. К.С.Давлетшин. Творчество поэта XVII века Мавля Кулыя / Автореферат диссер. на соискание ученой степени к.ф.н. – Казань: Изд.-во КГУ, 1971. – 28 с.

7. Татар әдәбияты тарихы: Сигез томда. 2 нче том / Фәнни мөхәррире – Х.Й.Миңнегулов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2014. – 471 б.

8. Средневековая татарская литература (VIII-XVIII вв.). – Казань, Изд.-во «Фән», 1999. – 24 с.

9. К.С.Дәүләтшин. XVIII гасыр шагыйре Мәүла Колый. – Уфа: БашДУ нәшр., 2010. – 400 б.

10. Татарская энциклопедия. – Т.4. – Казань, 2008.

11. Татар энциклопедиясе. – Т.4. – Казан, 2014.

12. Х.Й.Миңнегулов, Ш.А.Садретдинов. Әдәбият (Борынгы һәм Урта гасыр; 19 нчы йөз татар әдәбияты. ... 9 нчы сыйныф өчен дәреслек. Өченче басма. – Казан: «Мәгариф», 2005. – 407 б.

13. Татар әдәбиятыннан 9 нчы сыйныф өчен хрестоматия / Төзүчеләре Х.Й.Миңнегулов, Ш.А.Садретдинов. Икенче басма. – Казан: «Мәгариф», 2000. – 383 б.

14. Х.Й.Миңнегулов, Н.С.Гыймадиева. Татар әдәбияты. Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. – 363 б.

15. М.Әхмәтҗанов. Мәүла Колый кем ул? // Совет мәктәбе. – 1986. – №10. – 17-19 б. ■

Мәүла Колый

*Мөхәммәт Садыйков**

Җәен – арба, кышын чана тартып,
Мәүла Колый узган бу юлдан...
Шигырьләре, Коръән аятедәй,
Күңелләргә тирән уелган...

Бу юллардан бүген мин дә узам:
Аллаһ колы, шигырь колы да.
Күңелемнән шигырь укып барам,
Бәхет иңәр кебек юлыма.

Кипкән иренемне чылатырга
Сулар алган сыман коедан,
Еллар аша иманымны пакьләп,
Илһам алам Мәүла Колыйдан.

Кол Галиләр заманыннан килә,
Татар шигърияте борынгы...
Аллаһ колы булып язган идем –
Канаттылар авыз-борынны.

Шигърияткә алып килә мине
Милләтемә, дингә мәхәббәт.
Фәрештәләр куна иңнәремә,
Күңелемә иңә моң-рәхәт.

Диндар затлар сөргеннәрдә сүнде,
Узган юллар – газап-этаплы...
Алласызлар бездән яшерделәр
Коръән дигән изге китапны.

Милләтемнең рухын саклау өчен
Иманлы дин кирәк адәмгә;
Изге җиребездән аерылып,
Очып йөрү нигә галәмдә?!. ■

* Мөхәммәт Хәмит улы Садыйков 1934 елның 12 маенда Питрәч районының Күн авылында колхозчы гаиләсендә туган. Гомере буе Шәле авылы мәктәбендә укытучы булып эшли. Шигырьләре төрле газета-журналларда чыгып килә. «Зәңгәр юллар», «Дуслык», «Зәңгәр офыклар», «Яшьлек таңы», «Яшьлек алга ашыга», «Ходай колы», «Туган як җылысы» исемле шигъри җыентыклар авторы.

«Хатын әйтте: мин кылырмын чарасын»

(Мәүла Колый поэмалары)

Раиф Мәрданов

Шагыйрь Мәүла Колый – XVII гасырның икенче яртысында иҗат иткән күренекле татар әдибе. Ул Әхмәт Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Кол Гали, Сәйф Сараи, Өмми Камал, Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф кебек фикер ияләренең рухи бакчаларыннан азык алып, үз шигъри дөньясын тудырган олы шагыйрь. Мәүла Колый иҗатының нигезе суфыйчылык рухы белән сугарылган. Шул ук вакытта, башка татар суфый әдипләренә хас булганча, Мәүла Колый әсәрләрендә җирле традицияләр һәм дөньявилык идеяләре дә чагылыш тапкан.

Мәүла Колый әсәрләренең ТР Милли китапханәсендә саклана торган нөсхәсеннән аерым битләр

Мәүла Колый Чытыда дөньяга килгән

Шагыйрьнең иҗатына, ул яшәгән чор документларына, шәҗәрәләргә һәм риваятьләргә нигезләнеп, Марсель Әхмәтҗанов Мәүла Колый биографиясен ачыкларга омтылды. Галим туплаган мәгълүматларга караганда, Мәүла Колый (кайбер шигырьләрендә язылганча, «Меллагол кол») исеме белән билгеле шагыйрьнең чын исеме Бәйрәмгали Колыев (Бимкә суфый) булган икән. Ул 17 нче йөз урталарында Казан өязендәге Чыты авылында (хәзерге Питрәч районында) дөньяга килгән. Казанда мәдрәсәдә укыган. Аның исеме XVII гасыр ахырында хөкүмәт һәм татарлар арасындагы гауга-низагларга бәйләнешле документларда да телгә алынган. Казан ягындагы татар крестьяннары 1678 елда Мәүла Колый (Бәйрәмгали Колыев) җитәкчелегендә Биләр шәһәре хәрабәләре янына күчеп урнашканнар. Патша хөкүмәте, әлбәттә, бу хәл белән ризалашмаган һәм 1699 елда, Петр Беренче фәрманы буенча, татарлар ул җирләрдән куылганнар. Мәүла Колый иптәшләре белән Шушма буена, Иске Иштирәк авылына (хәзер Татарстанның Лениногорск районы җирлегендә) урнашкан.

Әдипнең шигырь-хикмәтләре теркәлгән иске кульъязмалар Казан, Уфа һәм Петербург шәһәрләрендәге гыйльми оешмаларда саклана. Аның әсәрләренең күчермәләре татарлар яши торган төбәкләрдә, сирәк булса да, хәзер дә табылып тора.

Мәүла Колый поэмалары табылу – зур вакыйга

XX гасыр ахырында Мәүла Колый поэмалары табылу татар әдәбияты тарихы өчен зур әһәмияткә ия булды. Әдипнең фәнгә бөтенләй билгесез яңа әсәрләренең күчермәләре табылгач, хикмәтләр авторы сыйфатында мәгълүм булган Мәүла Колыйның поэма жанрында да иҗат иткәнлеге ачыкланды.

Мәүла Колый поэмалары теркәлгән 1754 елгы кульъязма җыентык бу юлларның авторы тарафыннан 1990 елда табып алынган иде. Әлеге кыйммәтле кульъязма истәлек хәзерге вакытта Татарстан Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «606 т» шифры белән саклана. Аның табылу тарихы һәм тасвирламасы, шулай ук поэмаларның текстлары басылып чыкты*.

Хәзерге вакытка бердәнбер күчермәләре сакланган поэма текстларының беренчесе шактый тулы булса, икенчесенең башлангыч өлеше генә бар.

Күңелләрендә гыйшык уты кабына

Беренче – «Береккәннәр сыйфаты» поэмасының кыскача эчтәлеге моннан гыйбарәт.

Бер ир белән хатын, үзара киңәш-табыш иткәннән соң, фани дөнья мәшәкатьләрен читкә куеп, тыныч урынга китеп, тормышларын тулаем Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуга, ахирәт тормышына ихластан әзерләнүгә багышларга карар итәләр. Бер тауга барып кечкенә генә торак һәм гыйбадәтханә төзиләр, шунда гомер кичерә башлыйлар. Хак Тәгалә юлыннан тайпылмыйча, намаз укып,

* Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. – Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2008. – Б.12-14; Шул ук. – Икенче басма, 2011. – Б.12-14.

ураза тотып 60 ел яшәгәч, боларга Иблис вәсвәсә сала. Иблис ирнең гыйбадәт белән генә утыру фикерен чуалта.

Аллаһка биргән антларын бозу булса да, ир белән хатын дөнья күрергә дип чыгып китәләр. Бер шәһәр янындагы чишмә буенда тукталалар. Ире ипи алу өчен шәһәргә юнәлә. Аннан кайтышлый, бер мәһабәт сарай һәм сарай эчендәге искиткеч гүзәл хан кызын күреп туктала. Икесенең дә күңелләрендә гыйшык уты кабына. Хатыны янына кайткач, ир хәлне аңлатып бирә. (Шушы урында, кулъязманың берничә бите төшеп калу сәбәпле, текстка өзеклек кергән һәм әсәрдә тасвирланган кайбер хәлләр безгә билгесез кала.) Ниндидер вакыйгалардан соң хан кызы белән ирне «тотып алалар» һәм зинданга ябалар. Бичара хатын кайтмаган ирен эзләп сарайга килә. Аның кайда икәнлеген ачыклагач, башын-йөзен ике бөркәнчек белән каплап, ике табак аш (ризык) алып зинданга бара. Зиндан сакчысының күңелен бер табак аш белән яулап алып, зиндандагы кешемә ризык ашатыйм дип, эчкә үтә. Башындагы бер бөркәнчекне хан кызына яптыра һәм аңа буш табакны биреп, чыгарга куша. «Аулак җирдә табакларны ташлагач, сараеңа кайт та тыныч кына йөр», – дип, кызны өйрәтеп җибәрә.

> «
> **Ире ипи алу өчен шәһәргә юнәлә. Аннан кайтышлый, бер мәһабәт сарай һәм сарай эчендәге искиткеч гүзәл хан кызын күреп туктала. Икесенең дә күңелләрендә гыйшык уты кабына. Хатыны янына кайткач, ир хәлне аңлатып бирә.**

Кызының ниндидер ят ир белән тотылуыннан хурланган, ачуыннан ярсыган хан җәлладка тоткыннарны китерергә куша. Зинданчы аларны тиз генә хан янына алып килә. Шактый гына аңлашканның соңында, хатын йөзеннән бөркәнчеген алгач, боларның ир белән аның хәләл хатыны икәнлеген күреп, хан һәм җәллад хәйран калалар. Шул рәвешчә, ханның йөзе «ак» булып кала, ир белән хатын да җәзадан исән-сау котыла. Өстәвенә, хан аларга күп итеп мал-байлык бирә. Ир һәм хатын әүвәлгечә гыйбадәт белән тыныч гомер кичерүләрен дәвам итәләр.

***

Автор бу поэмасын береккәнлек, ягъни бердәмлек аркасында гына бәладән котылып, иминлеккә ирешергә мөмкин дигән фикер белән йомгаклап куя. Шулай итеп, әсәр укучыларны бердәмлеккә өндәп, «берлектә – көч» дигән рухта тәмамлана.

Әсәрнең сюжеты мавыктыргыч һәм чишелеше оста корылган. Автор әсәрдәге хәлиткеч вазыйфаны хатынга йөкләгән. Мәүла Колый, аның кыюлыгы һәм зирәклеге белән, четерекле мәсьәләне уңай хәл итә. Нәтиҗәдә, «бүреләр дә тук, сарыклар да исән» кала. Әсәрнең идея-тематик ягы кешелек дөньясында һәрвакыт актуаль булган бердәмлек мәсьәләсенә нигезләнгән.

Кулъязма җыентыктагы икенче әсәр – «Хәләл нәфака (байлык) эстәгәннәр сыйфаты» поэмасының аз өлеше генә сакланганлыктан, аның эчтәлеген тулаем күзаллау мөмкин түгел. Тик текст фрагменты буенча фикер йөрткәндә, Мәүла Колыйның бу поэмасы да шактый күләмле һәм гыйбрәтле сюжетка корылган булуы чалымлана.

Мәүла Колый поэмаларында гарәп-фарсы алынмалары чагыштырмача аз, борынгы язма төрки-татар теле формалары өстенлек итә.

Берләшкәннәр сыйфаты

(Хәзерге татар теленә күчермәдән өзек)

Мәүла Колый

Хезмәтче әйтте: «Ни кеше хатыны син?»
Хатын әйтте: «Заһидның хатыны мин».

Хезмәтче әйтте: «Булды безнең йөз кара,
Бу эш белән ни кылыйк соң, ни чара?»

Хатын әйтте: «Мин кылырмын чарасын,
Китәрермен сезнең йөзнең карасын.

Ни җирдә Заһид белән кыз – әйт миңа,
Илтегез мине, бик тиз барам аңа».

Хатынга хезмәтче зиндан урынын әйтте,
Ике табак ризык алып хатын китте.

Башына ике бөркәнчекне ябып,
Шул сәгать зинданга җитте барып.

Зинданчыга диде хатын: «Әй газиз!
Бер сәгатькә мине зинданга кертегез.

Зинданда кешем бар, аш ашатыйм,
Бер табак ризык сиңа ашарга бирим».

Зинданчы әйтте: «Сүзеңне тыңлыйм, хуш».
Таштай күңелне йомшаткан бер табак аш!

Хатын тиз керде зиндан эченә аш алып,
Бер яулыкны башыннан алды салып.

Яулыкны ул кызның башына салып,
Табакны кулына бирде: «Чык алып!

Зинданчыдан табакны ал сорап,
Аулак җиргә чыккач, табакны ыргыт!»

Кыз чыкты башына бөркәнчек салып,
Китте тиз зинданчыдан табакны алып.

Бер аулакта табакны ташлап китте,
Сараена исән-имин барып җитте.

Хан мәчеттә көндезге намаз кылып,
Ачу белән утырды тәхетенә килеп.

Диде: «Җәллад, китер Заһид белән кызны!
Ник болай кара кылды безнең йөзне?»

Зинданчы Заһид белән хатынны бирде,
Җәллад шундук боларны алып барды.

Заһид белән хатын ханны күрделәр,
Хөрмәт белән җиргә йөзләрен ордылар.

Хан анда диде: «Әй бәдбәхет хатын!
Йөз кара иттең, сакламый аталык хакын».

Хатын әйтте: «Ни тиде миннән зарар?
Ни зарар тисә миннән, бирче хәбәр?!»

Хан әйтте: «Ул бакчада ни кылдың син,
Йөзеңә кара сөртеп килдең син?»

Хатын әйтте: «Әй шаһым, булчы ата,
Кичәге эшебез бит булды хата.

Бу әрләү бакча өчен булса миңа,
Ялварамын Тәңре хакы өчен сиңа.

Килә-килә бер бакча эченә җиттек без,
Йокы басты да, шунда йомдык күз.

Арганлыктан йоклаганбыз һуштан китеп,
Йоклаганбыз уянмый, таң намазы үтеп.

Җәллад килеп тотты безне йоклаганда,
Диде безгә: «Киттек, урыныгыз зинданда!»

Кичәге эшебез хата булган икән,
Белмәдек без, бу бакча сезнеке икән.

Ул гаеп булды бездә, кичә өчен
Гаебебез кичер, Тәңре хакы өчен?»

Хан әйтте: «Күпме хәйлә итәсең,
Бу ният белән ничек боргаланасың?»

Хатын әйтте: «Безне болай итәсең,
Бакчагызга кергән өчен тотасың?»

Хан диде ки әйтеп туры сүзен:
«Син йөзебезне кара кылдың безнең!»

Хатын әйтте: «Ни эш булды бу ара,
Ни зарарым тиеп йөз булды кара?»

Хан әйтте: «Заһид белән тотылып,
Бу җиргә килгәнсең кара йөз булып».

Хатын әйтте: «Шәригатьтә мондый эш булса,
Үз хатыны белән тотылып ханнарга килсә...»

Хан әйтте: «Түгелме син минем кызым,
Югыйсә ялгышмы минем бу сүзем?»

Хатын әйтте: «Мин бу Заһид хатыны,
Синең кызың түгелмен, бел дөресне!»

Хан әйтте: «Йөзеңне ач әле, күрим,
Бу Заһидның хатыны булсаң, белим».

Хатын анда япмасын ачкан заман,
Хан күреп, бу эштән калды хәйран.

Хан әйтте җәлладка: «Бу нинди хәл?»
Җәлладның сүз әйтергә калмады әмәл.

Хан кызына кеше җибәрде белергә,
Сараенда бармы-юкмы – күрергә.

Сараенда күрделәр ул вакыт кызны,
Каралыктан юылды ханның йөзе.

Бердәмлектән итте алар мондый эш,
Береккәннәр имин булыр яз һәм кыш.

Акыллы адәм берләшеп берлек кыла,
Хак рәхмәте берлеккә якын була.

Кил, әй мөэмин, берләшеп кыл һәр эшне,
Хакның рәхмәтенә ирешә ул кеше.

Берләшкәннәр сыйфатын әйттем сезгә,
Берләшкән эш иминдер сезгә-безгә.

Тәүфыйк биреп күрсәт хак юлларыңны,
Рәхмәтлеккә ярлыка колларыңны?!

Әй Ходаем, гөнаһлы Мәүла Колый,
Рәхмәтең белән син бир коллык юлы.

*Текстны басмага **Раиф Мәрданов** әзерләде.* ■

Илһам Кашапов: «Авыл туризмы тарихыбызны саклый»

(Питрәч муниципаль районы башлыгы Илһам Миңнехан улы Кашапов белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон әңгәмәсе)

– Илһам Миңнеханович, Сез – озак еллар кошчылык өлкәсендә эшләп, бу юнәлештә хәтта махсус белем алып, галим дәрәҗәсенә ирешкән шәхес. Район хакимияте вазыйфасын башкарганчыга кадәр тагын нинди хезмәт юлларын уздыгыз?

– Кошчылык буенча Мәскәүдә һәм Балтыйк буенда гына махсус белгечләр әзерлиләр. Яшерен-батырын түгел, 1990 нчы елларда юридик яки медицина буенча югары белем алырга матди мөмкинлегебез юк иде. Ә мин югыйсә биология һәм химия фәннәреннән олимпиадаларда гел алдынгы урыннарны алып килдем. Районнан ике кешегә академик К.И.Скрябин исемендәге Мәскәү ветеринария

академиясендә уку мөмкинлеге тудырылды. Әти-әнием гомер буе Ленино-Кокушкино кошчылык фабрикасында эшләгәч, мин дә, аларның эшен дәвам итү нияте белән, әлеге юнәлештә укырга уйладым. Без кечкенәдән шул фабрикада, кошлар арасында үстек дияргә була, шуңа бу тармак миңа балачактан якын. Элек ата-ана белән бала мөнәсәбәтләре, гаилә традициясе дигән әйберләр бик көчле иде. Табиб баласы – табиб, укытучыныкы – укытучы яки башка укымышлы булырга тиеш дип кабул иттек. Хәзер исә, медицина яки башка тармакта атасы улы-кызы белән эшли башласа, «коррупция» дия башладылар.

Әйтергә кирәк, Мәскәү ветеринария мәктәбе бик көчле. Кичке тугызларга кадәр «анатомичка»да укып, этләрнең һәр сөягенә кадәр җентекләп өйрәнә идек. Шуңа түзгәннәр генә алга таба укуны дәвам итә алды. Медицина уку йортларында кеше анатомиясен дә алай җентекләп өйрәтмиләр. Мәскәүдә укып кайтсам – фабрика авыр хәлдә. Башка фабрикаларга киттем. Мине, Мәскәүдә укып кайткан кошчылык белгечен, бер җирдә дә эшкә кабул итмәделәр. Шулай итеп Питрәч зоолабораториясендә, СПТУда эшләдем. Әмма барыбер кошчылык тармагына күчү бәхетенә ирештем. Кошларны рацион нигезендә ашату буенча төбәктә иң яхшы белгечләрдән, дип мактап әйтә алам үземне. Бу миңа бик кызыклы өлкә булды. Кошчылык буенча Бөтенроссия фәнни-тикшеренү һәм технология институтында укып, шушы юнәлештә махсус фәнни хезмәт тә язып якладым.

– Сез яхшы мәгънәсендә үҗәт кеше. Кешенең шәхес буларак формалашуында гаилә традицияләре нинди роль уйный?

– Әйткәнемчә, мин – гаилә традициясен, әти-әнинең эшен дәвам итүче. Әтиәнием гап-гади эшче булса да, аларның белемгә тартылулары бик зур иде. Әнием үз заманында, мөмкинлек булмау сәбәпле, укый алмаган. Шунлыктан уку буенча

алар миңа бөтен шартларны тудырды. Заманча итеп әйтсәк, укуның киләчәккә яхшы инвестиция икәнен бик яхшы аңладылар.

Икенчесе – хезмәт. Бабаемның иртәнге өчтә йокыдан торгызып, ат җигеп, печән чабарга кардонга алып менгәнен әле дә яхшы хәтерлим. Чыклы печәнне чабып, иртәнге сигезләрдә генә кайта идек. Көндез су коенабыз, малайлар белән уйныйбыз, аннары кич яңадан печәнгә китәбез. Шунлыктан хәзер дә эш сәгатемне иртә таңнан башлыйм, кичен спорт белән шөгыльләнәм – без моңа балачактан ук күнеккән инде.

– Питрәч – Казан читендәге район. Башкалага юл бик кыска. Шундый районда эшләүнең үзенчәлеге бармы?

Мин – юлда туган бала. Кокушкино белән Питрәч арасы хәзер биш минутлык юл. Элек юл Иске Шигали аша уза торган булган. Тулгагы башлангач, әнине, автобуска утыртып, Питрәчкә алып киткәннәр. Әмма барып җитә алмаганнар: мин Иске Шигалидәге бер йортта дөньяга килгәнмен. Бу тарихны белүчеләр мине «Шигалиевский» дип үртәп йөрттеләр. Аңлагансыздыр, элек бу юллар алай кыска түгел иде. Хәзер исә ара якынайды – Казан белән Питрәч арасы ярты сәгатьлек кенә юл.

Миңа Яшел Үзәндә дә эшләргә туры килде. Шул ук технология, тавыгы да бер, тик кешеләре аерылып тора. Аларның холыклары, хезмәткә мөнәсәбәте дә үзгә. Яшел Үзәнгә шул ук технологияне алып килдем, әмма эш бармады. Шуннан соң мин үземә андагы кешеләрне ничек бар шулай кабул итәргә, аларны яратырга дигән максат куйдым. Соңрак Питрәч, Яшел Үзән һәм Чистай кошчылык фабрикаларын бер технологиягә берләштердем. Чистайда халык бөтенләй башка. Халыкны, аларның фикерләрен йөрәгеңә якын алып, уртак тел табып эшләмәсәң, бернәрсә дә килеп чыкмый.

– Сезгә Аллаһы Тәгалә төрле район халкы белән эшләп карарга мөмкинлек биргән. Хәзер Питрәч районын җитәклисез. Монда инде кошчылыкны гына түгел, игенчелек белән терлекчелекне дә истә тотарга кирәк...

– Үз туган җиреңне яхшы якка үзгәртү мөмкинлеге барлыкка килү – зур бәхет. Мин һәр проблеманы үзем барып күрергә, аягым-кулым белән тоярга күнеккән. Кешеләр хәзер күбрәк системалы проблема белән түгел, ә шәхси мәсьәләләр белән мөрәҗәгать итә. Аларның проблемасы – безнең проблема. Безгә райондашлар белән уртак тел табарга, алар белән бергәләп эшли белергә кирәк. Читтән килеп безнең өчен берәү дә берни дә башкармаячак. Питрәчкә күчеп кайтып яши башлаган кеше дә безнеке саналырга, аның проблемалары да безнеке булырга тиеш.

Хәзерге вакытта күбрәк кешеләр проблемасы белән шөгыльләнәбез. Яшерен-батырын түгел, авыл хуҗалыгы төбәгебездә икенче планда. Ул – шәхси тармак, анда артык кысылырга ярамый. Кешеләргә пай җирләре хакын, хезмәткә түләнүне, салым җыюны кайгыртырга тиешбез. Элекке кебек аякка резин итек киеп басуларда, фермаларда йөрүнең мәгънәсе юк.

Иң зур максатларыбызның берсе – кешеләргә яшәр өчен уңайлы шартлар тудыру. Мин районны җитәкли башлаганда бездә 36 мең кеше яши иде, хәзер исә – 53 400 кеше. Фәкать 1300е генә авыл хуҗалыгында эшли, шуның 700гә якыны кошчылык комплексында хезмәт итә. Район халкы ел саен 4-5 мең кешегә арта. Республикабызда иң күп туу һәм иң аз үлем күрсәткече – Питрәчтә. Яшь гаиләләр күпләп күчеп кайта, ай саен йөзләп пенсионер өстәлә. Царевода торган кешеләрнең кайберләре Шигали һәм якын-тирә авылларда өйләр сала башлады. Димәк, аларга районда яшәү рәхәт.

Әлбәттә, бу кешеләр авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнми диярлек. Алар районга йокларга гына кайта, салымны Казандагы эш урынында түли, әмма юл, медицина хезмәте, урамнарны яктырту, чистарту, кешеләрнең куркынычсызлыгы, балалар бакчасы һәм мәктәп белән тәэмин итү – безнең вазыйфабыз. Кыскасы, шәһәрдә эшләп, авылда яшиләр. Әмма авыл белән шәһәр арасындагы чик югалырга тиеш түгел! Күчеп кайткан кешеләр дә үзләренең авылда яшәүләре турында онытмасыннар иде. Авылның үз традицияләре, үзенчәлекләре бар. Ул беркайчан да Казан шәһәре кебек халыкара дәрәҗәдә булмаячак. Дөрес, авыллардагы яшәү шартларын заманча итеп үзгәртеп корырга омтылабыз. Шәле, Богородское, Кощаково һәм Ленино-Кокушкинода, шулай ук Питрәчнең үзендә шәһәрдәге кебек парклар ачылды.

– Питрәч дигәч, Хания Фәрхи башкаруындагы «Сагынам сине, Питрәч» дигән җыр искә төшә. Питрәч ягы Ленино-Кокушкино Ленин музее яки сугыш батыры Петр Гаврилов белән танылган. Бүгенге көндә Питрәч халкы кемнәр белән горурлана?

– Дөрес, балачакта безне геройлар рухында тәрбияләделәр. Совет чорында, чынлап та, Ленино-Кокушкино, андагы Ленин музее данлыклы булды. Соңгы вакытларда үзебезнең районнан чыккан күренекле шәхесләргә аеруча игътибар итә башладык. Совет тәрбиясе буенча, геройлар белән генә алга барганбыз, ә баксаң, татар дөньясына мәгълүм башка шәхесләребез дә бар икән. Айдар абый Хафизов белән аралашып, очрашып калдым, әмма аның белән тиешле дәрәҗәдә эшли алмавыма үкенәм. Мәгърифәтче Мәүла Колый турында аз гына белә идем, шулай да аны республика дәрәҗәсенә күтәрергә кирәклеген яхшы аңладым. Үз-үземә: «Миңа мөмкинлек бирелгән, мин булдыра алам», – дигән максат куйдым. Хәзер бу юнәлештә реаль мөмкинлек барлыкка килде.

«

Соңгы вакытларда үзебезнең районнан чыккан күренекле шәхесләргә аеруча игътибар итә башладык. Совет тәрбиясе буенча, геройлар белән генә алга барганбыз, ә баксаң, татар дөньясына мәгълүм башка шәхесләребез дә бар икән.

Ел саен бер үк ветераннарны хөрмәтлибез. Сүз дә юк, алар моңа бик лаек. Әмма мин башкачарак позициядән дә карарга булдым. Әгәр дә теге яки бу кеше районда бер юнәлештә утыз-кырык елдан артык хезмәт куйган икән, ул кадер һәм ихтирамга лаек түгелмени?! Үземнең блокнотта Питрәч җирендә озак еллар дәвамында эшләгән кешеләрнең исемлеген булдырдым. Анда 400гә якын шәхес бар. Исән вакытта без аларның, һичшиксез, кадерен белеп, игътибарыбызны кызганмаска тиешбез.

– Туризм буенча перспективалар бармы? Арчаның Тукае булган кебек, Мәүла Колыйны да районның бренды дәрәҗәсенә күтәреп булырмы?

– Минтимер Шәрип улы Шәймиев бер җыелышта авылларны саклау кирәклеге турында сөйләгән иде. Татарстанда моны эшләргә кирәклеген бар кеше дә яхшы аңлый. Әмма кешене фермага ничек эшкә җибәрергә яки тракторга утыртырга? Бу мөмкин түгел! Элек ун механизатор башкарган эшне хәзер бер трактор башкара ала. Ә менә авыл туризмы күпмедер дәрәҗәдә безнең авылларыбызны саклап калырга мөмкин. Шуңа бәйле рәвештә, фермер хуҗалыклары да үсәчәк. Хәзерге вакытта шәһәр кешеләре авылда җитештерелгән натураль, экологик чиста

«Питрәч районы һәм Мишә елгасы буйлары: үткәне-бүгенгесе» исемле төбәкне өйрәнүчеләр конференциясеннән соң. 2021 елның декабре

азык-төлеккә мохтаҗ. Бер үк вакытта сувенирлар белән дә кызыксыну уяначак. Күпмедер дәрәҗәдә авыл туризмы, ягъни авыл яшәеше белән кызыксыну этник яктан барлыгыбызны, тарихыбызны саклый ала. Шәһәр яны, олы юл читендәге авыллар өчен бу аеруча өстенлекле юнәлеш булырга тиеш. Әлеге тармакта башкарасы эшләребез бик күп.

Айдар Хафизовның туган авылы Күндә клуб төзекләндереләчәк, шунда ук истәлек тактасы куелып, музей оештырылачак, район үзәгендә бюсты да булыр дип уйлыйм. Театрга Айдар Хафизов исемен биреп, аның истәлегенә фестиваль уздыруны традициягә кертеп җибәрергә ниятлибез.

Шәледәге 1895 елгы тарихи мәчетне төзекләндереп, музей-комплекс эшләү нияте дә бар. Янында рәссам Харис Якупов әсәрләреннән музей булачак. Аны элекке даруханә бинасында ачарга ниятлибез. Даруханә исә Шәле дәвалау амбулаториясе бинасына күчерелде. Карнай чишмәсе буенда этнографик йорт төзелер дип уйлыйм. Шәле авылы бик уңайлы җирдә – М-7 трассасы буенда урнашкан. Юл читенә күрсәткечләр дә куйсак, туристлар бу урынны читләтеп үтмәс.

Советлар Союзы Герое Петр Михайлович Гаврилов истәлегенә өч көнлек фестиваль узачак. Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнеханов әлеге батырның туган авылы Әлбәдәндә мемориаль комплекс төзү идеясен хуплады. Анда сугышның ничек башланганлыгы, Брест крепосте оборонасы яхшы реконструкция һәм реаль эпизодлар белән күрсәтеләчәк.

Чыты авылында Мәүла Колыйга багышланган манара формасындагы алты метрлы истәлек билгесе урнаштырылачак. Конференция вакытында аңа нигез ташы салыныр, шунда ук киләчәк буынга өч телдә мөрәҗәгать белән капсула да куеп калдырырга уйлыйбыз. Ул телне, гореф-гадәтләрне саклау турында булачак. Бу көнне мәчеткә мәшһүр мәгърифәтченең исеме биреләчәк. Шулай ук Питрәчнең үзендә, Мишә елгасы ярында булырга тиешле Мәүла Колый паркы проектын да эшлибез, тиздән анысы да гамәлгә ашар дип өметләнәм.

ИншәАллаһ, Мәүла Колый исеме белән күкрәк билгеләре, мәкаләләр, китаплар чыгар. Аның тирән мәгънәле шигъри юллары юл читләренә язып эленер, тарих-әдәбият белән бөтенләй кызыксынмаган кешеләр дә шуны укып гыйбрәтләнерләр, дип уйлыйм.

Сагынам сине, Питрәч

Хания Фәрхи сүзләре,
Рифкат Сәйфетдинов көе

Мишә буе ямьле, Питрәч ягы –
Кочагыңда эреп югалам.
Тигез сукмакларга басып йөрим –
Синең эзләреңне саклаган.

Кушымта:
Үзәкләрне өзәсең бит,
Сагынам сине, Питрәч.
Аһ, диеп бер әйтеп куям,
Синнән еракка киткәч.

Сине ташлап киткән балаларың
Китмәскә дип кире кайталар.
Туйлар гөрли, яшәрә авыллар,
Җирне ямьләп туа сабыйлар.

Кушымта:
Өзелер әле үзәгең,
Сагындыра ул Питрәч.
Аһ, диеп әйтерсең әле,
Питрәчтән ерак киткәч.

Син дә, дустым, кайтчы туган илгә,
Йөрмә әле читтә адашып, –
Туган ягың кабул итәр сине
Кочагына алып, яратып.

Кушымта:
Үзәкләрне өзәсең бит,
Сагынам сине, Питрәч.
Аһ, диеп бер әйтеп куям,
Синнән еракка киткәч. ■

Безнең мирас №3 март 2022

Питрәч археологиясе

Альберт Борһанов

Альберт Борһанов археологик казу эшләре вакытында

Татарстанның Питрәч районы Казан артында, Мишә елгасы бассейнында урнашкан. 1930 елның 10 августында оештырылган Питрәч районы Биектау, Арча, Теләче, Балык Бистәсе һәм Лаеш районнары белән чиктәш.

Питрәч-Казан арасы – 45 чакрым.

Фәннәр академиясе, Федераль университет, башка фәнни үзәкләре булган мәркәзебезгә терәлеп торса да, Казан арты, шул исәптән Питрәч районы да, тарихи-мәдәни яктан бик аз өйрәнелгән. Шуңа да 2021 елның 9 декабрендә биредә, администрация хуплавы нигезендә, «Татмедиа» агентлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы, Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте, галим-голәма катнашында «Питрәч районы һәм Мишә елгасы бассейны: үткәннәрдән – киләчәккә (этномәдәни үсеш, традицияләр һәм новацияләр)» дип исемләнгән республика конференциясе оештыру һәм уздыру гаять мөһим вакыйгага әверелде. Ул төбәктәге авыллар тарихын, археология һәйкәлләрен, эпиграфика һәм архитектураны, күренекле якташларның тормышын һәм эшчәнлеген алга таба яхшылап өйрәнергә нигез булдырды.

Район җитәкчелегенең, бигрәк тә шәхсән Илһам Миңнехан улы Кашапов төплелеге, зирәклеге аркасында, конференциядә катнашучыларның үтенечен дә исәпкә алып, 2022 елның 1 апрелендә Питрәчтә бу чараның икенче өлешен Россия күләмендә уздырырга карар кылынды. Хәзер әлеге юнәлештә җитди эш бара, темага кагылышлы материаллар, чыгышлар әзерләнә; киләчәктә алар аерым бер җыентыкка тупланыр дип ниятләнелә.

Шунысын искәртергә кирәк: Питрәчтәге чара – Татарстан төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең һәм музей хезмәткәрләренең соңгы елларда аеруча активлашып китүе нәтиҗәсе. Мондый конференцияләр республиканың төрле районнарында уздырылып килә һәм киләчәктә дә үткәрелер дип ышанабыз.

Бүген төбәк тарихчыларының төп максатларыннан берсе булып күренекле якташларының истәлеген, тормышын, эшчәнлеген өйрәнү һәм барлау тора. Питрәч районына бәйле рәвештә, бу җәһәттән, иң әүвәл хәтергә татар халкының мәшһүр улы, мәгърифәтче, шагыйрь һәм әдип, Чыты авылы тумасы, XVII гасыр азагы-XVIII гасыр башында яшәгән һәм иҗат иткән остаз Мәүла Колый килә. Аның йогынтысы, Питрәч төбәге белән генә чикләнмичә, еракка – тулаем Казан артына, Татарстанның көнчыгышына һәм көньяк-көнчыгышына, Идел-Урал буена тарала, шәркый мөселман илләренә үтеп керә. Быел Питрәчтә, Идел Болгарстанының ислам динен рәсми кабул итүенә – 1100 ел, Бөтендөнья татар конгрессы оешуга – 30 ел тулуны да исәпкә алып, Мәүла Колыйга багышланган бик күп чаралар уздыру күздә тотыла. Шул исәптән, стела урнаштыру, музей булдыру, төзекләндерелгән мәчеткә Мәүла Колый исемен бирү, бөек якташларының әсәрләрен нәшер итү…

Кызганыч ки, җирле халыкның тарихи хәтере XVI гасыр вакыйгаларыннан еракк арак китми, тирәнгәрәк төшми. Бу, беренче чиратта, Ватан һәм татар тарихы белемендәге субъектив факторларга һәм, икенче яктан, төбәкнең, чыннан да, начар өйрәнелүенә бәйле. Гәрчә Питрәчтәге төбәкне өйрәнү музее экспозициясендә, аерым алганда, «Туган як табигате» бүлегендә мамонтларның, мөгезборыннарның һәм башка җанварларның сөякләре, тешләре урын алган. Аларның барысын да археологлар һәм җирле халык Мишә елгасы бассейныннан яисә күрше-тирә авыллардан тапкан. Бу аңлашыла да: Боз дәвере узып, Җир яңадан арчыла башлауга, борынгы кешеләр, кош-корт, җәнлек-җанвар аулый-аулый, су буйларына урнаша. Алар сунарчылык һәм балыкчылык белән көн итә. Ерак бабаларыбызның торак урыннары хәзерге Питрәч районына кергән авылларда да, Казан артының башка авылларында да табыла тора. Археологлар әледән-әле таш һәм тимер балталарга, китмәннәргә, пычакларга, ук һәм сөңге очларына тарый.

Мишә елгасы үзәннәрендә таш һәм бронза чорлары әсбаплары да очраштыргалый. Әйтик, 2000 нче елларда Питрәч авылы территориясендә (Питрәч урманчылыгының Лаеш урман хуҗалыгында) энеолит (таш-бронза гасыры, безнең дәвергә кадәрге III-II меңьеллык) чорына караган борынгы кешеләрнең тукталу урыны табыла.

Галимнәр Колай авылының фермаларыннан ерак түгел җирдә, Мишәнең уң як кушылдыгы буенда, диаметры 30 метр, биеклеге 60 сантиметр тәшкил иткән курганга юлыга. Шунда ук, ике күл янында, Казан яны мәдәнияте калдыкларына тарып, чакма ташыннан эшләнгән хезмәт кораллары, балчыктан ясалган савыт-саба ватыклары җыеп алына. Норма авылы янәшәсендәге тукталу урыны да Казан яны мәдәниятенә карый.

Питрәч районында (Югары Казиле, Платоновка, Татар Тау Иле, Тегермән Тавы, Чирмеш, Чыты, Юныс авыллары) табылган археология һәм эпиграфика һәйкәлләре, нигездә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорын чагылдыра.

Әйтик, Татар Тау Иле авылы җирлегендә, Норма елгасының уң ярында, кызыл һәм соры төстәге, бизәкле керамик әсбаплар, тимер шлак һәм крица кисәкләре табыла. Питрәч районы һәм Мишә елгасы бассейнында торак пунктларның кайчан барлыкка килеп, кайчан үсеш алуы турында Кибәч, Пановка, Татар Тау Иле, Урывкино, Чыты, Тегермән Тавы һәм Янсуар авылларының зиратлары да күп мәгълүмат бирә.

Үлчәмнәре буенча 135х65х70 см булган бер кабер ташы 1491 елга карый. Анда мондый сүзләр язылган[1]:

1. Әйтте Пәйгамбәр (с.г.в.): «Хак диндәгеләр үлмиләр, бары
2. фани дөньядан бакый дөньяга күчәләр». Елы
3. сигез йөз туксан җиденче, ае шәгъбан,
4. унбишенче көндә шул булды ки, Тәвәккәл
5. Сәйәд-Әхмәт мәүлә [улы], егерме өч яшендә
6. [суда] батып, фани дөньядан дөньяның
7. [бакыена] күчендә, Хак Тәгалә аны кичерсен.

Татар Тау Иле зиратындагы 1518 елгы үзгә кабер ташында (үлчәмнәре: 23х65х100 см) мондый сүзләр уелган[2]:

1. «Ул терек, ул үлемсез, терек һәрнәрсә үлә, –
2. диде Аллаһ. – һәр җан үлемгә тарыячак. Аннан соң [сез] безгә кайтырсыз, –
3. диде Аллаһ. – Һәм җан белми кайсы җирдә үләчәген. Аллаһ һәрнәрсәне белә һәм һәрнәрсәдән хәбәрдар».
4. Һәм Пәйгамбәр әйтте: «Безгә иминлек иңсен, хак юлдагылар үлми, бары
5. фани дөньядан бакый дөньяга күчәләр. – Пәйгамбәр әйтте: – Аңа иминлек иңсен, дөнья бер сәгатьлек,
6. шушы вакытны саваплы гамәлләргә сарыф ит». Елы тугыз йөз егерме дүрттә,
7. җөмәдиел-ахир башында иде, хаҗи Хәсән углы Шәйдул-
8. лаһ … яшьтә фани дөньядан бакый дөньяга күченде.

Галим Марсель Әхмәтҗанов Татар Тау Иле авылында 1683-1684 (һиҗри 1095 ел) нче елларга караган кабер ташы язуын да өйрәнеп, теркәп куйган:

1. Тарих мең дә туксан биштә, дирләр ирди Ишбулат
2. Акман углы үз вакытында билгини куйды ирәнләрдән
3. дога өмидләрдән кыйгайлу…

Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларына караган тәңкәләр дә галим-галәма арасында зур кызыксыну уята, аларны минем коллегалар О.В.Степанов һәм Е.В.Бугарчев җентекләп өйрәнә.

2010 елда Ленино-Кокушкино авылы янында Иван III, Василий III, Иван IV исеменнән Мәскәү, Тверь, Новгород һәм Псков шәһәрләрендә сугылган 350 тәңкә табыла.

Әлегә кадәр сакланып калган тарихи-архитектура һәйкәлләре дә зур әһәмияткә ия. Алар арасында Шәле авылында XIX гасыр азагында төзелгән Җәмигъ мәчете аерым урын тота (биредә хәзер реставрация эшләре башкарыла).

1885 елның июнендә Казан губерна идарәсе Шәле авылына икенче мәхәллә булдырырга һәм мәчет төзү эшенә керешергә рөхсәт бирә. Бу эш шактый озак, авыр бара, химаячеләр табу җиңел булмый. 1889 елда Тәтеш өязенең Әҗем авылы (хәзерге Апас районы) крестьяны Исмәгыйль Габдуллаҗәлил улы Бәширов үз хисабына мәчет торгызырга теләвен хәбәр итә. Әмма аңарчы үзен икенче мәхәлләнең мулласы итеп тануларын сорый. Крестьяннар мондый шартка күнәргә мәҗбүр була, ике яклы килешү төзелә. Алай да губерна идарәсе крестьян җыенының әлеге карарын расламый. Төзелеш өчен җитәрлек акча юнәткәнче, тагын дүрт ел уза. 1893 елда гына икенче

[1] Галим Һ.В.Йосыпов укыган текст хәзерге татар әдәби телендә бирелә. – *Редакция*.
[2] Галим Һ.В.Йосыпов укыган текст хәзерге татар әдәби телендә бирелә. – *Редакция*.

Археологик казу эшләре

мәхәлләнең яңа агач мәчетендә гыйбадәт кылына башлый.

498 ир-атны берләштергән икенче мәхәлләнең беренче имамы итеп 1893 елның 18 августында Сәхәбетдин Габделлатыйпов билгеләнә (хәзерге Лаеш районының Иманкискә авылыннан). Кече мулла вазыйфасына шул ук елның 25 сентябрендә аның улы Мирзагабдулла Сәхәбетдинов (1878 елда туган) куела. Аңарчы ул 1890-1898 нче елларда Казанның «Госмания» мәдрәсәсендә белем ала, укудагы уңышлары өчен Мактау кәгазе белән бүләкләнә. Мирзагабдулла соңрак хәрби сафка алынып, 37 нче Екатеринбург полкында хезмәт итә, кече унтер-офицер дәрәҗәсенә ирешә. 1902 елда, запаска күчерелгәч, яңадан Шәле авылына әйләнеп кайта.

Беренче мәхәлләнең мәчете күп тапкыр үзгәртеп корыла (шуңа күрә, бүгенгә кадәр сакланып калмаган да). 1841 елның 10 гыйнварында аның имамы итеп Ногман Вахитов (башка чыганакларда – Габделлатыйпов) билгеләнә һәм бу вазыйфаны 1880 нче елларга кадәр биләп тора. 1852 елның 23 июнендә мәхәллә халкы имам итеп Мөхәммәтвәли Гобәйдуллинны сайлый, ул үз эшен 1902 елның 9 апреленә, ягъни вафатына чаклы алып бара. Аның улы – моңарчы кече мулла вазыйфасын башкарган Мирзахәсән Мөхәммәтвәлиев 1903 елның гыйнварында беренче мәхәлләнең имамхатыйбы итеп раслана.

Беренче мәчет янындагы мәктәптә 96 малай һәм 30 кыз укый. Аларны укыту эшендә Мирзахәсән Мөхәммәтвәлиевкә Әхмәтша Мөхетдинов ярдәм итә. Икенче мәхәллә мәктәбендә 75 малай һәм 32 кыз белем эсти.

Нәсара архитектурасына караган тарихи һәйкәлләр дә (алар, нигездә, Аркатово, Богородское, Югары Дәүләтьяр, Урыс Сәрдәсе, Чирмеш, Колай һәм Тугаш авылларында урнашкан) галим-голәмада зур кызыксыну тудыра.

Әйтелгәнчә, әлеге юнәлештә шактый эшләр башкарасы бар әле…

Бу җәһәттән, Питрәч районында гамәлгә ашырыла килгән «2021-2023 нче елларда Питрәч районында Татарстан мәдәниятен саклау һәм үстерү программасы» һәм 2022 елның 1 апрелендә узачак Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе алда торган зур максатларга ирешүдә, һичшиксез, ныклы адым булыр дип ышанабыз. ■

Безнең мирас №3 март 2022

Питрәч районының нумизматика ядкярләре

Алексей Бугарчев, Олег Степанов

Питрәчтә табылган Җанибәк хан тәңкәләре. Сарай әл-Җәдид шәһәре

Мәгълүм булганча, нумизматика – тәңкәләрне өйрәнә торган фән. Акча әйләнешен, тәңкә сугуны, акча-үлчәм берәмлекләрен тикшереп, нумизматлар һәм тарихчылар борынгы илләрнең икътисады һәм сәүдәсе торышын ачыкларга омтыла. Урта гасырларга караган язма чыганаклар аз саклангангa күрә, тәңкәләр төрле дәүләтләрнең җитәкчеләре, ханнары, солтаннары, кенәзләре, алар идарә иткән чорлар турында да күзаллау тудырырга өстәмә мөмкинлек бирә. Табылдыкларның топографиясенә карап, аерым илләрнең үсеш-үзгәреш дәрәҗәсен дә чамаларга мөмкин.

Татарстан Республикасы – нумизматик ядкярләргә бай төбәк. Биредә X-XV гасырларга караган тәңкәләр даими табылып тора. Әйтик, X гасыр мирасы, беренче чиратта, Урта Азиядән кайткан куфи дирһәмнәреннән гыйбарәт. Алар югары сыйфатлы көмештән 3-5 грамм авырлыкта эшләнгән. Билгеле, Урта Идел

дәүләтләрендә сугылган акчалар да әйләнештә йөргән. Куфи дирһәмнәре аша без X гасырда Идел Болгарстаны тәхетен биләгән илбашларының (әмирләренең) исемнәрен төгәл беләбез: Микаил бине Җәгъфәр, Габдулла бине Микаил, Талиб бине Әхмәт, Мөэмин бине Әхмәт, Мөэмин бине әл-Хәсән. Алар идарә иткән елларда Болгар һәм Сувар шәһәрләрендә тәңкә сугу йортлары ачыла.

«Галимнәр Ленино-Кокушкино тирәсендә урыс кенәзләренең 350 данә көмеш тәңкәсенә тап була. Бу акчалар XV гасырның икенче яртысы-XVI гасырның беренче яртысы аралыгында Иван III, Василий III һәм Иван IV исеменнән сугылган.

Идел Болгарстанында акча сугу эше аеруча XIII гасырда алга китә. Мәрхүм Багдад хәлифе ән-Насыйр Лидиниллаһ исеме язылган динарлар, монгол каһаннары Мөнке һәм Арыг-Богый исеме төшерелгән дирһәмнәр Татарстан җирлегендә еш очрый.

XIII-XV гасырларда Жучи Олысында сугылган 143 тәңкә мәгълүм. Җүкәтау (хәзерге Чистай), Биләр, Иске Казан археологик объектларында табылган акчаларга карап, бу төбәкләрнең сәүдә-икътисад мөнәсәбәтләрен күзалларга мөмкин.

Алтын Урда тәңкәләре күпләп табылган җирлекнең берсе – Татарстан Республикасының Питрәч районы.

Безнең мәгълүматларга караганда, Урта гасыр тәңкәләре Урыс Казысы (Җанибәк дирһәме, 1340 нчы еллар; Гали Дәрвишнең бакыр пулы[1], XIV гасыр), Татар Казысы (Гөлестанда сугылган Хозыр хан пулы, 1360 нчы еллар), Ленино-Кокушкино (Болгарда сугылган анэпиграфик тәңкә[2], XIV гасыр), Чирмеш (Мөнке каһанның бакыр динары, 1250 нче еллар), Колай (30дан артык Алтын Урда пулы, алар арасында – ән-Насыйр һәм Хозыр хан исеменнән сугылган тәңкәләр, «өчпочмак эчендәге тамга», «йолдыз эчендәге тамга», «болгар рәшәткәсе», «арыслан һәм кояш», «ике башлы каракош», «розетка» тибындагы акчалар, XIII гасыр-XIV гасыр уртасы; 10 көмеш дирһәм, XIV гасыр) авыллары янында табыла.

Аннан тыш, галимнәр Ленино-Кокушкино тирәсендә урыс кенәзләренең 350 данә көмеш тәңкәсенә тап була. Бу акчалар XV гасырның икенче яртысы-XVI гасырның беренче яртысы аралыгында Иван III, Василий III һәм Иван IV исеменнән сугылган.

Дөрес, биредәге табылдыклар саны күрше Биектау һәм Лаеш районнарында табылган хәзинәләр күләменнән шактый калыша. Моны Питрәч районының археология ягыннан аз өйрәнелгән булуы белән аңлатырга мөмкин.

Язманың авторлары Татарстан Республикасы һәм, гомумән, Урта Идел буе нумизматика ядкярләре юнәлешендә бик күптәннән эшли. Җүкәтау (Чистай), Кожаевка, Чакма (Лаеш районы), Иске Сәлмән, Сахаровка, Гурьевка, Шәпше, Ага-Базар кебек урыннарда очраган табылдыкларга бәйле бихисап хезмәтләребез бар. Әлбәттә, Болгар археология комплексы да игътибарыбыздан читтә калмады. Ульяновск, Самара һәм Пенза өлкәләрендә табылган хәзинәләр дә фәнни басмаларда яктыртылды. Киләчәктә Питрәчкә кагылышлы нумизматик мәгълүмат та биниһая артыр дигән өметтә калабыз. ■

---

[1] Пул – Алтын Урдада акча берәмлеге.
[2] Анэпиграфик тәңкә – язусыз (рәсемле генә) тәңкә.

«Нәчә кусаң, уткән гомер янә булмас»

(Мәүла Колыйдан)

Узган елның декабрь аенда Питрәчтә «Питрәч районы һәм Мишә елгасы буйлары: үткәне-бүгенгесе» дигән темага төбәкне өйрәнүчеләр конференциясе узды. Чарада XVII-XVIII нче гасырлар чигендә яшәгән суфи шагыйрь Мәүла Колый иҗатын өйрәнү, исемен мәңгеләштерү, истәлегенә мемориаль таш кую, Мишә буенда аның исемендә парк ачу мәсьәләләре күтәрелде. Игътибарыгызга әлеге конференциядән фоторепортаж тәгъдим итәбез.

Питрәч мәгариф идарәсе җитәкчесе Марина Харитонова һәм галим Альберт Борһанов

Язучы Мирсәй Гариф

Питрәч керамикасы

Питрәч геройларына багышланган күргәзмә

«Татмедиа» АҖнең генераль директоры Шамил Садыйков

Төбәкне өйрәнүче Нурулла Гариф

Төбәкне өйрәнүче Илфар Габдрахманов

Званка мәчетенең имамы Илдар Шагалиев

Безнең мирас №3 март 2022

Татар халкының легендар улы

Рәдиф Сәгъди



Әмәтхан Солтан

Александр Покрышкин

Авиация маршалы, өч мәртәбә Советлар Союзы Герое Александр Иванович Покрышкин (16.03.1913-13.11.1985) үзенең истәлекләрендә ике тапкыр Советлар Союзы Герое булган милләттәшебез, легендар очучы Әмәтхан Солтан турында: *«Ул инде Бөек Ватан сугышы барышында ук (1941-1945) биш мәртәбә герой булырга тиеш иде»,* – дип искә ала. Аның сүзләре дөреслеккә туры киләме соң? Статистика менә болайрак. А.И.Покрышкин сугыш чорында 22 дошман самолетын бәреп төшерә, тагын 7 самолетны – төркем белән һөҗүм иткәндә. Инде үзебезнең Әмәтхан Солтаныбызга (25.10.1920-01.02.1971) килик. Барлыгы 30 дошман самолетын юкка чыгара, төркем белән очканда тагын 19ны. Чагыштырып карагыз! Покрышкин, намуслы полководец буларак, Әмәтхан алдында баш ия. Рәхмәт аңа! Александр Иванович маршал дәрәҗәсен ала, чөнки рус кавеменнән санала. Ә бөек татар халкының легендар улы Әмәтхан Солтан 1971 елның 1 февралендә «канатлы» ракеталар сынаганда полковник дәрәҗәсендә һәлак була.

Шулай ук урыс империясенә хезмәт иткән, татар милләтеннән чыккан кайбер шәхесләрне дә искә алып китсәк, урынлы булыр. Суворов, Кутузов, адмирал Нахимов, тагын меңләгән җәмәгать эшлеклеләре, әдипләр, рәссамнар, композиторларның бабалары да татар дигән бөек исемне йөрткән. Икен-

Алексей Антонов

че бөтендөнья сугышының тагын бер каһарманы – полководец Алексей Иннокентий улы Антонов (сентябрь, 1896-16.06.1962), Генштаб башлыгы буларак, бөтен сугыш хәрәкәтләре белән идарә итә, армия генералы дәрәҗәсенә хәтле үсә. Ләкин, христиан динендә булуына карамастан, маршалны бирмиләр, чөнки татар милләтеннән. Аңа, урыс булып языл, дип әйтеп карыйлар. Әллә бик кире була, әллә туган халкына, әти-әнисенә хыянәт итәсе килми, үз милләтендә кала. Сугыш вакытында ул иң талантлы штаб офицеры буларак таныла. А.Антонов Беренче бөтендөнья, Ватандашлар һәм Бөек Ватан сугышларында, совет-япон бәрелешләрендә дә катнаша. Ә Беренче Ватан сугышы герое Данис (Денис) Васил улы Давыдов, илбасар Наполеонны җиңгәннән соң, киләчәк буыннарга истәлекләр яза. Аның мемуарларында: «Лучше татар никто не воевал, им завидуют даже донские казаки!» – дип әйтелгән.

Данис (Денис) Давыдов

Бүгенге көндә әлеге орыш турында дистәләгән тарихи китаплар чыгардылар (тарихилыкка кертеп булса, әлбәттә), татар полклары, татар кавалериясе хакында ник бер рәтле-башлы сүз булсын! Югыйсә Кавказның кыргый дивизиясе дә кертелгән, Париж кырыенда тирмәләр корып ашарга пешереп яткан башкортларның да сурәте бар. Ничәсе башкорт булды икән?!. Кайда ул Данис (Денис) Давыдовның (27.07.1784-04.05.1839) истәлекләре? Әлеге яуда күрсәткән батырлыкларын күз алдында тотып: «Париждагы Җиңү парадында иң алда татар полклары, кавалериясе барды, алардан соң данлыклы Кавказның кыргый дивизиясе атлады...» – дип язып калдырган. Батый ханның оныгының оныгы Данис (Денис) бабама дөреслекне безгә дә ишеттергәне өчен зур рәхмәт!

Толерант дәүләт төзер өчен, бу державага дөреслек җитми. Мин әле, язучы буларак, безнең җирлектә дә тигез хокуклы милләтләрдән торган дәүләт төзелер дип уйлыйм. Кайчан булса да...

Радик Бариев

Мари Иленең Бәрәңге районы үзебезнең Әтнә районының күршесендә генә, дисәк тә, ялгышмабыз. Элек анда татарлар күпчелекне тәшкил иткәнгә, ул «татар районы» дип тә аталган. Биредә көчләп чукындырылудан, милли изелүдән качып, тугандаш мари халкы янәшәсенә килеп сыенган Биектау, Әтнә, Арча кебек туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган милләттәшләребез яши. Халыкның күпчелеген шуларның дәвамчылары тәшкил итә. Урман артындагы әлеге җирлекне без тагын бер легендар шәхес, фашистлар өнендәге яшерен оешма җитәкчесе шагыйрь Гайнан Кормаш аша да ишетеп беләбез. Ләкин язмам икенче бер каһарман татарыбыз – Радик Әбрар улы Бариев хакында барачак.

РФ Президенты Владимир Путин каһарман очучы Радик Бариевка «Россия Герое Алтын Йолдызы»н тапшыра. 2006 ел

...2006 елның апреле. Үзәк телевидениенең «Время» программасыннан дәүләт бүләкләрен тапшыру тантанасы бара. Россия Президенты Владимир Путин полковник Радик Бариевның күкрәгенә үз куллары белән Россия Герое Алтын Йолдызын кадый. Соңрак әлеге хәрбигә багышланган репортаж да тәкъдим ителде. Менә шул чакта гына бөтен ил очучы-сынаучы, герой Бариев турында ишетте. Бәрәңге районының Ирнур авылы халкы, якташларын күреп, шатлык хисләре кичергәндер. Алай гынамы соң! Бөтен Татарстан, Мари Иле горурланды ул көннәрдә...

Офицер, хәрби сейсмолог Әбрар абый белән балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче Нурания апа гаиләсендә 1961 елның 31 июлендә, әтисе төрле җирләргә күчеп йөрү сәбәпле, ерак Украинаның Житомир өлкәсендәге Белокорович авылында уллары Радик дөньяга килә. Бүгенге көндә әлеге авыл шәһәр статусын йөртә. Хәрби офицерларның тормышы гарнизоннан гарнизонга бик еш күченеп йөрүләрдән тора. Бертуктаусыз җирлек үзгәрә, яңа кешеләр, яңа мәктәп, яңа дуслар... Радикның әтисе белән әнисе бер авылдан булу сәбәпле, ул вакытвакыт Ирнурда дәү әнисе тәрбиясендә яши. Әлеге җирлекне ул тарихи Ватаны дип саный, аның башлангыч мәктәбендә белем дә ала. Тарихка күз салсак, биредә яшәүчеләрнең саны меңнән артмаган, халкының күпчелеге игенчелек, терлекчелек һәм умартачылык белән шөгыльләнгән. Биредән Бөек Ватан сугышына киткән 240 ир-атның 89ы гына туган җирләренә кире әйләнеп кайта, аларның да шактые җәрәхәтле. Кыскасы, хәсрәт дәрьясы...

Радикның әтисе Әбрар Бариев, әнисе Нурания һәм әтисенең абыйсы Харис

Балачак еллары. Радик апасы Нурфия белән

Радик Әбрар улы: *«Мин хәрби гаиләдә үстем. Үзем дә әлеге традицияне дәвам итәчәгемә икеләнмәдем. Ә инде бишенчедә укыганнан алып очучы булачакмын дигән хыялыма беркайчан да хыянәт итмәдем. Безнең гаиләдән әти ягыннан фронтка дүрт кеше киткән була – бабай һәм әтинең бертуган өч абыйсы. Шулардан берсе – минем бабам гына, 1943 елда каты яралар алып сафтан чыккач, хәрби хезмәтен Мәскәү тирәсендә генә дәвам итеп исән кала һәм Ирнурга әйләнеп кайта. Күңелне иң әрнеткәне – өч улы да яу кырында башларын сала. Ниләр кичергәндер, ничек түзгәндер ата-ана йөрәге?!. Әти-әни өчен шуннан да зуррак кайгы-хәсрәт була аламы икән?!. Кече уллары инде Җиңү көне килде дигәндә генә, 1945 елның 2 маенда Берлинны штурмлаганда Ватан өчен башын сала. Аңа бит ул чакта нибары 19 гына яшь була. Бабай колхозда җитәкчелектә – рәис урынбасары булып эшли. Әнием Нурания ягыннан да бабам 1943 елны Смоленск тирәсендә барган бәрелешләрдә хәбәрсез югала».*

1935 елны дөньяга килгән Әбрар, Ирнурда урта мәктәпне тәмамлагач, Томскидагы артиллерия училищесына укырга керә. Аны бетергәч, ул Пермь, Белокоро-

вич шәһәрләрендә хезмәт итә. Әбрар 1967 елда Можайский исемендәге хәрби академияне тәмамлый, шуннан соң аны Байконурга җибәрәләр, ул гаиләсе белән Ленинск шәһәрендә тора. 1955 елда туган апасы Нурфия дә, югары белем алып, Алма-Атадагы комбинатта баш экономист булып хезмәт куя. Әби-бабалары, әнисе һәм апасы бүгенге көндә безнең арада юк инде…

2006 елның сентябрендә Бәрәңге районы башлыгы Әлфит Габделхак улы Ибраев шалтырата: «Рәдиф, иртәгә ике генә көнгә Радик кайта, килеп китә алмассыңмы? Әгәр җыенсаң, иртән үк хәбәр сал, сигездән дә соңга калма, мәктәпләрдә очрашулар булачак!» – ди.

Икенче көнне мин иртә таңнан Мари Республикасына юл алдым. Район җитәкчесе белән полковник Радик Бариев хакимият бинасында көтеп торалар иде. Нык гәүдәле, урта буйлы хәрби белән аралашып китү авыр булмады. Өстәвенә, бик итагатьле булуы, күбрәк башкаларны игътибар белән тыңлавы аның тыйнаклыгына басым ясый иде. Күп афәтләр күргән, үлемне күп тапкырлар җиңеп чыккан кешеләр шулай булырга тиештер дә, күрәсең…

«Бер рәхәтләндереп ял иттерермен дигән идем үзегезне, әле тегеннән шалтыраталар, әле моннан, мәктәпләргә очрашуларга йөрербез, ахры, Радик үзе дә шулай тели. Өстәвенә, республика башлыгы, иртәгә Йошкар-Олага алып кил, безнең өчен дә зур кунак бит ул, ди. Менә шул ике көндә нәрсә генә эшләп бетәргә инде…» – дип аңлата Әлфит Габделхак улы.

Сулдан уңга: Рәдиф Сәгъди, Радик Бариев, Әлфит Ибраев. Сентябрь, 2006 ел

Сәфәребез авыл мәктәпләрендә дәвам итте. Сәхнәдә татар җырлары, татар биюләре… Радикка күз салсам, җаны-тәне белән бирелеп карый. Бик сагынган-юксынган икән ул туган җирен, тарихи Ватанын. Сүзне башта район җитәкчесе, Радикның туганнан-туган агай-энесе Әлфит Габделхак улына бирәләр. «Радик балачагыннан ук нык холыклы, максатчан, хыялчанрак иде. Башлангычта укыганда, Яңа елга чыршы кирәк дип, безне урманга ияртеп чыгып китте. Кулда – балта, кар тездән, өч чакрым барасыбыз бар… Баруын да барып җиттек, агачын да таптык, ул арада караңгы төшеп, хәерчегә җил каршы, дигәндәй, көчле буран чыкты. Арада иң өлкәне мин – дүртенчедә, Радик – икенчедә, энем Альберт исә беренчедә генә укый. Ул куркып елый, мин борчылам. Кайтыйк, әйдә, тизрәк, бүреләр килеп чыкма-

сын, ташлыйк чыршыны, дим, үзем борыла-борыла артыма карыйм. Куркудандыр инде, бөтен урман тишегеннән ерткычлар килеп чыгар кебек тоела. Өстәвенә, кире өч чакрым кайтасы бар! Радик кына: «Анда чыршыны бизәргә дип кызлар көтеп тора, мин бит аларга вәгъдә бирдем!» – дип, карга бата-чума, ике метрлы чыршыны сөйри. Аңа ярдәмгә мин дә алынам. Аның куркуын җиңә, бөтен ихтыяр көчен бер ноктага туплый ала белүе шул чакларда ук сизелә иде. Мәктәптә белем алган чорда да бөтен хыялы очучы булу иде. Радикны, яхшы укыганы өчен, башкаларга үрнәк итеп куялар, шул сәбәпле, көнчерәк малайлар, җыелышып, аны тотып кыйнаганнары да булды. Ләкин ул мәктәпне соңыннан 4,9 балл белән тәмамлады. Иң сәере шунда – тарих белән кызыксынган малайга нәкъ шул фәннән генә «4»ле куйганнар».

Бөек Ватан сугышы геройлары турында да бик күп китаплар укып, исән кайткан ветераннарның истәлекләрен тыңлап үсә кызыксынучан малай. Укыган әсәрләре арасында фантастик-хыялый романнар да бихисап. Иксез-чиксез биеклеккә омтылган малайның белем биштәрендә данлыклы очучылар турындагы китаплар. Ул Михаил Ефремов, Петр Нестеров, Константин Арцеулов, Сергей Уточкин кебек авиациягә нигез салучылар белән кызыксына. Икенче бөтендөнья сугышының очучы геройлары – Валерий Чкалов, Алексей Маресьев, Александр Покрышкин, Әмәтхан Солтаннар кебек батырлыклар кылырга тели Радик. Балачак хыяллары 1978 елда аны Качинск шәһәрендәге Югары хәрби авиация училищесына китерә. *«Беренче тапкыр самолет штурвалы артына утырып, корыч кошны буйсындырып зәңгәр күккә тәүге тапкыр күтәрелүемне мәңге онытасым юк, хәтеремә нык сеңеп калды. Балачак хыялларым тормышка аша бит! Түбәндәге кечерәеп калган күренешләргә күз салгалыйм, сокланып, тимер айгырны иярли алуыма шатланып очтым мин!»* – дип, училищеда уку чорын хәтерендә яңарта Радик. Шул көннәрдән башлап дистә меңләгән очыш ясаган ул.

1982 елда хәрби училищены тәмамлаган яшь офицерны Карпат буе хәрби округына караган 145 нче авиация полкына Иванова-Франковск шәһәренә юллыйлар. Радик Бариев 1988-1991 нче елларда Ю.А.Гагарин исемен йөрткән хәрби һава көчләре академиясендә укый. Аны тәмамлагач, очучы-сынаучылар әзерли торган Дәүләт үзәгенә билгеләнә. 1993 елда ул – очучы-сынаучы. Радикның талантын, курку белмәс ир икәнен белеп алгач, 2003 елның 267 нче Үзәкнең, ягъни ГЛИЦның башлыгы итеп билгелиләр. Хәрби хезмәт чорында кайларда гына булмый: Кавказда барган канлы бәрелешләрдә, Көньяк Осетия, Сирия һәм башка төбәкләрдәге хәрби операцияләрдә турыдан-туры катнаша ул. Атналар буе аңсыз килеш үлем белән көрәшә Радик. Аңына килеп, дөньяга күз салса, урын өстендә яткан яралы хәрбине көчкә җыйганнар икән, исән каласына да ышанмаганнар. Булачак хәләл җефете Натальясы белән дә ул хәрби госпитальдә таныша. Тора-бара ике арада көчле мәхәббәт хисләре кабынып китә. Кызның әнисе: *«Ул бит мөселман өммәтеннән, кызым, үзебезнең урыс егетләре беткәнме сиңа!»* – дип аптыраса, әтисе: *«Борчылма, кызым, яратсаң, мәхәббәтең чын булса, ике дә уйлама! Мин татарлар арасында үстем, алар кебек хезмәт сөюче, чисталык-пөхтәлек яратучы, эшен җиренә җиткереп эшләүче халык Россиядә тагын бармы икән? Булса да, ул, – әлеге дә баягы, татарлар!»* – дип, хәер-фатихасын бирә. Аягына баскан Радик кабат зәңгәр күккә күтәрелә. Шул вакыт эчендә ул Россия Герое исеменә өч тапкыр тәкъдим ителә. Икесе – хәрби операцияләрдә күрсәткән батырлыклары өчен, өченчесе...

Радик идарә иткән очкычның ракетасы тәтегә-пускка басу белән үк очып китми, шундук шартлый. Самолет меңләгән тимер кыйпылчыгы белән теткәләнеп

бетә. Гомумән, очучыларның батырлык күрсәтергә мөмкинлекләре бик еш туып тора, ә инде сынаучы очучыларның исә һавага күтәрелгән саен. Бу юлы Радик үлем белән күзгә-күз очраша… Аңа иптәшләре: «Радик, сикер, сикер!» – дип аваз салалар. Катапульта белән атылып чыгып, күпме хезмәттәшенең гарип, хәтта гомерлеккә инвалид кәнәфиенә калганлыкларын күреп белгән Бариев сикерми. Бер двигателе, ягулык үткәргече эштән чыккан, үзе каты яралы… Шулай да йөз чакрымлап араны бер двигатель белән үтеп, хәрби аэродромга төшеп утыра ул. Бәхетенә, Аллаһы Тәгалә саклап калган икән, икенче двигателе дә, ягулыгы бетеп, тынып кала. Шуңа күрә төшкәндә тигезлеген саклап калуга ирешә, югыйсә самолет «штопор»га керер иде. Могҗиза бит! Аңа бүләкләү кәгазе тутырганда санап карыйлар: Радик Бариев ил бюджетының бер миллиард доллар акчасын саклап калган икән, чөнки әлеге тимер кошлар сынау үткәндә бердәнбер экземплярда була. Шушы сынаулар, кораллы бәрелешләр, хәрби операцияләр чорында ул, әйтеп киткәнемчә, өч мәртәбә Россия Герое исеменә лаек була. Шул турыдагы документлар Мәскәүгә китсә дә, ник берсенә игътибар бирсеннәр! Алар сазлыкка баткан кебек юкка чыга торалар…

Нәтиҗәдә, туганнарын, гаиләсен, хезмәттәшләрен шатландырырмын дип йөргән батыр йөрәкле офицерның күңеле төшә. «Әллә хәрби хезмәттән китәргәме икән?..» – дигән уйлар да бик еш килгәли. Утны-суны ничә мәртәбә бергә кичкән сугышчан дусларының, әтисе Әбрар абыйның: «Ташла ул уйларыңны, мы как без тебя, сабыр булырга кирәк! Түзәргә, улым!» – дигән сүзләре аны бу адымнан туктатып кала. Радик, гарьлеген җиңеп, авыр хезмәтен дәвам иттерә.

Шундый көннәрнең берсендә ул Мәскәүдә үзенең элеккеге сугышчан җитәкчесе – генерал Шаманов белән очраклы рәвештә генә күрешә. Шунда очрашу хөрмәтенә чәйләп утырганда Владимир Анатольевич:

– Мин кул куйган Алтын Йолдызың кайда соң синең? Ник тагып йөрмисең? – дип сорап куя.

– Аннан соң тагын ике тапкыр җибәрелде, берсе генә дә бирелмәде.

Хәрби генерал, гаҗәпләнеп, ачуы чыгып сүгенеп куя.

– Радик туган, иртәгә Владимир Владимирович Путин белән күрешәсем бар, кайтып китмә, түз бер генә көн! – дип үгетли.

Шулай итеп, элеккеге хәрби җитәкчесе аны Президент белән очраштыра. Ил башлыгы:

Владимир Шаманов

– Шаманов Владимир Анатольевич Сезнең турыда бик җылы сөйләде. Монда өстә утырсак та, барысын да күреп тә, белеп тә бетереп булмый икән! Берьюлы өч Геройлыгыңны да бирә алмыйм, Радик Әбрарович, ә менә беренчесен бүген үк тапшырам! – ди, аннан сынаулы караш ташлап: – Бәлки, Герой урынына генерал погоннары алырсыз? – дип сорый.

– Гафу итегез, Владимир Владимирович, миңа, ничә тапкыр тәкъдим ителеп тә, әлеге зур бүләк бирелмәгәнгә гаиләм бик борчыла бит, кайтып аларны куандырасым килә! – ди.

Шуннан соң Президент, елмаеп:

– Бик дөрес, Радик туган! Героен алгач, генерал дәрәҗәсен генә тартып китерә инде ул! – дип, кулын кыса.

2006 елның 4 февралендә ул, ниһаять, гаиләсен куандыра. Нинди авыр, гомеренә үлем куркынычы яный торган күпме һава юллары үтелгән әлеге шатлыклы көннәргә кадәр!.. Легендар Әмәтхан Солтан да бит яңа техниканы сынаганда һәлак булган, аның кебек үк Радик Әбрар улы да үлем белән ничәмә-ничә тапкыр очраша. Очучы-сынаучылар көн саен диярлек, яңа техниканы сынау өчен, зәңгәр күккә күтәрелә бит. Двигательләрне сүндереп «штопор»ларга да китеп карыйлар, «штопор»дан чыгарып, сүнгән очкыч белән җиргә дә төшеп утыралар... Кыскасы, сынау арты сынау... Бик сирәкләр генә мондый осталыкка, кыюлыкка ия. Әле, җитмәсә, күпме стресс халәте кичерәсең!.. Хәзерге заман техникасын тиешле дәрәҗәгә җиткерер өчен, әнә шулай күпме көч, күпме сәламәтлек таләп ителә. Ә кайбер очракларда әлеге сынаулар фаҗига белән тәмамлана... Мондый самолетны җитештерү дәүләткә 100 миллион яки миллиард долларга төшә. Һәм әлеге техника бер генә данәдә була. Нәтиҗәдә, әлеге самолетны югалту техника үсешен ике-өч елга кирегә чигерә. Пилотлар, яңа очкычны саклап калу өчен, соңгы минутларына кадәр көрәшәләр, ләкин... Бариев җитәкләгән хәрби базага куелган дөньядагы бердәнбер һәйкәлдә сынаулар вакытында һәлак булган 50дән артык очучы-сынаучының исеме бар. Аларның фотосурәтләре, йөрәкне сыкратып, сиңа төбәп карап торалар. Күпме кайгы-хәсрәт китергән аларның туганнарына, дус-ишләренә...

«Командир башкаларга иң беренче үзе үрнәк күрсәтергә тиеш. Аллага шөкер, сәламәтлегем булганда очам әле», – ди Радик Бариев. Үз эшенең менә шундый фидакярләре күп булганда Россия авиация төзелешенең киләчәге бар әле. Радик Әбрар улыдай талантлы сынаучыларның булуы аркасында бүгенге көндә Россия – борыла торган двигательләр ясаучы бердәнбер ил! Мондый техника һавада хәрәкәтсез бөтерелә, спортчылар кебек, сальто-морталелар ясый ала! Һәм ул, шул темага диссертация язып, аны җиңел генә яклый. Әлеге сугышчан самолет уникаль машина булып чыга, чөнки ул бомбардировщик белән истребитель «холык»ларын бергә кушып җитештерелгән. Галәмәт зур ут көченә ия әлеге очкыч сигез-тугыз тонналы бомба һәм ракеталарны күтәреп оча һәм алар акыл белән эш итә торган гаҗәеп катлаулы кораллар. *«Безнең очучылар, чыннан да, иң тәвәккәлләр, иң яхшылар, алар эшләгәнне дөньяда әлегә башкалар кабатлый алмыйлар!»* – ди ул, горурланып.

Ә Радик Бариев – шул сирәкләр арасында һавадагы хәрби очкычны яки ракетаны («цель»не) самолет «штопор»да чагында юкка чыгара алган бердәнбер очучы.

Радик Әбрар улы – 2009 елдан алып бүгенгә хәтле В.П.Чкалов исемен йөрткән 929 нчы үзәкнең җитәкчесе. Аның кул астында 250дән артык полковник, шуларның дистәгә якыны – Россия Геройлары. Радик Бариевка 2012 елны, Президент Указы белән, генерал-майор дәрәҗәсе бирелде. Үз гомерендә ул хезмәттәшләре белән 560тан артык яңа самолетны сынап, аларны кулланылышка керткән, хәрби хезмәткә буйсындырган. Менә әлеге очкычларның кайбер төрләре: Су-17, Су-25, МиГ-21, МиГ-23, МиГ-25, МиГ-29, Су-27, Су-33, Ту-134, Як-402, Ан-26, Су-29, Су-34, Су-35...

Радик Әбрар улы 2021 елның 31 июнендә 60 яшен тутырды. *«Үткән гасырның болганчык 90 нчы елларында бер урында таптанып торган хәрби авиация үсеше*

хәзерге көндә ныклы адымнар белән алга бара. Инде ул болганчык елларда әле җирне генә саклаган очкычларның «онык»лары зәңгәр күкне иңлиләр. Әлеге чорда стимул булмау, аз хезмәт хакы, офицер гаиләләренең, тиешле шартлар тудырылмыйча, тулай торак, барак яки коммуналкаларда яшәве, балалар бакчалары һәм мәктәп белән бәйле проблемалар, ял урыннарының да йөзләгән чакрым ераклыкта булуы әлеге үсешкә гаять зур зыян салды. Нәтиҗәдә, яхшы очучылар башка хезмәткә күчәргә мәҗбүр булды, алар урынына килүчеләр кимеде. Ниһаять, дәүләт, Президентыбыз тарафыннан да әлеге проблемаларны чишүгә ярдәм кулы сузыла башлагач, яшәү шартлары да яхшыра бара, хезмәт хаклары да артты, социаль мәсьәләләр дә уңай якка хәл ителә. Соңгы вакытта гына да Актүбәдә күпфатирлы йортлар төзеп, күп гаиләләрне бәхетле иттек. Бу эш өзлексез дәвам итә. Яшәү шартлары яхшыру аркасында оста очучыларны саклап калдык, безнең хәвефле хезмәткә тартылучылар күбәйде. Ләкин сынаучы югары дәрәҗәдә булу өчен, үзенең физик формасын даими сакларга, аны ныгытырга тиеш. Безнең профессия кешеләренең бит, беренче чиратта, умыртка сөяге зыян күрә. Шуңа күрә, организмны формада тотар өчен, иптәшләрем белән көндәлек рәвештә спорт залына йөрим. Кайчагында вакыт килеп чыкса, балык тотарга яратам. Кечкенәдән яраткан шөгылем инде ул. Шунысы хәтердә: балачакта Ирнурда әбиемнең эремчек сөзә торган марлясын сорамыйча алып, Әлфит Ибраев белән балык сөзәргә киткән идек. Кайткач, тетелеп беткән тукыманы күреп, әби бәгърем әй сүккән иде дә соң! Шундый очсыз малны табуы да проблема булгандыр, ахрысы.

Очучы-сынаучыларның режимында даими тренировкалар, әлбәттә, тагын да мөһимрәк. Шунсыз булмый, югыйсә инвалид калуың да бар! Менә соңгы тикшеренүләрдән дә бик канәгать калып чыктым. Табиблар: «Җитмешләргә кадәр оча аласың әле!» – диләр. Әллә арттыралар инде! Шулай гына була күрсен! Әле дәвамчыларны аякка бастырасы бар. Хатыным Наталья белән ике чибәр кыз үстердек. Светлана белән Лилия Мәскәүдә яшиләр: берсе – психолог, икенчесе – дизайнер. Аллаһы үзебезгә малай бирмәсә дә, оныгым Денис минем эшне дәвам итә, бүгенге көндә хәрби офицер. Тагын ике оныгым Анна белән Артем да – тормышыбызның бизәге. Ике киявем дә минем кебек очучылар. Бергә җыелганда бигрәк тә рәхәт. Элек яшь чакта вокаль-инструменталь ансамбльдә гитарачы идем, аны да чирткәлим, тик андый очрашулар еш тәтеми шул. Хәрби хезмәт, иксез-чиксез күк көтә! Кабат яңа техника белән һавага күтәрелү, сынаулар, аларның җитешмәгән якларын ачыклап төзәтмәләр кертү. Бер самолетны тиешле югары дәрәҗәгә җиткерү өчен, кайчагында конструкторлар белән сынаучыларның 4-5 ел вакыты китә. Ә бит шушы хезмәткә безнең төркем 14 кеше булып килгән иде, хәзер шуларның өчесе юк инде. Шуңа күрә дә сынаучы эшенә меңләгән очучылар арасыннан сайлап алынып, 2-3 кеше генә үтә. Ә истребитель очучыларын санасак, алар бөтен илгә егермеләп кенә. Дөрес, очучылар җитәрлек анысы, ә менә очучы-сынаучылар бармак белән генә санарлык», – ди Радик Бариев.

Безнең очсыз-кырыйсыз илдә табигый байлыклар өеп бирелгән: урман һәм кырлар, елга һәм күлләр, диңгез һәм океаннар, иксез-чиксез зәңгәр күк… Ләкин безнең җәмгыятькә толерантлык җитми, ягъни кешеләрне, милләтләрне тиң-тигез күрү. Ә ул – бәхетле тормыш төзүнең иң төп нигезе. Иртәме-соңмы без ул югарылыкка да җитәрбез, чөнки тарих, бәхетсез үткәннәребез шуны таләп итә. Иң мөһиме – күгебез тыныч булсын! Радик Әбрар улы Бариев кебек бөркетләребез булганда анысына да ышаныч бар. Күкрәгендә өч урынына бер генә Алтын Йолдыз балкыса да, татар халкының да, мари халкының да легендар герое, горурлыгы ул Радик Әбрар улы! ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – язучылар, галимнәр, журналистлар, дин һәм сәнгать әһелләре март аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

1 март – балалар язучысы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1997), 1988 елдан Татарстан Журналистлар берлеге һәм 1995 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Биектау районының Мәмдәл авылы тумасы **Ләлә Нәгыйм кызы Сабирова**га (Гыймадиевага) 75 яшь (1947);

5 март – язучы, драматург, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2000), Г.Державин исемендәге әдәби премия лауреаты (2004), 1986 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Киров өлкәсендәге Омутнинск шәһәре тумасы **Лев Афанасьевич Кожевников**ка (шагыйрә һәм тәрҗемәче Роза Кожевникова-Баубекованың (1950-2007) ире) 75 яшь (1947);

5 март – рәссам, шаржлар остасы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Журналистлар берлеге һәм Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы **Зөлфәт Әнәс улы Хәйруллин**га 65 яшь (1957);

9 март – композитор, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2009), Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1979), БРның халык артисты (2017), Г.Сәләм исемендәге премия лауреаты (1976), 1974 елдан СССР Композиторлар берлеге әгъзасы, БРның Благовар районындагы Языково авылы тумасы **Рим Мәхмүт улы Хәсәнов**ка 75 яшь (1947);

12 март – артист, ТАССРның атказанган (1986) һәм ТАССРның халык артисты (1991), Әтнә районының Түбән Бәрәскә авылы тумасы **Марсель Бакир улы Җаббаров**ка 75 яшь (1947);

21 март – артист, драматург, Татарстан Республикасының халык артисты (2009), Д.Сираҗиев исемендәге (2011) һәм Т.Миңнуллин исемендәге (2021) премияләр лауреаты, Арча районының Алан авылы тумасы **Булат Нуретдин улы Сәлахов**ка 70 яшь (1952).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Безнең мирас №3 март 2022

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Дунган гаиләсе. Гөлҗә шәһәре. XIX гасыр ахыры

Кытайларның холык-табигатьләре

Боларның мөселманында да, мәҗүсиендә дә бер үк холык, бер үк гореф-гадәт. Төрләре буенча бер үк милләт. Араларында дин ягыннан күпме генә төрлелек булса да, тышкы күренешләрендә боларны мөселман, мәҗүси яки христиан дип, берсен-берсеннән һич кенә дә аерып алып булмый.

Бүгенге көндә бу хакта сөйләү дә мөмкин түгел дип уйлыйм. Кеше саны буенча Кытайда 80 миллион мөселман булса да, боларның мәҗүси кытайлардан гадәт, әхлак һәм яшәү рәвеше буенча беренче карашка ук аерылып торганнары бары тик Төркестан Кытаенда яшәүче кашгар, дунган, таранҗа һәм алтышәһәр төркиләре генә. Аларның да саны 12 миллион тирәсе булырга мөмкин. Калган-

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

нары кытайлар белән кушылып-катнашып беткән. Хәтта төркиләрнең бары төрки телдә сөйләшкәннәрендә дә кытай һәм мәҗүси гореф-гадәтләре өстен чыккан. Маньчжуриядә яшәгәннәре дә тулысынча кытайлашкан, бер генә яктан да аерылып тормыйлар.

Кытайларда бар нәрсәгә дә сәләт бар һәм бик камил дәрәҗәдә. Минем гади фикер йөртүем буенча, милли хис бөтен нәрсәдән дә мөкатдәсрәк һәм бу аларның табигатьләрендә бар. Ул озын чәчләр, ул килеш-кыяфәт, ул тырнаклар – барысы да табигатьләренең бер кисәгенә әйләнгән. Кытайның Аурупадагы хәзерге баш илчесе килеш-кыяфәтен алыштырганмы? Юк, әлбәттә. Киресенчә, милли киеме белән горурлана. (Безнең госманлы төрекләре исә Аурупада фәс кияргә оялалар, шунда ук эшләпә күләгәсенә сыеналар.) Кытай илчесе бар җирдә дә: «Мин – кытай кешесе!» – дип кычкырып тора. Кытайлардагы милли ныклык, чынлап та, мактауга лаек. Болар, исламиятне кабул иткәннән соң, беркадәр җаһилләрчә милләтпәрвәрлекләре хакына хәтта исламиятнең кайбер хөкемнәрен дә фида иткәннәр. Мәсәлән, хатын-кызларның аякларын кечерәйтүләре ислам дине нигезләренең иң мөһименә каршы килә, шуны белә торып, әлеге нигезне үз милләтләренә җаһилләрчә бирелгәнлеккә корбан иткәннәр. Андый аяк белән хатын-кыз намаз укый алмый. Тагын башка кайбер мәҗүси гадәтләре исламияткә дә кергән, хәзер дә бар, яшәвен дәвам итә.

Шул ук вакытта мөселман кытайларның дини ныклыклары да юк түгел. Мөселманлык хакына да, таләп ителсә, җаннарын фида кылырга әзер торалар. Исламият өчен канлы вакыйгалар да, дәһшәтле дип әйтерлек сугышлар да була. Вак-төяк вакыйгалар хәзерге вакытта да һәр ел диярлек булып тора икән.

1895-1896 нчы елларда салар һәм дунганнарның баш күтәрүе бары тик дин аркасында гына килеп чыккан. Мәҗүсиләр йөзләрчә мәчетне утка тотканнар. Шул ук вакытта мөселманнар күрсәткән дини бирелгәнлек һәм гайрәт хуплауга һәм мактауга лаек. Бу хәлләрне Кытай мөселманнарының сәяси тормышы һәм аның киләчәге белән бәйле җан җылыткыч хәбәрләр дип атарга мөмкин.

Пекинның якын тирәсендә йөрим-йөрим дә, кабат Пекинга әйләнеп кайтам. Ник дигәндә, Кытайда яшәгән көннәремдә, японнар белән дә, гаиләм белән дә хат-хәбәр алышу мөмкинлеге бары тик Пекинда гына бар иде. Ул көннәрдә шәһәрнең алдынгы кешеләре белән мөмкин булган кадәр танышырга, күрешеп сөйләшергә тырыша идем. Шул ук вакытта, чит ил илчелекләрендә эшләүче кайбер шәхесләр белән дә очрашып, аларның уй-фикерләрен белер өчен дә күп көч куя идем.

Беркөнне Русия илчелегенә хезмәткә билгеләнгән бер полковник җәнаплары белән күрештем, шактый фикер алыштык. Хәзер бу шәхеснең фикерләрен язып үтәм:

«Кытайның киләчәге

Аурупа аркылы төшмәсә, Кытайның киләчәге безнең өчен искиткеч булачак. Бик зур тырышлык куеп эшлиләр. Нинди сугыш кораллы кирәк булса, шуны аз гына вакыт эчендә таба алачаклар, чөнки Кытай илендә акча бар. Бүген никадәр генә бурычлы булсалар да, Аурупаның акчалылар даирәсендә дәрәҗәләре бик зур. Кирәк булса, күпме теләсәләр, шулкадәр бурыч ала алачаклар. Ләкин хәзер боларның читтән бурыч аласылары килми, эчке бурычлану белән чикләнергә телиләр. Сәүдәгәрләрен күндерә алсалар, дөресрәге, Шанхай белән Тензин эчке бурычлануны кабул итсә, Кытай хөкүмәте читтән бурыч алуның кирәген күрмәячәк.

Нигездә, шул ике шәһәр сәүдәгәренең ризалыгын алу иң мөһим мәсьәлә булып торган. Инде хөкүмәт бу ихтыяҗын кабул иттерү алдында тора. Ризалык алынганнан соң, 400-500 миллион күләмендә эчке бурычлану, һичшиксез, гамәлгә ашачак.

Бүгенге көндә инде нык тәртипкә салынган һәм яңа кораллар белән коралланган 400 мең кешелек гаскәре бар. Әгәр бу эчке бурычлану тормышка ашса, бер миллион кешелек гаскәре булачак. Ике-өч елга да калмаячак, мотлак, бу хәл булачак. Аннан соң инде кытайларның Япония һәм Русия өчен гел куркыныч тудырып торачаклары ачык билгеле. Моннан тыш, Кытайдагы хунхузлар да гел гаскәр хезмәте күрсәтеп тора алалар, боларның коралга булган осталыклары табигый сәнгать дәрәҗәсенә җиткән. Яңа коралларны кулланырга бары бер-ике ай өйрәтү җитәрлек булгач, бу милләт гаскәри булып туган дип әйтми хәлең юк.

Кытайларда, гомумән, сәнәгатькә сәләт бик көчле. Бүгенге көндә бөтен тимер юлларда эшләүче эшчеләр һәм хезмәткәрләр – барысы да кытай кешеләре. Аурупаның бөтен илләрендә диярлек кытай студентлары һәм офицерлары белем ала. Ун елдан соң югары уку йорты тәмамлаган белгечләр Кытайда 30-40 мең кешене тәшкил итәчәк. Хезмәткәрләр барысы да уку йортларыннан белем алып чыккан ватанпәрвәр кешеләрдән гыйбарәт булачак.

Соңгы елларда бары тик Япония уку йортларында гына да ун меңләп кытай студенты укый. Болар, укуларын тәмамлап Япониядән киткән көннән башлап ук, берсе дә калмыйча, япон дошманына әвереләләр. (Безнең Русиядә укып белем алган болгарлар кебек.)

Болардагы кадәр милләткә үтә бирелгәнлек беркемдә дә юк. Бүгенге көндә христиан кытай кешесенең саны ике-өч миллионлап бардыр. Әмма милләт өчен берәр төрле хәрәкәт башлана калса, иң беренче булып христианнарга һөҗүм итәчәк кешеләр дә нәкъ менә шулар. Хәзерге вакытта мөселманнар белән мәҗүсиләр арасында эчке фетнәләр булса да, өч көн дә үтмәс, болар да чит дошманга каршы бер йодрык булып берләшәчәкләр. Кирәк булса, Аурупа каршысына ун миллион сугышчысы булган гаскәр чыга алачак. Боларның гаскәре өчен тик корал гына кирәк. Ризык кирәкми, чөнки нәрсә тапсалар, шуны ашыйлар. Берни дә тапмасалар, үз мәетләрен дә ашарлар, чөнки үлем белән яшәү арасында әллә ни аерма күрмиләр. Кыскасы, безнең руслар Байкалның бу тарафында үз мәнфәгатьләрен тәэмин итә алмаслар кебек күренә. Бу якларда тотылган бөтен чыгымнарыбыз безнең өчен зыян гына. Тик, кытайларның үз араларында күренгән төрлелек, нәтиҗәдә бүлгәләнүгә хезмәт итеп, көньяк Кытай белән Маньчжурия арасында сугыш китереп чыгарса, Монголия белән Маньчжуриянең бер өлеше безгә сыеначак. Менә шулвакыт без Кытайда рус мәнфәгатен тәэмин итә алыр идек, тик ул бик якында күренми әлегә. Шулай булса да, ихтималы бар, бераз тырышлык кына кирәк.

Кытайда икътисад

Кытай милләтендә икътисад мәсьәләсе ис-акыл китәрлек дәрәҗәдә һәм бу аларның киләчәге өчен бик мөһим юл була алачак. Кытай кешесе Америкага бара, Аурупага бара – акча эшли. Тик кайда гына эшләп тапса да, бөтен тапканын Кытайда тота. Эшләп акча тапкан илендә бер тиенен дә тотмый. Бөтен кытайларда акча тоту, акча табу белән чагыштырганда, уннан дүрт дәрәҗәсендә. Моны һәрбер кытай кешесе үзенә кагыйдә иткән. Бер генә кытай кешесе дә керемен уйламыйча гына акча сарыф итми. Аннары кытайлар, гомумән, бик эшчән милләт. Моннан ун

ел элек мәмләкәтләрендә берни юк иде, бүген исә илдә эшләп чыгарылган нәрсәләргә таләп көн үткән саен арта бара. Бик күп завод-фабрикалар ачылды. Тиздән шахталар казый башлаячаклар. Тибет тауларында мәгъдән ятмалары искиткеч күп, диләр. Әфьюн да юкка чыкканнан соң, бөтен кытай халкы, зур хезмәт куеп, мәмләкәтләрен күтәрер өчен тырышсалар, һичшиксез, Аурупаның Кытайда тоткан урыны нигезенә кадәр җимерелеп төшәчәк. Дөресе белән барганда, бүген үк Кытайдан китү ягын карасак, үзебез өчен файдалы эш эшләгән булырбыз.

Дунган хатын-кызлары. Гөлҗә шәһәре. XIX гасыр ахыры

Инде моны безнең хөкүмәтебез дә аңлап алды. Узган ел һәм аннан элегрәк тә монда безнең йөзләрчә хәрби кешебез бар иде. Хәзер нибарысы егермеләп гаскәри белән берничә офицер гына калып бара. Болары да алдагы елларда моннан китәчәкләр. Әйе, китү – иң җиңеле, ике начарның бераз начары. Шунысы да бар: монда хәрбиләр тотуның чыгымы күп, мәнфәгате юк, кирәксезгә сарыф итү генә.

Кытайда диңгез көчләре

Кытай хөкүмәтендә бүгенге көндә диңгез көчләре дип әйтерлек берни дә юк. Кытайларның әлегә диңгез көчләренә ихтыяҗлары да юк дип уйлыйм. Саклануы Кытай хөкүмәте өчен үтә зарур булган берәр яр буе да юк. Никадәр яр буйлары булса да, аларның барысында да кытайларның мәнфәгате кадәр үк инглизләрнең дә мәнфәгате бар. Шуңа күрә, әлеге җәһәтләрне тулысынча инглизләргә тапшырып, билгеле бер вакытка кадәр хөкүмәт инглизләр белән дус-тату яшәргә тиеш.

Яр буйларын шул рәвешле тәэмин иткәннән соң, бары тик коры җир көчләрен тәэмин итәргә генә кирәк була. Анысының исә ике-өч ел эчендә хәл ителәчәге көн кебек ачык. Менә шуңа күрә, безнең дуслар – бигрәк тә безнең руслар өчен – Ерак Көнчыгышта сәяси мәнфәгать күзәтү – үз-үзебезне алдау, ялгыш юлдан китү дигән сүз. Безнең иң зур дошманыбыз булган Австрия Якын Көнчыгышта бөтен мәнфәгатен тәэмин итте-итүен. Тик бу хәл безнең Ерак Көнчыгышта көчсезләнгән булуыбыз аркасында гына килеп чыкты, Австрия форсаттан оста файдаланды».

Менә бу – Кытайда 12 ел яшәгән, русларның Көнчыгыштагы максатларына 20-30 ел хезмәт куйган полковникның фикере. Мин биредә үземнән берәр нәрсә өстәргә кирәк тапмадым.

Кытайда мин танышкан шәхесләрнең тагын берсе – Гамбоев. Бу кеше чыгышы буенча бурят кабиләсенә барып тоташкан монгол милләтеннән. Балачагында руслар тарафыннан Петербургка китерелгән, анда рус уку йортын тәмамлаган һәм шуннан соң Русия хөкүмәте аны Пекин илчелегенә эшкә җибәргән.

Гамбоев монда 14 ел буе кытай телен өйрәнү белән шөгыльләнгән, Кытайны аркылыга-буйга гизгән, русларның сәяси максатларында корал мисалында хезмәт иткән.

Мин бу кеше белән дә берничә тапкыр күрешеп сөйләштем һәм аннан бераз мәгълүмат алдым. Гамбоев дигән бу яшь кеше кытай телен бөтен әдәбияты белән бергә белә, ул гына да түгел, Кытай дәүләте һәм кытай милләте турында да шактый киң белем алган булуы аңлашылды. Шул ук вакытта үзенең монгол кешесе икәнен дә онытмаган, җае чыкса: «Мин – монгол», – дип әйтәчәге сүз сөрешеннән аңлашылып тора иде. Мин Көнчыгыш кавемнәре турында сүз ачкач, үзенең бурят икәнен кабатлады, аннары бурятларның мәнфәгате Көнчыгыш мәнфәгате белән бәйле булуын, бурятларның кайбер хокуксызлыклары, бигрәк тә Русия боерыгы астына кергәннән соң, халыкның бөтенләй таркала башлавы турындагы фикерләрне бик ачык итеп әйтте.

Бу кешенең фикере болайрак иде:

«Кытай хөкүмәтенең киләчәге әлегә күпме генә билгесез һәм тәрәккъые шикле булып тоелса да, сәләте мөкәммәл. Кытайда гыйлем һәм мәгарифтән башка бөтен нәрсә бар, гыйлем һәм мәгариф юлында исә хәзерге вакытта зур көч сарыф итәләр, тырышалар. Аурупаның бөтен җирендә меңнәрчә кытай студенты белем ала, инде бүгенге көндә дә төрле белем юнәлешләрендә меңнәрчә белгече бар. Бары тик Япониядә генә дә ун мең студент укып белем алган. Боларның барысы да исәпкә алынса, кытайларның киләчәге үзеннән-үзе аңлашыла. Минемчә, кытайларның киләчәге ышанычлы, тик ике шарты бар: беренчесе – әгәр бер ун-унбиш ел берәү белән дә сугышка кермәсәләр; икенчесе – миссионерларның коткысына бирелеп, үз араларында бүлгәләнә башламасалар, бу дөрескә чыгачак. Бүгенге көндә бөтен аурупалыларның бердәнбер максаты – кытайларны бүлгәләү. Моның булуы бик ихтимал. Маньчжурия үз бәйсезлеген дәгъва итсә, аннары Монголия, Тибет, Көньяк Кытай, барысы дүрт кисәк булып, үзләрен аерым итеп күрсәтергә маташса, ул вакыт монголлар Русиянең канаты астына керергә мәҗбүр калачак. Маньчжурлар – японнарга, көньяк яр буйлары французларга, инглизләргә һәм алманнарга сыеныр, Тибет берара, ихтимал, мөстәкыйль булып кала алыр, ләкин ахыр чиктә барыбер инглизләр кулына эләгер дип уйлыйм.

Шул рәвешле кытайларга һәрвакыт менә шушы ике зур куркыныч янап торачак. Бу куркынычларга дучар булмыйча, ун елны уздыра алсалар, аннан соң инде кытайлар бернәрсәдән дә курыкмаячаклар. Кытай турында минем фикерләрем менә шундый».

Гамбоев җәнаплары сүзен шуның белән тәмамлады.

Минем күзәтүләрем дә бу фикерләргә туры килә иде. Бүгенге көндә миссионерлар да әлеге фикергә хезмәт итә, Маньчжурия белән Көньяк Кытайда аеруча көчле төрлелек һәм дошманлык барлыкка килгән һәм дәвам итә. Бу яктан Кытай хөкүмәтенә ил эчендәге фетнәләр өзлексез янап торачак. Кытайларның үзләренең дә бөтен куркулары шушы сәбәпләр аркасында.

Гомумән, бөтен дәүләтләр өчен дә шулай: эчке тынычсызлык, эчке бәрелешләр

иң куркыныч һәм һәлакәткә китерә торган чир кебек. Кытайда исә бу чир бигрәк тә зур югалтуларга сәбәп булырга мөмкин, чөнки кечкенә генә бер фетнә кабынып китә калса, шул сәгате-минуты белән чит дәүләтләр килеп тыкшыначак. Боларның тыкшынырга сәбәп эзләп кенә торуларын 1900 ел вакыйгасы бик ачык күрсәтте.

Японнар белән кытайларның берләшүе

Әлеге мәсьәләнең әһәмияте шунда: ул сәяси даирәләрдә гасырның иң зур мәсьәләләренең берсе булып тора. Бу әһәмиятлелек ике җәһәттән чыгып билгеләнә ала: берсе – кытайларның киләчәгенә, икенчесе – аурупалыларның икътисади мәнфәгатьләренә бәйле рәвештә. Әлбәттә, башка җәһәтләр дә бар, әмма игътибарны күбесенчә бу икесенең җәлеп итәчәге көн кебек ачык.

Беренчедән, кытайлар белән японнарның берләшүе, японнардан бигрәк, кытайларның мәнфәгатенә хезмәт итәчәк. Ник дигәндә, бүгенге көндә кытайларның һәр җәһәттән таянычка ихтыяҗлары барлыгы бик ачык аңлашыла. Әгәр кытайлар үзләре дә бу ихтыяҗны аңласалар (аңлаган булырга тиешләр), һичшиксез, мәдәни дәүләтләрнең берәрсе белән берләшергә мәҗбүр булачаклар. Әлеге мәҗбүрилек гаять табигый һәм сәясәтчеләр тарафыннан да расланган. Шул ук вакытта берләшү киләчәктә кытайларның мәнфәгате өчен файдалы булачакмы, файдасызмы дигән сорау игътибарсыз кала алмый. Бу хакта кытайлар, әлбәттә, уйланалар иде. Гафләтләре аркасында бүген кабул итмичә, киләчәктә мондый берләшүне кирәк дип табып, тормышка ашырырга теләсәләр, ничек булачак – болар хакында да хәзердән үк уйларга кирәк булганга, һәр яклап эзләнсәләр, тикшеренсәләр, һичшиксез, японнар белән берләшүнең яхшырак булачагын аңларлар иде.

Кытайларның японнар белән берләшүе аурупалыларның Кытайдагы икътисади мәнфәгатьләренең юлын кисәр, бәлки, хәтта бөтен Көнбатыш сәясәтенә көчле йодрык булып төшәр иде. Беренче нәүбәттә Русия хөкүмәтенең тоткан урыны какшаячак. Болар турында, кытайлар белән японнардан бигрәк, аурупалылар уйланды. Шул сәбәпле Япониянең мондый берләшү адымына рөхсәт итәргә теләмәделәр, японнарга көндәш булу өчен, «Америка-Кытай берлеге» дигән мәсьәләне иҗат иттеләр. Әлбәттә, әгәр Америка белән Кытай арасында мондый берлек барлыкка килсә, аурупалыларның мәнфәгатенә бу зур мөмкинлекләр ачачак, бөтен аурупалыларның икътисади сәясәтләре ышанычлы һәм ышыкта булачак.

Әлеге мәсьәләдә Америка да бик тырышты. Американың Кытай сараена – илләр вәкиллегенә хезмәткәрлекнең ни икәнен дә белмәгән бер капиталистны илче итеп билгеләве дә шушы мәсьәләнең Америка мәнфәгатенә хәл ителүе өчен эшләнде. Ришвәтләр биреп, Кытай сараен Америка белән берләшергә күндерәчәкләр иде, тик кытайлар алар уйлаганча булып чыкмады, ул түбәнлекне кабул итмәделәр һәм Америка-Кытай берлегенә омтылыш нәтиҗәсез калды.

Американлылар биредә, ягъни Америка-Кытай берлеге мәсьәләсендә, сәясәткә җиңелсәләр дә, Кытай белән Япония берләшүенә дә, вакытлыча булса да, комачаулык иттеләр. (Барыбер үз дигәннәренә ирештеләр дип уйлыйм.)

Японнар өчен дә бу мәсьәлә яшәү мәсьәләсе дәрәҗәсендә. Әгәр Кытай-Япония берлеге тормышка ашса, бу бары тик Ерак Көнчыгыш өчен генә түгел, бөтен Көнчыгыш халыкларының сәяси тормышлары өчен дипломатиядә зур уңыш булыр иде. Ник дигәндә, ул Көнчыгышның берләшү мәсьәләсен уртага куяр иде.

Кытай дипломатларының күпчелеге бу мәсьәләдә японнар белән берләшү яклы. ■

Ислам. Дини сүзлек

Адәм

Адәм – 1. Тәүрат һәм Коръән буенча, Аллаһ тарафыннан балчыктан яралтылган тәүге кеше, беренче пәйгамбәр (галәйһис сәллам)

Аллаһының җирдә үзенең «вәкил»ен – Адәмне яралтуы турында Коръәндә берничә урында әйтелә: «Ул Адәмне туфрактан бар итте, аннан соң аңа: «Бул!» – диде һәм ул булды» (3: 52); «Иблис болай диде: «Мин аннан (Адәмнән) яхшырак: мине – уттан, ә аны кызыл балчыктан бар иттең» (7: 11); «Ул (Аллаһ) кешене судан бар итте» (25: 56); «Кешене куерып укмашкан каннан бар итте» (96: 2) һ.б.

Аллаһының кешене яралтуының максаты турында Коръән болай ди: «Кеше илә җенне халык кылмадым, мәгәр Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым. Мин кешеләрдән һич ризык теләмим, ягъни сорамыйм, дәхи Мине ризыкландыруларын да сорамыйм» (51: 56-57).

Адәм белән Хәваның җәннәттән куылуы.
Луи Огюст Гюстав Доре (1832-1883) рәсеме

Коръәннән чыгып караганда, Адәмне яралтуы – Аллаһ кодрәтенең иң югары нәтиҗәсе: җир, җирдәге бар нәрсә Адәм ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен. Аллаһ хәтта фәрештәләргә дә Адәмне олылап сәҗдә кылырга куша. Адәмнең кабыргасыннан беренче хатын-кыз – Хәва яралтылган, алардан кешелек башланып киткән.

Адәм белән Хәваның яралтылуы, оҗмах эчендә үскән агачның тыелган җимешен ашап бик зур гөнаһлы булулары турында Коръән аңлатмасы Тәүраттагыдан аерылмый диярлек. Әмма христиан дине өйрәтүендә Адәм белән Хәваның шул гөнаһысы өчен җир йөзендәге бөтен кешелек Аллаһ җәзасына дучар ителгән булса («тир түгеп эшләү», «бала тудыру газабы»), Коръәндә аларның оҗмахтан сөрелүләре белән чикләнүе турында әйтелә: «...аннан соң Раббысы аны (Адәмне) сайлап алды, гафу итте һәм туры юлдан алып китте» (20: 120).

«Ислам. Белешмә-сүзлек» китабыннан
(1993, Татарстан китап нәшрияты) алынды. ■

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре*

Әхмәдвәли Рәхими

19

Әбү Һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Бер адәм белгәненнән соралып җавап бирмәсә, Кыямәт көнне ул адәмгә утлы йөгән кидертерләр».

Укы һәм исеңдә калдыр!

20

Ибн Мәсгуд разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Аллаһ бездән ишеткән нәрсәне ишеткәненчә ирештерүче ирнең йөзен нурлы кылсын. Күп вакытта ирештерүчеләр ишетүчедән аңлырак буладыр».

Укы һәм исеңдә калдыр!

21

Габдулла бине Гомәр разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Гыйлем өч: 1) мөхкәм (ачык) Коръән гыйлеме; 2) сабит (шиксез) булган хәдис гыйлеме; 3) хәдискә, Коръәнгә мөхалиф (каршылыклы) булмаган иҗмаг, кыяс гыйлеме. Болардан башкасы диннән тыш гыйлем».

Укы һәм исеңдә калдыр!

22

Әбү Һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Бер адәм гыйлеме булмаган килеш фәтва бирсә, гөнаһысы үзенә булыр. Кем, киңәшнең дөрес түгел икәнен белә торып, ишарәт белән генә булса да, киңәшне башкача әйтсә, чынлыкта, ул кардәшенә хыянәт кылды».

Укы һәм исеңдә калдыр!

23

Госман разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Күркәм тәһарәт алган кешенең тәненнән хаталары чыгар, хәтта тырнак асларыннан да».

Укы һәм исеңдә калдыр!

24

Әбү Һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Кыямәт көнендә тәһарәт әсәреннән өммәтемнең йөзләре, аяклары нурлы булыр. «Ак йөзлеләр, ак аяклылар», – дип чакырырлар. Кемнең мөмкинлеге булса, йөз нурын арттырырга тырышсын».

Дәвамы. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

*Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтүль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.

*Текстны басмага **Айсылу Вәлиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №3 март 2022

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Тугызынчы дәрес
Адәмнең тәүбәсе. Пәйгамбәр булуы. Ширек вә потпәрәслек (потка табыну). Могҗиза

Мөгаллим: Иблиснең сөрелүе белән Адәм вә Хәваның җәннәттән чыгарылулары арасында аерма бар. Иблис тәкәбберлек кылган, Аллаһы Тәгаләгә карышкан. Аннан соң үзенең начар эш эшләвенә, гөнаһка төшүенә үкенмәгән. Икенче төрле әйтсәк, тәүбә кылмаган, шунлыктан, ул Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән мәңгегә сөрелгән. Ә атабыз Адәм белән анабыз Хәваның Аллаһы Тәгаләнең боерыгыннан чыгулары тәкәбберлек кылып карышу булмаган. Бәлки, Иблиснең сүзенә ышанып, алданып кына эшләнгән. Алар аның татлы теленә, матур сүзләренә алданып, Аллаһы Тәгаләнең әмерен онытканнар. Шунлыктан, алар да җәннәттән чыгарга мәҗбүр булганнар. Аның соңында атабыз Адәм белән анабыз Хәва үзләренең кылган эшләренә бик нык үкенгәннәр, тәүбә кылганнар. Аллаһы Тәгаләдән үзләренең гөнаһларын җуюын, икенче төрле әйтсәк, ярлыкавын үтенгәннәр. Бәндәләренә бик мәрхәмәтле булган Аллаһы Тәгалә аларның үтенечләрен, ялыну-ялваруларын, ягъни тәүбәләрен кабул иткән, гөнаһларын ярлыкаган. Атабыз Адәмне әүвәлгечә изгеләрдән кылган. Аңа үзеннән таралган кешеләрне туры юлга күндерергә, аларга үзенең боерыкларын аңлатырга, тыйган нәрсәләрен белдерергә, кыскасы, аларга юлбашчылык кылырга кушкан. Беләсезме, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бәндәләргә үзенең боерыкларын, тыйган эшләрен белдерергә кушылган кешегә кем диләр?

Шәкерт: Кем диләр?

Мөгаллим: Менә мин сезгә аны аңлатыйм. Аллаһы Тәгалә бәндәләренә бик мәрхәмәтле. Аның рәхмәтенең иге-чиге юк дигән идек. Әнә шул рәхмәте сәбәпле, Ул адәм балаларын болай юлбашчысыз калдырмаган, аларга әледән-әле юлбашчылар җибәреп торган. Ул юлбашчылар адәм балаларына Аллаһы Тәгаләнең нинди эшләр эшләргә кушканлыгын, нинди нәрсәләрдән тыйганлыгын, икенче төрле әйтсәк, аларга дин вә шәригать хөкемнәрен өйрәткәннәр. Аллаһы Тәгалә тарафыннан бәндәләргә дин вә шәригать өйрәтергә кушылган кешеләргә пәйгамбәр диләр. Менә безнең атабыз Адәм, Аллаһы Тәгаләгә тәүбә кылгач, Аллаһы Тәгалә аны үзеннән туган балаларга пәйгамбәр кылган. Аңа аларны туры юлдан алып барырга, аларга дин вә шәригать хөкемнәрен өйрәтергә кушкан.

Сезгә пәйгамбәрләр хакында тагы бераз сөйлим әле. Пәйгамбәрләр алар – безнең кебек үк кешеләр, тик бик яхшылар. Алар Аллаһы Тәгалә кушкан гамәлләрне генә кылалар, аның әмеренә бер дә каршы килмиләр. Аз-маз гына кимчелек кылсалар да, ул эшләренә үкенеп, Аллаһы Тәгаләгә кайталар. Без әүвәл

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

дә: «Иблис вә шайтаннар Адәм балаларына бик дошманнар», – дип әйткән идек бит. Шулай түгелме?

Шәкерт: Шулай, хәлфә, шулай.

Мөгаллим: Әнә шул Иблис вә шайтаннар адәм балаларын һәрвакыт котырткаңнар. Шулай итеп адәм балалары әледән-әле туры юлдан язып киткәннәр. Менә шундый туры юлдан язган кешеләрне туры юлга күндерү, онытылган дин вә шәригать хөкемнәрен яңадан торгызу өчен, пәйгамбәрләр җибәрелгәннәр. Пәйгамбәрләргә дә бөтен кешеләр иярмәгән. Пәйгамбәр үлгәч, халык тагы туры юлдан язган, яхшы-начарны бер дә аермый башлаган, Аллаһны да оныткан. Кояш, ай һәм йолдызларны, хәтта бәгъзе бер таш, агачларны да Аллаһы дип таный башлаганнар. Таш вә агачлардан сурәтләр ясап, шуңа гыйбадәт кыла торган булганнар. Мондый «Аллаһ» дип табынган нәрсәләрне пот, потка табынучыга мөшрик диләр. Аларны мондый нәрсәләргә табынырга шайтан котырткан, шайтан алдаган. Шунлыктан, рәхмәте киң булган Аллаһы Тәгалә, юлдан язган бәндәләрен яңадан туры юлга кертер өчен, әледән-әле пәйгамбәрләр җибәреп торган. Пәйгамбәрләр күп булганнар. Дөнья яралтылганнан бирле ничә пәйгамбәр килгәнлеген без төгәл белмибез. (Коръән Кәримдә 25 пәйгамбәр (г.с.) искә алына. – Ред.) Шунысы безгә билгеле ки: Аллаһы Тәгалә һәр кавемгә, һәр халыкка пәйгамбәр җибәргән. Аларга дин вә шәригать хөкемнәрен өйрәтә торган китаплар да биргән.

«
Кайбер халыклар пәйгамбәрләргә һаман ышанмаганнар. Шуннан соң инде Аллаһы Тәгалә, башка халыкларга, соңгы буыннарга гыйбрәт булсын өчен, аларны һәлак кылган.

Пәйгамбәрләр, Аллаһы Тәгаләнең боерыгыннан чыгып, туры юлдан адашкан халыкларны яхшылыкка, тугры юлга өндәгәннәр. Ай һәм йолдызларга, кояшка, таш вә агачларга коллык кылуның ялгышу икәнлеген аңлатканнар. Бары күк һәм җирне, бөтен дөньяны яралткан Аллаһыга гына коллык кылырга тиешлеген белдергәннәр. Пәйгамбәрләр үзләренең Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгәнлекләрен сөйләгәннәр. Күп вакыт халыклар пәйгамбәрләргә каршы төшкәннәр, алардан көлгәннәр, аларны мәсхәрә кылганнар: «Син дә бит безнең кебек үк бер кеше. Ничек син Аллаһы тарафыннан җибәрелергә мөмкин? Синең белән Аллаһы арасында ничек якынлык булырга кирәк? Пәйгамбәр булсаң, безгә пәйгамбәрлегеңнең галәмәтен күрсәт!» – дигәннәр. Моңа каршы пәйгамбәрләр пәйгамбәрлекләренең галәмәтләрен күрсәткәннәр, бәндәләрнең кулыннан Аллаһы Тәгаләнең ярдәменнән башка гына килми торган гамәлләр кылганнар. Бәндәләрнең үз кулларыннан гына килми торган, Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән генә эшләнә торган мондый эшләргә могҗиза диләр. Менә пәйгамбәрләр үзләренә ышанмаган кешеләргә могҗизалар күрсәткәннәр. Мәсәлән, кайберсе таякны елан ясаган, икенчеләре тумыштан сукырларны күрә торган иткән. Шулай була торып та, кайбер халыклар пәйгамбәрләргә һаман ышанмаганнар. Шуннан соң инде Аллаһы Тәгалә, башка халыкларга, соңгы буыннарга гыйбрәт булсын өчен, аларны һәлак кылган. Киләчәктә мондый һәлак кылынган халыклар хакында сүз булыр әле.

Текстны басмага ***Мәдинә Әбделганиева*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №3 март 2022

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

РӘФИКОВ СӨББУХ (1913-1971)

Татар язучысы. 1913 елның 15 июлендә Татарстанның Сарман төбәгендәге Нөркәй авылында туган.

1937 елның 17 октябрендә аны, террорчы, диверсант, дип, гаепсезгә кулга алалар. 1938 елның 12 маенда ул, мәхкәмә карары белән, 10 елга иректән һәм биш елга хокуклардан мәхрүм ителә. Сөббух Рәфиков иреккә чыга, ләкин 1951 елда кабат кулга алынып, Красноярск краена сөрелә. Ул тагын 7 ел төрмәдә интегә. Сталин үлгәч, 1957 елда аклана. Сөббух Рәфиков 1971 елның 21 ноябрендә вафат булды һәм Зәй шәһәренең татар зиратына җирләнде.

РӘХИМ ГАЛИ (1892-1943)

Татар язучысы, тәнкыйтьче, тәрҗемәче. 1892 елның 4 ноябрендә Казанда туган. 1927 елда Иске татар имлясын яклап Сталинга язылган хатка имза куя.

1930 елда аңа ике тапкыр суд була. Гали Рәхим 1932 елның 11 маенда ОГПУның махсус коллегиясе тарафыннан 5 елга лагерьга җибәрүгә хөкем ителә. Беломорканал төзелешендә катнаша.

1937 елның июлендә Гали Рәхим кабат кулга алына. Ике еллап төрмәдә тоткач, аны 1940 елда 8 елга хезмәт белән төзәтү колониясенә озаталар. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, ул 1943 ел башында вакытыннан алда иреккә чыгарыла. Гали Рәхим шул ук елның 3 мартында Казанда вафат була.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

САТТАР РӘХИМ (1912-1943)

Татар шагыйре, кормашчы-җәлилче. 1912 елның 15 августында Башкортстанның Чишмә төбәгендәге Түбән Каҗәт авылында туган.

Десантчы буларак, ул күп кенә хәрби операцияләрдә катнаша, чолганышта калып, әсирлеккә эләгә. 1943 елның гыйнвар уртасында Рәхим Саттарны, А.Алиш, Ф.Булатов, Г.Шабаев белән бергә, Берлиндагы «Идел-Урал» газетасына эшкә алалар. Рәхим Саттар, шуннан файдаланып, әсирләр лагеренда һәм мәгълүм «Идел-Урал» легионында фашистларга каршы өндәмәләр язуда һәм аларны бастырып таратуда актив катнаша. 1943 елның июнь аенда ул корал тотып һәм үзе белән дүрт легионерны да ияртеп, фронт сызыгына таба китә. Ләкин бу төркем фронт сызыгы аша үтә алмый. Чикне чыкканда алар Совет Армиясенең махсус отрядына юлыккан һәм һәлак булган дигән фараз бар.

ОЛЬГА САНФИРОВА (1917-1944)

Хәрби очучы, капитан. Советлар Союзы Герое. Ольга Санфирова (Ләйлә Александр кызы Санфирова) Самара каласында керәшен гаиләсендә туган.

Ольга Санфирова 1944 елның 13 декабрендә сугышчан заданиене үтәп кайтып килгәндә һәлак була. Гродно шәһәре каберлегендә җирләнгән. 1945 елның 23 февралендә аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Самарадагы бер урам аның исемен йөртә.

СӘЛАХОВ ИБРАҺИМ (1911-1998)

Татар язучысы. 1911 елның 30 августында Казакъстанның Күкчәтау шәһәрендә һөнәрчеләр гаиләсендә туган.

Ибраһим Сәлахов 1937 елның 25 октябрендә кулга алына. Ул байтак еллар дәвамында (1947 елның 25 октябренә кадәр) зинданда җәфа чигә. Ибраһим Сәлахов 1956 елның 25 апрелендә акланып, иреккә чыгарыла. Ул 1998 елның 7 июлендә вафат булды һәм Күкчәтау шәһәре янындагы Кызыл Яр авылы зиратында җирләнде.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Игелекле эшкуар Эдуард хаҗи Ганиев ядкяре

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә, «Безнең мирас» редакциясе белән берлектә, заманыбызның аталы иганәчесе, эшкуар, галим, РФнең Электротехник фәннәр академиясе академигы, РФнең атказанган машина төзүчесе, «ГЭКСАР» электротехника заводының генераль директоры Эдуард Әнвәр улы Ганиевнең (1952-2019) якты истәлегенә багышланган «түгәрәк өстәл» утырышы узды. Анда яңгыраган фикерләрне сезнең игътибарга да тәкъдим итәбез.

Ильяс хәзрәт Җиһаншин:

«Ак бай»ларыбызның чын варисы иде»

– Татар дөньясында Эдуард хаҗи Ганиевне белмәгән кеше бик сирәк иде. Ул милләткә чын күңелдән, тугры хезмәт итүе, нинди мәсьәлә белән барсаң да, аны хәл итү юлларын эзләп таба белүе, киң күңеле белән аерылып торды. Кешеләрне, милләттәшләрен ул ихлас яратты, шуңа күрә аның үзен дә хөрмәт иттеләр. Безнең өчен Эдуард хаҗи Ганиев заманында милләтебезне мәгърифәти югарылыкка күтәргән «Ак бай»ларыбызның чын варисы иде.

Татар сәүдәгәрләре һәм сәнәгатьчеләре революциягә кадәр ислам дине кануннары белән яшәүче дини кешеләр була. Аларның мөселман диненә ихлас бирелгәнлеге төрле гамәлләрендә һәм тормыш рәвешләрендә чагылыш таба. Мәсәлән, Акчуриннар, үзләренең ата-бабалары каберләреннән тыш, мөселманнарның изге саналган каберлекләрен дә күңел җылысын биреп карый торган булганнар. Мөхәммәтҗан Галиев тә Яңа Татар бистәсе зиратын карап торучы була. Татар эшкуарлары, ислам таләпләрен үтәү йөзеннән, җирле мөселманнарның хаҗга баруларын да оештыра. Мәчет-мәдрәсәләребез дә татар байлары акчасына төзелә һәм яшәешләре дә алар тарафыннан тәэмин ителә. 1853 елда Сембер сәүдәгәре Курамша Абдулла улы Акчурин губерна үзәгендә мөселманнар өчен таштан мәчет салдыра.

Татар байлары дин әһелләренә ихтирамлы мөнәсәбәттә булып, танылган кешеләр, галимнәр белән еш очрашып торганнар. М.Галикәев Мәрҗани хәзрәтләренең ярдәмчесе-мөриде була. Шиһабетдин Мәрҗани гомеренең соңгы елларында, фабрикант Алиевлар чакыруы белән Сембергә килеп, аларда кунакта була. Хәсән Акчурин танылган мөселман фәлсәфәчеләре, дин һәм сәясәт эшлеклеләре белән аралашып яши. Әлеге аралашу һәм бергәлек Идел буе һәм Урал төбәге мөселман мәхәлләләре тарихында гаять мөһим роль уйный.

Аллаһ ризалыгы хакына башкарыла торган эш берничә юнәлештә алып барыла. Беренчедән, эшкуарлар үзләре яшәгән мәхәлләне игътибар үзәгенә алып, сәүдә-сәнәгать эшчәнлегеннән кергән акчаның бер өлешен шуңа иганә кыла. Икенчедән, туып-үскән төбәгендәге мөселманнар тормышы белән даими кызыксынып яши, якташлары турында кайгыртуны изге эшләрдән саный. Өченчедән, күпмедер байлык туплаган сәүдәгәр яки фабрикант бөтен Россия империясе буйлап таралган татар мәхәлләләренә булышып яшәргә тырыша. Алар читтәге мөселманнарның матди һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатыннан уңышлы эш алып баралар. Дүртенчедән, капиталының саллы бер өлешен татар мәдәнияте һәм мәгарифе үсеше өчен васыять итеп калдыра. Моның иң матур үрнәген Әхмәд бай Хөсәенов мисалында күрәбез.

Эшкуарлар тарафыннан ярдәмнең берничә төре күрсәтелә. Беренчесе – мәчет-мәдрәсә төзү. Икенчесе – Россия күләмендәге төрле хәйрия акцияләрендә катнашу, тупланган малдан зәкят бирү. Өченчесе – татар сәүдәгәрләренең дин әһелләре гаиләләре белән туганлык мөнәсәбәтләре корырга омтылуы. Байның үз кызын мул-

ла егетгә кияүгә бирүе яки мулланың бай кызын алуы табигый күренеш булып, бу татар мәхәлләсендәге тормышның матди һәм мәгънәви үсешенә уңай тәэсир иткән. Әйтик, мулла булыр дип көтелгән акыллы егет – һөнәрче улы Галиәсгар Камалны бай кызы, исәп-хисап эшендә бик оста булган Бибигайшәгә өйләндерәләр. Әмма егет, белгәнегезчә, драматург булып танылa.

Татар мәчет-мәдрәсәләрендәге тормыш-тәрбия күренекле химаячеләр тарафыннан җайга салынган. Безнең мәчет һәм мәдрәсәнең дә язмышы бу җәһәттән ярыйсы гына бәхетле булган. Апанаев, Галиев, Якупов, Галикәев, Козлов кебек иганәчеләр – моңа дәлил.

Татар байларының ислам дине үсешенә булышлык күрсәтүе тарихта гына калмады. Әлхәмдүлилләһ, безнең заманда да иганәчелек традицияләрен дәвам итүчеләр бар. Алар арасында Эдуард Әнвәр улы Ганиев иң күренекле затларның берсе иде. Ул күп еллар динебез үсешенә бик зур өлеш кертте – мәчетләр төзеде, мәдрәсәләргә ярдәм итте, дини укулар үткәрде, үзенең изге гамәлләре белән зур рухи үрнәк күрсәтте. Ихлас милләтпәрвәр, тәкъва затлардан иде Эдуард хаҗи.

Эдуард Әнвәр улының хакимияткә дә сүзе үтте, җитәкчеләр белән элемтәсе яхшы иде. Берзаман Мостякта ике класслы кечкенә генә мәдрәсә ачарга уйладык. «Ачылыш тантанасына кемнәр килә?» – дип кызыксынуыма: «Кирәк булса, губернаторны да чакырабыз!» – диде. Икенче көнне губернатор килеп тә җитте. Аның җитәкчеләр белән менә шулай дусларча эшләве, мал-мөлкәтен тиешле юлга сарыф итүе милләтебезгә күп файда китерде. Ул эшләгән елларда Кулаткының үсәргә мөмкинлеге булды. Район эшкуарларына ярдәм итү, аларны үстерү аның төп максаты иде. Эдуард хаҗи Кулаткының 26 мәчетендәге һәр имамга хезмәт хакы түләп торды, машиналар алып бирде, мәхәллә тормышы белән даими кызыксынып, аларны гел кайгыртып торды.

Эдуард Әнвәр улыннан үрнәк алучылар арасында безнең мәдрәсәнең хәзерге химаячеләре дә мактауга вә хөрмәткә лаек. Ул салган юлдан Вәдүт хаҗи Вафин, Равил хаҗи Гарипов, Фәрид хаҗи Мифтахов һәм Рәшит Гайнетдинов да бара. Авыр чакларда ярдәм кулларын сузган, мәчет-мәдрәсә хәлләрен һәрдаим белешеп, ярдәмләшеп торган, иң кирәк чакларда терәк, киңәшче вә булышчы булганнары өчен аларга олы рәхмәтләремне белдерәсем килә.

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә безләргә хәерле гамәлләр, киләчәк эшләребездә уңышлар, тәннәребезгә саулык-сәламәтлек, араларыбызга татулык вә ныклык, милләтебезгә хезмәттә булып, ислам диненә тугрылык саклап калырга насыйп әйләсен. Әмин.

Данис Шакиров:

«Изге гамәлләре бихисап»

– Иганәчелек, мәчет-мәдрәсәләр төзү, газета-журналлар чыгару, гомумән, милләткә хезмәт итү мәсьәләсендә Хөсәенов һәм Акчуриннарны гына искә алыр-

га гадәтләнгәнбез. Әмма бүген дә мондый изге гамәлләр башкаручы кешеләр барлыгын онытырга ярамый. Ышанып әйтәм: Эдуард Әнвәр улы Ганиевнең ярдәмен тойган кешеләр җыелса, зур заллар тулыр иде. Аларның барысы да: «Аның янына нинди генә мөрәҗәгать белән килүебезгә карамастан, ул һәрвакыт ярдәм кулын суза иде», – дип искә ала. Эдуард хаҗиның аерым кешеләр генә белә торган изге гамәлләре бихисап. Ул мәчет-мәдрәсәләрне, дин кардәшләрен генә түгел, православ динендәгеләрне дә үзенең рәхим-шәфкатеннән калдырмады. Социаль объектларны төзекләндерү, мәчет-мәдрәсәләр, юллар төзү, милли йолаларыбызны пропагандалау – болар Эдуард хаҗи башкарган изге гамәлләрнең бер өлеше генә...

Җәлил хәзрәт Фазлыев:

«Эшкуарлар безнең милләттән булса, файда зуррак»

– Эдуард хаҗидагы энергия, изгелек һәм юмартлыкны бәяләп бетерә торган түгел. Аның татар дөньясына кылган игелеге чиксез. «Байларга җәннәткә керү дөягә энә күзеннән үтүгә караганда да авыррак», – дигән тирән мәгънәле гыйбарә бар. Байлык – зур җаваплылык. Үз бизнесын булдыра ала торган кешеләр, мәдрәсәдә

Шәкертләр Эдуард Ганиев рухына Коръән укый.

генә укып утырып, эшкә керешмим дисә, әлеге кәсеп белән башка дин яки милләт вәкиле шөгыльләнәчәк. Урын буш тормаячак! Белгечләр белән дә шулай. Эшкуарлар яки башка белгечләр безнең милләттән булса, һичшиксез, ислам диненә файда зуррак. Революциягә кадәр Россиядә көчле эшкуарларыбыз мәгарифне, динне үз кулларында тотканнар. Миргазиян Юныс: «Кешенең баеганыннан курыкмагыз, ул күңел ачар, өйләр салыр, әмма күңеле канәгатьләнмәс. Шулай бервакыт дингә килер...» – дигән. Аллаһка шөкер, хезер исламга тартылучы эшкуарларыбыз елдан-ел күбәя бара. Мәдрәсә бетергән шәкертләрем арасында төрле белгечләр бар: юристлар, мәктәп директорлары, табиблар... Аларның барысы да – безнең кешеләр! Әгәр бу егетләр һөнәр иясе булмаса, һичшиксез, урыннарын башка кешеләр алыр иде.

Эдуард Әнвәр улыннан: «Хәлең, саулыгың ничек? Кай җирең борчый? Нинди хәсрәтең бар?» – дип сорадыкмы икән... Ә ул, кешеләрнең хәлен аңлап, күпме ярдәм кулын сузган! Мәрхүмнең эше югалмаганын, дәвамчылары бизнесын саклаганын күреп куанып кайттым.

Мөнир Якупов:

«Туган җанлы кеше иде»

– Эдуард хаҗиның әбисе минем әбиемнең туганы. Гает бәйрәмнәре вакытында без бер-беребезне кунакка чакырып, аралаша идек. Эдуард хаҗи белән бергә печән чабып, утын әзерләвебез аеруча истә калган. Әтием – урман караучы, ә аның әтисе Әнвәр абый бездән печәнлек җирләр ала иде.

Эдуард хаҗи, Сарытауга китеп яши башлагач, һәр җомга көн кичен әти-әнисе йортына кайта иде. Соңгы елларны без шунда очраштык. Аның авыл өчен эшләгән эшләре бик күп булды. Авылга гына түгел, райондашларына изгелеге күп тиде. Эшкуарларга булышты, трактор, машина, яңа орлыклар алырга ярдәм итте... Безнең авыл мәчетен төзекләндерде, бакча торгызды, зират тирәләрен киртә белән уратып алды, аның төзеклеген кайгыртып торды, хәйрия бәйрәмнәре үткәрде.

Туган җанлы кеше иде мәрхүмкәй. Себер, Әстерхан һәм Урта Азия тарафларында яшәүче туганнарын эзләп табып, аларны үз ягына – Сарытауга җыйды. Мин аннан: «Бу сиңа нигә кирәк? Аларның ярты гомерләре шунда узган!» – дип әйткәч: «Без бит кан кардәш кешеләр, җыелып, кунакка йөрешергә тиеш!» – дип җавап бирүе хәтердә. Хәзерге көндә аның күп туганнары Сарытауда, Кулаткыда яши.

Харис Камалиев:

«Байларны милләт эшенә ничек җәлеп итәргә?»

– Бай кешеләрне ничек итеп милләт эшенә җәлеп итәргә? Агроном буларак әйтәм: кеше күңеленә орлык салырга кирәк! Күңелне йомшарта торган орлык – ислам дине. Ислам кануннары белән яши башлаган кешенең күңеле йомшара. Ул мал-мөлкәтне бакый дөньяга алып китеп булмый дип уйлана. Нәтиҗәдә, инсан тыштан түгел, ә эчтән өлгерә һәм башкаларга ярдәм итә башлый. Эдуард Әнвәр улы да кече яшьтән үк ислам тәрбиясе алып, бизнесын да алып барган, ислам дине үсеше өчен дә җигелеп хезмәт иткән. Бу – безнең өчен үрнәк гамәл. ■

Айдар иле яки Татарның Жан Габены

Ләбиб Лерон



Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Хафизов (1943-2020)

Валлаһи, дип әйтәм, хан булу аңа килешер иде. Айдар хан! Юк, бөек адашы – заманында беренче булып ислам динен кабул иткән Идел буе Болгары хакиме Айдар ханны (VIII гасыр-865) яисә «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт) спектаклендә ул башкарган Җиһангир хан ролен хәтеремдә яңартып әйтүем генә түгел бу. Чынлап та, татарның бай тарихыннан, бәһа биреп бетергесез мәдәниятеннән һәм, әлбәттә, Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Акмулла, Ш.Мәрҗани кебек мәшһүрләребезнең, Г.Ибраһимов, Һ.Такташ, Н.Исәнбәт, Ә.Еники, С.Хәким кебек классикларыбызның хәзинәгә тиң әсәрләре белән бергә, бүгенге күренекле әдипләребез иҗатыннан тирәнтен хәбәрдар булган үтә талантлы артист һәм режиссер Айдар Садретдин улы Хафизов, мәһабәт төс-кыяфәтендәге олпатлылык, вәкарьлек, затлылык, зыялылык, үз-үзен тотышы белән генә түгел, чын мәгънәсендә, бар вөҗүде белән хан булырлык шәхес иде.

Айдар абый хакында мин узган ел башында, вафатыннан соң бер ай үтәрүтмәстән үк, мәкалә язарга тиеш идем. Чөнки кызы Айсылуга (без – коллегалар, ул – «Идел» журналының русча басмасында баш мөхәррир) вәгъдә биргән идем. Бирүен бирдем, әмма, сәфәрдә еш булуым һәм кырыкмаса-кырык эш өелеп тору сәбәпле, язарга һич кенә дә җай чыкмады. Айсылуның күзенә артык чалынмаска тырышып, менә бүген язам, менә иртәгә тотынам, дип йөри торгач, елдан артык вакыт агымсу кебек «акты» да китте. Хәзер үз-үземне, күрәсең, вакыты җитмәгәндер, шулай кирәк булгандыр, дип тынычландырырга тырышам. Бәлки, шушы вакыт аралыгында мәрхүм артистка нисбәтле китапның (автор-төзүче – драматург, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Юныс Сафиуллин) дөнья күрүе, Айдар абыйның чын исеме Бәдретдин (гарәпчәдән «диннең тулы ае» дигәнне белдерә) икәнлеген белүем, артистның вафатыннан соң ярты ел узуга, сабакташы, сәхнәдәше, дусты Хәлим Җәләйнең дә «таҗлы» зәхмәт (коронавирус) авыруыннан, көтмәгәндә-уйламаганда, Айдар абый шикелле, серле рәвештә бакыйлыкка

Айдар Хафизов кызы Айсылуның (хәзерге вакытта «Идел» журналының русча басмасында баш мөхәррир вазыйфасын башкара) хезмәттәше Шамил Садыйков (бүген ул – «Татмедиа» АҖнең генераль директоры) белән бергә «Эфир» телеканалында эшләгән чагы

көчүеннән янә бер сискәнүем, шулай ук узган ел ахырында Питрәчтә Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Хафизов исемендәге театр фестивале зурлап уздырылуыннан хәбәрдарлыгым кирәк булгандыр?!.

Камал театрына берәр спектакль карарга килсәм, гадәттә, тәнәфес вакытында сәхнә артына кереп, коридорда очраган яисә грим бүлмәләрендә булган артистлар белән күрешеп чыгарга тырышам. Кайчак артистларның (гадәттә, шахмат-шашка «җене» кагылган ике ахирине – Айдар абый белән Хәлим абый Җәләйне) шахмат тактасы янында үзара көч сынашкан чагына туры киләм. Айдар абыйның кайчандыр шушы театрда гап-гади артист булып хезмәт иткән драматург Туфан Миңнуллин белән дә шахмат уйнаганы һәм аны җиңгәне булган икән. Җиңелгәненә әллә ни борчылмаган драматург, могтабәр артистыбызның беркайчан да эшсез-шөгыльсез тора алмавын фикерендә калкытып, үзенчә гомумиләштереп, болай дигән, имеш: «Нишлим икән, дип, мескенләнеп йөри торганнардан түгел бу кеше – теләсә нинди хәлдә дә үзенә шөгыль табачак!»

Шахмат турында сүз чыккач, бу урында мәрхүм Айдар Садретдин улын соңгы юлга озату мәрәсиме вакытында, үзенең вафатына да санаулы айлар гына калганын уена да китермәгән Хәлим Җәләйнең сөйләгәннәрен искә төшерергә булдым. Хәлим ага хастаханәдә яткан хезмәттәше Айдар абыйга шылтыраткан – бу аларның соңгы сөйләшүе булган. Хәлим Җәләйнең: «Ничек хәлең, Бәдретдин, җиңеллек бармы? Иркәләнеп ятма анда, тизрәк чык, сине шахматта бергәләп уйнап бетерәсе партия көтә! Теге көнне син җиңгән идең, бу юлы мин җиңәргә тиеш!» – дип әйтүенә җавап итеп, Айдар абый: «Ярар, Җәләлетдин, уйнарбыз, син җиңәрсең!» – дигән. Инде икесе дә мәрхүм.

А.Хафизовка нисбәтле китап (автор-төзүче – Ю.Сафиуллин) тышлыгы

Шәхес хакында күбрәк беләсең, кемлеген, асылын аңлыйсың килсә, аның балачагын өйрәнергә кирәк, диләр.

1943 елның 20 маенда, ягъни Бәдретдин (сәхнә дөньясына аяк баскач, булачак артист Айдар тәхәллүсен ала) гаиләдә сигезенче бала булып дөньяга килгән

А.Хафизовның Х.Җәләй белән шахмат уйнаган мәле

А.Хафизовның әтисе Садретдин

вакытта аның атасы – Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышын исән-сау кичкән, чыгышы белән Балык Бистәсенең Чирмешән авылыннан булган Садретдин абзый – илле өч яшен, әнисе – Питрәч районының Күн авылы тумасы Зөлкагъдә Хәлиулла кызы исә кырык ике яшен тутырган була инде.

1944 ел башларында булса кирәк, тома сукыр Хәлиулла бабай беркөнне әле генә тәпи йөреп киткән оныгының битен-йөзен сыйпаштырып алмакчы була, куркудандырмы, Бәдретдин-Айдар кычкырып еларга тотына. Шулвакыт бабасы: «Тавышы көр чыга моның, югалып калмас бу!» – дип әйтеп куя.

Сабый чак, балачак, дигәннән... 1949 елгы язгы ташуның иң котырынган вакытында алты яшьлек Бәдретдин, әнисенең кер юа торган озынча калай ләгәнен көймә итеп йөзгәндә, чүттән генә батмый кала – ярый әле вакытында әтисе килеп коткара үзен!

И ул балачакта күргәннәр!..

Әлеге язгы ташудан соң күп тә үтми, йорт җиткезеп кергәч, әти-әнисенең сыер мае, йомырка сатудан җыелган акчага күрше-күләннән бурычка алып торганын да өстәп, Казан базарыннан күкеле сәгать алып кайтуы, шул сәгатьнең күкесенә кызыгып, аны башыннан эләктердем дигәндә генә, берсе өстенә икечесе куелган урындыклар җимерелеп, Бәдретдиннең идәнгә мәтәлеп төшүе, күкенең исә хәрәкәтсез асылынып калуы, малайның: «Бетте башым!» – дип, куркуыннан бәрәңге бакчасындагы бураздада качып

Кечкенә Айдар авыл малайлары арасында. Беренче рәттә (сулдан уңга): Харис, Айдар, Барый, Габдерәүф; икенче рәттә: Кашшафетдин, Фәрзетдин (Айдарның абыйсы), Барый

ятуы дисеңме, абыйлары Хөснетдин (Татарстанның халык артисты Раушания Юкачеваның әтисе) белән Фәрзетдингә (Татарстанның атказанган артисты Фердинанд Хафизовның әтисе) охшарга тырышып, төрле яфрак белән мамык кушып, шуны тәмәке итеп тартуы (кайсы малай-шалайның гына башыннан үтмәде икән бу?!) дисеңме, сигез яшендә ике зур кәбестәне, күчәннәреннән бәйләп, иңенә аллы-артлы асып, алты чакрым араны җәяү үтеп, Питрәч базарына сатарга алып баруы, көне буе аяк өстендә торып, инде караңгы төшә башлагач кына, үзен жәлләгән бер апага шуларны әллә илле тиенгә, әллә бер сумга сатып җибәрүе дисеңме...

Бабасы Хәлиулла, әтисе Садретдин кебек хезмәт сөеп үскән Айдар Хафизов, бала вакыты, яшүсмер чагы турында сөйләгәндә, мондый бер вакыйганы искә ала: *«Өебез өй рәвешенә керсә дә, әтинең тәрәзә рамнары эшләтергә, аңа пыяла сатып алырга акчасы калмаган иде. Рамсыз өйдә кышны ничек уздырасың? Фәимә апа (1932 елда туган) Себер якларына вербоваться ителеп китте. Унсигез яшьләр генә иде аңа. Ул «единовременно» дип түләнгән акчаны (ә ул акча барган җирдә яшәп китәр өчен бирелә бит инде) әтигә алып кайтып бирә дә: «Тәрәзә эшләт, әти!» – ди. Әти, боларны сөйләгәндә, кинәт саркып чыккан яшьләрен сөртергә онытып: «Менә бит кыз бала башы белән өебезне тәрәзәле итте Фәимәбез», – дип елмаер иде. Аның яхшылыкка булган мондый мөнәсәбәте бәгыремә үк үтте. Үземнең дә шундый игелекләр эшлисем килде. Апага бирелгән акча рамнарның бер генә катын эшләтергә җиткән, шуңа салкын кышкы көннәрдә өебездә җылы бик тормый иде. Берничә ел әнә шулай туңып, салкыннарда мич ярылырлык итеп ягаяга яшәдек. Тәрәзәнең биштән дүрт өлешен ылыс белән сипләп менсәк тә, җылы җитми иде. Әти, туңган саен: «Их, ике кат рамы булса, бу кадәр ягуга өебез май кебек булыр иде!» – дияр иде...»*

Хафизовлар гаиләсенең төп нигезе

Безнең мирас №3 март 2022

Ният иткән – морадына җиткән, дигәндәй, бишенче сыйныфта укыганда, урындык-мазар ясарга өйрәнгән, инде столяр булам дип хыяллана башлаган Бәдретдин, ничек итсә-итә, өйләренә тәки икенче кат рам куя бит: *«Беренче эшләгән рамымны тәрәзә уентыгына урнаштыра башлауга, әни, күреп алып: «Кай арада ясадың син моны, йа Рабби, улым, атаң күрсә, башыңны өзә бит, ник сорамый-нитми генә тотындың соң?!» – диде. Ул арада капкадан әти керде, мин, куркып, урамга шылдым. Әти әнидән сорый икән: «Бу нинди рам? Кайсы остадан ясатып алдыгыз? Күпмегә килештегез? Акча юк бит, көтәргә ясадымы соң?» Әнинең: «Малаең эше», – дигәнен әти шаяртуга гына юрый: «Үзе ясады, димәкче буласың алайса? Тәк-тәк, кайда соң малай үзе?!»*

«Шуннан, әни, шуннан соң әти ни әйтте, ярый, башкаларына да ясасын, димәдеме?» – дим, түземсезләнеп. Әни үзе бик теләп сөйләп бирә: «Ак димәде, кара димәде, рамга бик озак карап утырды, ошаткан кебек булды», – ди. Миңа шул гына кирәк тә, дәшмәү – ризалык билгесе...»

Җиденче-сигезенче сыйныфларда укыганда Бәдретдин авыл көтүен көтәргә алына: *«Әти мине иртәнге сәгать өчтә уятырга кирә. Әле көтүне көтә башлаган чакта, чынықмаган гәүдәм тәмам ватылып бетә иде. Мин, елар дәрәҗәгә җитеп, урынымнан тора алмый интегәм. Тора-бара күнегелә, чыныгыла. Тәки көтүне көтеп чыктык. Акчама беренче сатып алып кайткан әйбер «Шуйский» дигән хромка гармун булды. Бераздан велосипедлы да булдым...»*

Шуннан соң, кем әйтмешли, инде буй җиткән, чын мәгънәсендә хезмәт белән чыныккан, гармун уйнарга өйрәнүе киләчәктә бик ярап куячагын башына да китермәгән егетебез олы юлга сәфәр чыга...

Айдар Хафизовның башта Васильево бистәсендәге техникумның автомеханиклар әзерли торган бүлегендә укырга ниятләп тә, көтмәгәндә-уйламаганда, Юдинодагы тимерьюл училищесына укырга керүе, анда төзүче-монтажчы һөнәрен үзләштерүе, Тимерьюлчылар мәдәният сараенда гармунчы-баянчы булып эшләве, шулай ук кинәт кенә Казандагы театр училищесына укырга керүе – болар барысы да аңа ул вакытларда Аллаһы Тәгалә бүләк иткән – язмышында тирән эз калдырган вакыйгалар.

1961 елның 1 декабрендә ул Наил Шәйхетдинов, Хәлим Җәләй, Наил Әюпов белән бергә Театр училищесында укый башлый. Остазлары – Ширияздан Сарым-

Театр училищесында бергә укыган өч талант (сулдан уңга): Наил Әюпов, Хәлим Җәләй, Айдар Хафизов

Театр училищесында очрашу истәлеге: уңнан икенче – Илһам Шакиров, Рабит Батулла, Равил Фәйзуллин, Айдар Хафизов

саков (курс җитәкчесе), Габдулла Шамуков, Шәүкәт Биктимеров, Хөсәен Уразиков, Әнвәр Бикчәнтәев, Вахит Хаков, Татьяна Геллер, Анна Гацулина һ.б. Тик икенче курстан укуын ташлап торырга язган була Айдарга…

1963 елда берара җырчы һәм композитор, хор җитәкчесе Сара Садыйкова белән бергә «Спартак» комбинатының Горький исемендәге клубында концертмейстер булып эшләп алу, шуннан соң Польшада армия хезмәтендә булу, аннан кайткач, ягъни 1968 елда кабат Театр училищесында уку (булачак хатыны Фәридә Ибраһимова, Илдар Хәйруллин һәм Фәрит Мәмәш белән бергә), өйләнү, Филармониядә, шулай ук Күчмә театрда эшләп алу, 1969 елда олы кызы Ләйсән туу, 1970 елда Казан университетында студентлар белән бергә «Сакла, шартламасын!» (К.Тинчурин) спектаклен кую, шул елларда Илһам Шакиров, Җәваһирә Сәлахова кебек күренекле җырчылар, нәфис сүз остасы Айрат Арсланов, баянчы, композитор Марс Макаров, шагыйрьләр – Равил Фәйзуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов белән аралашу, 1974 елда икенче кызы Айсылуның дөньяга килүе – болар киңкырлы талант иясе Айдар Хафизов биографиясенең хәтердә уелып калырлык сурәтләре…

Шулай да Айдар Хафизовның, язмышында кискен борылыш ясап, гомерен Олы Иҗатка тулаем багышлавы аның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли башлау чорына туры килә. 1969 елдан башлап ул алтмыштан артык спектакльдә уйный. Айдар Хафизов башкарган рольләр арасында кемнәр генә юк: Гариф («Туган туфрак», С.Шәкүров, 1969), Сәяр («Әни килде», Ш.Хөсәенов, 1970), Газраил («Әлдермештән Әлмәндәр», Т.Миңнуллин, 1978), Имаметдин («Кичер мине, әнкәй!», Р.Батулла, 1979), Ланфредини («Моңлы бер җыр», Т.Миңнуллин, 1981), Камали («Бәхетсез егет», Г.Камал, 1984), Якуб Акчурин («Без китәбез, сез каласыз», Т.Миңнуллин, 1986), Дәрвиш («Ай тотылган төндә», М.Кәрим, 1988), Листунов («Ат карагы», Т.Миңнуллин, 1989), Җиһангир хан («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт, 1990), Мостафа («Зөләйха», Г.Исхакый, 1992), Кадыйрбирде («Идегәй»,

Ю.Сафиуллин, 1994), Тимуш («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин, 2000), Зәйнулла («Арбалы хатыннар», З.Зәйнуллин, 2010), Алтын хан («Хан кызы Турандык», К.Гоцци, 2012), Әбделхан («Мәңгелек буран», Ч.Айтматов, 2018) һәм, әлбәттә, Г.Тукай премиясе лауреаты, язучы М.Хәсәновның «Язгы аҗаган» романы буенча куелган телевизион спектакльдәге Иргали, шулай ук бөтен татар дөньясын шаулаткан Мөхәммәдьяр образлары («Мөхәммәдьяр», драматик поэма, Ф.Яхин).

Артист Айдар Хафизовның үзенә бирелгән рольләрен ничек башкаруы турында сәхнәдәше Равил Шәрәфидән дә оста итеп әйтеп булмастыр. Менә нәрсә дигән иде ул: *«Артист буларак Айдарның иң кирәкле сыйфаты – персонаждан читкә-чатакка китмичә, төп үзәген табып эзләнүендә һәм аны бернинди хилафлык китермичә гәүдәләндерүендә. Кемне уйнаганын белеп эш итә. Артистка тагын бик кирәк нәрсә – күз. Күз карашы дисәк, дөресрәк булыр. Бернәрсә аңлатмый торган күз карашлы артистлар була. Ул, сиңа карап торса да, сине күрми. Ә менә Айдарның һәр персонажында шул персонажга гына хас күз карашы белән очрашасың. «Хуҗа Насретдин»дә мин – Хуҗа, ул Хан иде. Халыкка беренче спектакльне уйныйбыз: Айдарның күзләренә карыйм, куркып киттем, миңа ерткыч Аксак Тимер үзе карап тора кебек тоелды... Айдар – татарның Жан Габены булып танылырлык артист!»*

А.Хафизов Мөхәммәдьяр образында

Айдар Хафизов хакында сөйләгәндә, аның яшьтәше (икесе дә 1943 елда туган) – Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин белән җандаш дуслар булуын әйтми мөмкин түгел. 1999 елда бу ике ахиригә Кырымда сәяхәттә булырга, Бакчасарайдагы атаклы Чуфут-Кала (яки Җефет-Кала, Кырык Үр) түбәсенә күтәрелергә туры килә. Үзләренең дуслыклары хакында Равил ага болай дип сөйләгән иде: *«Кан кардәшләр дә түгелбез, туган җирләребез дә кайсы кайда, мәгәр туганнардай якынлык бар бездә. Бу ерак бабаларыбыздан, әлегә ачыкланмаган нәсел чыгышыбыздан киләдер, бәлки, дип тә уйлыйм. Монысы, әлбәттә, туган төбәгебез якынлыгына ишарә кылып фаразлау».* Чынлап та, Айдар абыйның әнисе ягыннан Хәлиулла бабайның – Балык бистәсендәге Чирмешән авылыннан, ә Равил Фәйзуллинның исә шул ук районның Балтач (Юлсубино) авылы тумасы икәнен искә төшерсәк, олуг Артист белән Шагыйрьнең нәсел җепләре бергә тоташкан булу ихтималын күрербез.

Равил Фәйзуллин «Казан утлары» журналында егерме биш ел буе баш мөхәррир булып эшләгән чакта, яшьтие Айдар Хафизов режиссурасы ярдәмендә, журналның дүрт-биш юбилей кичәсе һәм үзенең берничә юбилее тиешле югарылыкта билгеләп үтелде. Әйтик, шулардан берсе – 2012 елда «Казан утлары»ның 80 еллыгын Камал театры сәхнәсендә билгеләп үткән чарада Айдар Хафизовка – режиссер, мин фәкыйрегезгә исә сценарий авторы буларак катнашырга туры

А.Хафизов (рәсемдә арткы рәттә) сәхнәдәшләре – Х.Мәхмүтов, Н.Шәйхетдинов, И.Мәхмүтова, Ю.Сафиуллин, И.Мәсгутов белән хаҗ сәфәрендә. 2007 ел

килгән иде. Шөкер, ашык-пошык, ордым-бәрдем эшләргә күнекмәгән Айдар абый белән бергәләп, сәхнәдән әйтеләсе һәр җөмләне кат-кат тикшереп, җеген-җеккә китереп, тамашачыга югары кимәлдәге затлы кичә тәкъдим итә алдык.

Айдар Хафизов татар мәдәниятендә, аерым алганда, театр сәнгатендә һәм әдәбиятта үзенең үзенчәлекле сәхнәви уеннары, сыйфатлы, мәгънәле, күркәм нәтиҗәле эш-гамәлләре белән башкалардан аерылып торган, халкым өчен дип янып-көеп яшәгән, талантын, бар көчен бары тик милләткә хезмәт итү юлында сарыф иткән асыл шәхесләребездән иде.

2007 елда үзе шикелле үк киң танылу алган артистлар Наил Шәйхетдинов, Идрис Мәсгутов, Юныс Сафиуллин, Исламия Мәхмүтова, Хәлил Мәхмүтов белән бергә хаҗ сәфәрендә булып кайткан дин кардәшебезнең гомеренең соңгы елларында табигатькә, җиргә тагы да якынаюы, Аллаһка сыенып, аның һәр бирмеш көненә шөкер кылып яшәве, туган авылындагы төп нигез урынында яңа йорт җиткезүе, умарта тота башлавы, әти-әнисе, туганнары җирләнгән авыл зиратына барып, Коръән Кәрим укып кайтуы, атна саен диярлек Күн авылы мәчетендә мәрхүм мәзин бабасы кебек азан әйтүе – аның бәрәкәтле тормыш белән яшәвенә янә бер дәлилдер.

А.Хафизовның әнисе Зөлкагъдәгә 100 яшь тулуны билгеләп үткән чак. 2001 ел

Ни кызганыч, 2020 елның 13 декабрендә аяусыз үлем аны – Олпат Артистны, милли-мәдәни дөньяда чын мәгънәсендә Айдар илен булдырган татар Жан Габенын безнең арадан алып китте... ■

Истә, һаман да истә!

Хәрби эшлекле Якуб Чанышевның тууына 130 ел

Генерал-лейтенант, совет хәрби эшлеклесе Якуб Җиһангир улы Чанышев 1892 елның 10 (кайбер чыганакларда – 12) мартында Уфа губернасының Стәрлетамак өязендәге Тукай авылында туган. Ул Алтын ятмалары хуҗалары Рәмиевләрнең якын туганы була. Казанда Татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. Якуб Чанышев гомеренең 45 елын хәрби хезмәткә багышлый, өч сугышта катнаша.

1937 елның 13 маенда Ташкентта кулга алына. Аны троцкийчы оешмада катнашуда гаеплиләр. Идел буе хәрби округының 1939 елның 1-4 декабрендәге хәрби трибуналында үз гаебен танымый. Нәтиҗәдә, хәрби мәхкәмә аны аклау карарын чыгарырга мәҗбүр була.

Шуннан соң Якуб Чанышев, Бөек Ватан сугышын кичеп, Берлингача барып җитә. Генерал 1958 елда отставкага чыга.

Якуб Чанышев 1987 елның 6 ноябрендә Мәскәүдә вафат булды.

Язучы Галимҗан Ибраһимовның тууына 135 ел

Язучы, галим, дәүләт эшлеклесе, Хезмәт Батыры Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов 1887 елның 12 мартында Уфа губернасының Стәрлетамак өязендәге (хәзер Башкортстанның Авыргазы районына карый) Солтанморат исемле татар авылында туган. 1912 елның маенда Г.Ибраһимов үзенең тәүге зур әсәрен – «Яшь йөрәкләр» романын язып тәмамлый һәм аны 1913 ел башында бастырып чыгара.

Галимҗан Ибраһимов, саулыгы какшау сәбәпле, гомеренең соңгы ун елын Ялтада уздыра. 1937 елның 29 августында ул Ялтадагы йортында кулга алынып, авыру хәлендә этап белән Казанга озатыла һәм Плөтән төрмәсенә ябыла. Аны троцкийчы контрреволюцион оешма төзеп, Сталинга һәм совет-партия җитәкчелегенә каршы һөҗүм әзерләүдә гаеплиләр.

Г.Ибраһимов 1938 елның 21 гыйнварында төрмә хастаханәсендә вафат була. Әдип Казанның Архангел зиратында җирләнгән дигән фараз бар.

Җәмәгать эшлеклесе Габдулла Апанаевның тууына 160 ел

Җәмәгать һәм дин эшлеклесе, меценат, публицист, педагог һәм нашир Габдулла Габделкәрим улы Апанаев 1862 елның 15 мартында Вятка губернасының Малмыж өязендәге Сосна авылында (хәзерге Балтач районына керә) туган. Ул Шиһабетдин Мәрҗанинең яраткан шәкерте була. Габдулла Апанаев 1906 елның 1 февралендә «Азат» газетасының беренче санын, нашир буларак, бастырып чыгара.

Аның шәкертләре арасында Нәҗип Думави һәм Гаяз Исхакый кебек шәхесләрнең булуы үзе генә дә күпне сөйли.

Габдулла Апанаевның гомере фаҗигале төстә өзелә: 1919 елның 25 июнендә ул, М.Вахитовны үтерүне оештыруда гаепләнеп, кызыл гаскәрләр тарафыннан атып үтерелә.

Композитор Мансур Мозаффаровның тууына 120 ел

Композитор, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1950), Татарстанның халык артисты (1964), Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1959) Мансур Әхмәт улы Мозаффаров 1902 елның 18 (кайбер чыганакларда – 6) мартында Казанда туган. Әнисе – танылган шагыйрә, кызлар мәктәбенең мөгаллимәсе Маһруй Мозаффария. 1945 елда Казан консерваториясе ачылу белән, Мансур Мозаффаров анда гомеренең соңгы көннәренә кадәр укыта. Композитор 1939 елда беренче операсын – «Галиябану»ны, 1943 елда исә икенчесен – «Зөлхабирә»не иҗат итә.

С.Хәким, М.Мазунов, Ә.Ерикәй, М.Җәлил, М.Садри кебек күренекле шагыйрьләрнең шигырьләренә көйләр язган М.Мозаффаров 1966 елның 20 ноябрендә вафат булды һәм Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнде.

Китапчы-рәссам Мөхәммәд Идрисинең тууына 140 ел

Китап басу остасы, китап бизәүче, картограф, каллиграф, беренче профессиональ татар рәссамнарының берсе, СССРның күпчелек төрки халыкларына басма шрифтлар ясаган Мөхәммәд Ибраһим улы Идриси 1882 елның 19 мартында туган.

Ул – география һәм арифметика дәреслекләре, графиканы бердәм калыпка салу турындагы китап авторы. «Аң» журналында аның Мөхәммәд Идриси псевдонимы белән хикәяләре басыла.

Мөхәммәд Идриси 1935-1936 нчы елларда яза торган машинада 35 милли тел өчен клавиатура проектын әзерли.

Ул 1948 елның 28 сентябрендә Мәскәүдә вафат булды.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №3 март 2022

Җуелмас хәзинә

«Фазыл чишмәсе» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Тәртип радиосы

Фазыл чишмәсе

(Сибгат Хәким сүзләре, татар халык көе)

Чылтырап аккан чишмәгә
Суга дип килгән идем;
Тиз генә әйләнеп өйгә
Кайтырмын дигән идем.

Өздереп нигә карадың,
Ник тоттың чиләгемнән?
Суларым түгел, ялкыным
Түгелде йөрәгемнән.

Кызарып янган шәфәкътан
Күзләрем алалмадым.
Тибрәнде телем, әйтергә
Сүзләрем табалмадым.

Йолдызлар чишмә суында
Ардылар инде йөзеп шул.
Әй, йөрмә, йөрмә, Фазыл, син
Бөтенләй өмет өзеп.

Чишмәгә төшкән сукмакның
Читләре үлән генә.
Вәгъдәм бар сиңа, белмәсен
Тик күрше-күлән генә.

«Фазыл чишмәсе» – күтәренке күңелле җыр. Көйне заманында – радиокомитетта эшләгән чагында баянчы Рокыя Ибраһимова Татарстанның Теләче районыннан отып кайта. 1946 елда (кайбер чыганакларда – 1940 елда) аңа әлеге районның Яңа Ил (Янил, Югары Мәтәскә) авылында булырга туры килә. Бу авылда Фазыл чишмәсе дигән чишмә булган.Чишмә буе авыл яшьләренең эштән соң кичен җыелып күңел ача торган урыны икән. Зиннәт (Зиннәтулла) исемле бер гармунчы егет бик күңелле, әмма Р.Ибраһимовага таныш булмаган яңа көй уйный. Яшьләр аны «Яңа көй» дип кенә йөртә. Фазыл чишмәсе янында җырланганга, Р.Ибраһимова аңа «Фазыл чишмәсе» дип исем куша.

Баянчы, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1982), Казан шәһәре тумасы (әтисе Габдерәхим, әнисе Сәхипҗамал чыгышлары белән Питрәч районының Шәле авылыннан) Рокыя Ибраһимова (20.01.1913-28.04.1998) һәм мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакиров (15.02.1935-16.01.2019)

Күпмедер вакыттан соң (1947 елда) шагыйрь Сибгат Хәким җырның яңа сүзләрен яза. Бераздан «Фазыл чишмәсе» җыры Зифа Басыйрова, Гөлсем Сөләйманова һәм Рокыя Ибраһимова (баян) башкаруында радиодан яңгырый башлый.

Җырның сүзләре ничек тууы турында С.Хәким болай дип яза: *«Җырның исеме үк ниндидер бер сюжетны сорап тора иде. Мин башта шул сюжетны таба алмый аптырадым... Авыл кызлары, авыл егетләре, чишмә буйлары искә төште. Мәхәббәт үзенең авылча тыйнаклыгы, оялчан сафлыгы белән күңелдә уянды. Ул минем шундый җыр язуымны теләде. Мин күңелем кушканча яздым. Башта ул ике генә куплет иде. Радио көнендә радиокомитет артистлары Мехчылар клубында чыгыш ясый. «Фазыл чишмәсе» дә җырлана. Җыр җиңел, күтәренке. Әмма тыңлаучыларга кыска тоела. Залда утырган бер апа торып баса да җырның дәвамын таләп итә, тагын җырлагыз, ди. Ә дәвамы юк. Җырны ахырынача җиткерергә халык миңа үзе, аның настроениесе булышты, димәк, җыр аның рухына туры килгән, рухына яткан. Минем өчен иң бәхетле җыр – шагыйрьдән халык арасына күчкән җыр».*

Җырны С.Хәким биш куплетлы итә. Әмма ахыр чиктә җырчылар җырның дүрт кенә куплетын башкара. Әүвәл: «Сибгат Хәким сүзләре, татар халык көе», – дип күрсәтелсә, соңрак чыккан татар җырлары җыентыкларында: «Мансур Мозаффаров көе (әлеге халык көен ул халык уен кораллары оркестры һәм солист өчен эшкәрткән), Сибгат Хәким сүзләре», – дип бирелә.

«Фазыл чишмәсе» җыры Зифа Басыйрова, Галия Гафиятуллина, Гөлсем Сөләйманова, Мөнирә Булатова, Энҗе Шәймурзина һ.б. репертуарында бар.

Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева) материалларына нигезләнеп, Ләбиб Лерон әзерләде. ■

Безнең мирас №3 март 2022

Артыш

Кипарисның туганы саналган артыш (можжевельник) төрки-татар дөньясында изгеләштерелгән агач исәпләнә. Аны җен һәм шайтаннан саклый дип санйылар. Шуңа күрә артышның ботакларын йортка керә торган ишек башларында күрергә мөмкин. Бала бишегенең сиртмәсен дә элек артыштан ясарга тырышканнар, бу инде яңа туган баланы җен алыштырмасын өчен эшләнелгән. Күз тиюдән сакласын дип, бала башлыгына да еш кына артыш ботагы теккәннәр – себер татарлары әле дә шулай эшли. Йокы тынычлыгы өчен дә артыш ылысларыннан ясалган мендәрдә йокларга кушалар, шулай иткәндә, албасты яисә шайтан йоклаучыны борчымый икән.

Язучы Ләбиб Лерон, «Татар ядкярләре» проекты кысаларында, артыш турында сөйли.
4 гыйнвар, 2022 ел. Ф.Җәүһәрова фотосы

Борынгы заманнарда авыл көтүен, тагы да элгәрерәк – кавем көтүен, кышлыктан соң беренче тапкыр көтүгә куганда артыш таягы белән куарга тырышканнар; көтүче таягы да артыштан булса, көтүлекләргә үләт керми, маллар исән-сау була дип исәпләгәннәр. Көтүче артыш таягын, беркемгә дә бирмичә, үзендә саклаган.

Артыш ботагы төтене белән мәет озаткан йортның эчен төсләтсәң – үлем, куркып, бу йорттан китә дигән мәҗүсилектән калган ышану да яшәп килә. Мал үләте булган елларда, артыш ботакларын яндырып, абзар-кураларны әле дә төсниләр, бу инде үзенә күрә үләтне куркыту да, дезинфекция чарасы да.

Артышның магик көче моның белән генә бетми әле. Берәр төрле гарасат башланса, өй һәм каралты-кура түбәләрен җил-давыл күтәреп атмасын өчен, борынгы бабаларыбыз ишек өстендәге артыш ботагын, «Бисмилла» әйтеп, ишегалдына тотып атканнар. Имеш, җил шунда ук тынып калачак, яисә хәрәкәт юнәлешен үзгәртәчәк. Артыш ботагын күп итеп йорт кырыйларына кыстырсаң, йортны яшен сукмый дигән ышану әле дә бар.

Себер татарларында теге яисә бу йортта янгын чыкса, артыш ботаклары белән: «Алас, Алас!» – дип, шул рәвештә Ут алласын туендырып, янгынны туктата торган гамәл хәзер дә сакланган. Бездәге «ылыс» сүзенең каян килеп чыгуын инде чамалыйсыз булыр...

Мәшһүребез **К.Насыйри** үзенең **«Хәвасе нәбатәте дәваәять», ягъни Тыйбта мөстәгъмәл нәбатат вә үләннәрнең хасыятене бәян кылур»** дигән китабында (1885) артышның шифасы турында болай дип язган: *«Артышның үзлеге – тирләтүче һәм сидерткеч. Ягъни тирләтер, сидекне чыгартыр һәм йөртер, сидек куыгын пакь кылыр,*

сидек куґы авыруларын бетерер һәм исиска (сары су) авыруына шифа бирер. Тагы сидек юлындагы һәм сидек куыгындагы ташларны ватар һәм көнаралаш килгән бизгәккә файдалы, җенси дәрткә куәт китерер. Кулланылышы: 7 мыскал артыш ботагын яки энәсен бер кадак (409,512 граммга тигез авырлык күлчәме) суда кайнатып яки чәй кебек пешереп, көн дә ике яки өч мәртәбә яртышар чынаяк эчәләр. Артыш суы белән авыз чайкасаң, теш ýртларын тазартыр. Артыш җиләген сусын мае (аир) белән тимер савытта кайнатып, колакка тамызсаң, саңгыраулыкны бетерер».

Казак артышы

Артыш җиләгенә гарәпчә *сөммәр-әл-гаргар* диләр.

Игътибарны янә **К.Насыйри** язмасына юнәлтик: «*...артыш агачының икенче төре бардыр, сәмихле артыш яки ладан артыш (можжевельник ладановый) дип атала. Ладан дигән хуш исле сагыз шушы артыш агачыннан әзерләнә. Артыш агачының бу төре безнең якта юк, әмма Испаниядә, Италиядә һәм башка Кавказ якларында, Әстерхан диңгезе буенда көнбатышка таба урманнарда үсә, даруга кулланылмый.*

Артышның тагы бер төре казак артышы (казацкий можжевельник) аталыр, гадәти артышка охшаган. Энәле агачлар шикелле һәрвакыт яшел, буе 5 аршын кадәр була, әмма гадәти артыш кебек каты энәле түгел. Моның энәсе йомшак, чәнечкеле түгел, энәләре агачына ятып үсә. Апрель аенда чәчәк ата. Дару өчен ботак башларын кулланалар. Әмма исе авыр, тәме әче. Бу артышның үзлекләре: куәт бирүче, уятучы, кыздыручы һәм эс-селек бирүчедер. Эчтәге кортларны куар, тыштагы җәрәхәтләрне әрчер, сидекне һәм күремне йөртер. Тәндәге бозык каннарны һәм сары суларны саф кылыр, ләкин куллана белеп кулланырга кирәк».

Сәхифә «Татар халкы традицияләрен саклау һәм үстерү «Татар ядкярләре» шәхси учреждениесе (җитәкчесе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе ***Фәнзилә Җәүһәрова****) белән берлектә әзерләнде.* ■

Артыш турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Көлке куа килә...

Балалар язган иншалардан

Алмачуар кешнәп көлеп җибәрде.

***

Безнең авылда да Шүрәле бар.
Тик ул Хәсән исемле.

***

Телсез Герасим беркайчан да ялган сүз сөйләмәде.

***

«Туп-туры аэропортка!» – дип кычкырды Хлестаков.

***

Чацкийның әтисе әле кечкенә чакта ук үлгән.

***

Капка төбенә ике ат килеп туктады. Тарас Бульбаның ике улы иде бу.

***

Ростовларның өч кызы булган: Наташа, Соня һәм Николай.

***

Тарас атка утыргач, ат көлеп куйды.

***

Татьянаның күңеле мәхәббәт белән тулы иде. Бу мәхәббәтне ул кемгә багышларга да белмәде...

***

Пьер Безухов мәхәббәте уңышлы булмады – ул өйләнде.

Т.Миңнуллин.
Илдус Әҗемов шаржы

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Түрәләр файдасына

(Робагый)

Театрга түрә халкы йөрсен дисәң,
Сәхнәләрдә ни булганын күрсен дисәң,
Артистлардан футбол яки хоккей уйнат,
Түрәләрнең файдасына булсын исәп.

Шамил Маннапов (1938-2012)

Авыл саен Рәхимә

(Мәзәкият)

Заманында шагыйрь Мәхмүт Хөсәен, язучы һәм нәфис сүз остасы Камил Кәримов һәм җырчы, композитор Риф Гатауллин Югары Ослан районында кичәләр уздырып йөри.

Мәхмүт абыйның халык игътибарын тиз генә яулап алуда үз алымы бар. Ул һәр авылда: «Сездә Рәхимә исемле хатын-кыз бармы? Булса, безнең кичәгә килсен. Мин аңа багышланган поэмамны укыйм...» – ди. Һәм укый да. Дөресрәге, яттан сөйли. Халык әле Мәхмүт абыйга, әле алгы рәттә утыручы Рәхимәгә карый. Соңыннан тамашачылар шаулатып кул чаба, ә Рәхимә, алсуланган йөзе белән балкып, Мәхмүт абыйны коча-коча, аңа рәхмәт әйтә.

Ләкин Яңа Болгар авылында әз генә аңлашылмаучылык килеп чыга. Анда да Мәхмүт абыйның соравына: «Бар бездә андый кызый. Иллә дә матур инде үзе!» – диләр. Шагыйрь бу кичәдә дә Рәхимәнең гүзәллеге, мәхәббәт ялкынында януы, тырыш хезмәте турындагы поэмасын ялкынланып сөйли. Үзе, залны күздән кичереп: «Бу чибәркәйләрнең кайсы Рәхимә икән соң, чукынмыш?» – дип уйлап алырга да өлгерә. Чыгышы тәмамлануга, сәхнәгә чәчәк бәйләме тоткан нәни генә кызчык йөгереп менә.

– Рәхмәт, Мәхмүт абый! Мин, зур үскәч, Сезнең шигырегездәге апа кебек булырмын, – ди.

– Синең исемең ничек соң? – дип сорый Мәхмүт Хөсәен.

– Рәхимә... Мин өченче сыйныфта укыйм... – ди кызый.

Бу юлы Мәхмүт абыйны башка авыллардагыга караганда да көчлерәк алкышлыйлар.

Илдар Юзеев (1933-2004)

Бер җырчыга

Чын җырчыга караганда
Сәхнәгә ул еш чыга,
Табигатьтән бирелмәгән
Иләмсез тавыш чыга.
Кайчагында бераз гына
Охшап куя җырчыга.
Әйе шул, чынлап еласа,
Сукыр күздән яшь чыга.

1995

Мөхәммәт Мәһдиев (1929-1995)

Өчәү булса – дуслар

(Күзәтүләрдән)

Бер хатын-кыз – бары тик хатын-кыз гына. Икәү булсалар – дуслар яки дошманнар. Өчәү булса – дуслар. Өчтән артып китсә – хатын-кызлыктан чыгып, коллективлыкка әйләнәләр. Бу коллектив эчендә вак-төяк группачыклар, ярым-йорты, ике якка да карый торган группачыклар була. Әмма инде болар – көч. Хатын-кыз гына түгел.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■



БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БАЛАЧАКТАН

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Нәүрүз бәйрәме

Элгәре заманнарда бабаларыбыз, бабаларыбызның бабалары Яңа ел бәйрәмен 22 мартта уздырганнар һәм аны **Нәүрүз бәйрәме** дип атаганнар. Ошбу көнне малайлар вә кызлар, һәр өйгә кереп, хуҗаларны бәйрәм белән котлаганнар, аларга такмак-такмазалар әйткәннәр:

Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде,
Былбылдан аваз килде –
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Абзый, эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
Күңелләрең хуш булсын –
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Нәүрүз хакы биш алтын,
Бирсәң, ярар ике алтын,
Карама ялтын-йолтын –
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Сажидә Сөләйманова (1926-1980)

Кем уяткан Ләйләне?

Иртүк торып битен юган,
Кем уяткан Ләйләне?
Уятмаган, үзе торган –
Бүген әни бәйрәме.

Пәрдәләрне ачып куйды,
Көн кояшлы, әй, ямьле!
Якты булсын, балкып торсын –
Бүген әни бәйрәме.

Өстәл өстен кат-кат сөртте,
Җәйде ап-ак җәймәне.
Чиста булсын, пөхтә булсын –
Бүген әни бәйрәме.

Кумәкләшеп без дә, дуслар,
Җырлап алыйк, әйдәле:
«Котлы булсын! Гөрләп торсын
Әниләрнең бәйрәме!»

Әминә Бикчәнтәева (1913-1986)

Март аенда

Җылы шарфка урады
Әнисе Гөлсинәне:
– Туңа күрмә, тышта салкын,
Кечкенә бит син әле.

– Күзем туңмый бит, әнием,
Борыным бераз туңса да.
Сине күргәч, җылынырмын,
Бик-бик салкын булса да.

Әхәт Гаффар (1949-2021)

Таган

Яшәгән, ди, бер Таган. Сәгатьләр буе, көннәр буе, атналар буе, айлар буе, еллар буе балаларны атындыра-атындыра ул бик арып беткән, ди.

«Сәгатьләр буе, көннәр буе, атналар буе, айлар буе, еллар буе балаларны атындыра-атындыра мин бик арыдым, минем ял да итәсем килә», – дигән Таган.

Шуннан балаларны атындырудан туктаган ул. Сәгатьләр буе, көннәр буе, атналар буе, айлар буе, еллар буе тик кенә тора икән. Шулай тора торгач, күгәргән. Хәзер, җил искән саен, балаларны сагынып, чыгыр-чыгыр-чыгыр килә-килә елый да елый, ди, Таган.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ФЕВРАЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 1 февральдә «Казан утлары» журналы редакциясе Татарстан Язучылар берлеге белән бергә уздырган ябык әдәби конкурсның роман жанры номинациясе җиңүчеләре билгеле булды. Беренче урын – «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар» романы өчен Зөлфәт Хәкимгә, икенче урын – «Урда ханы Үзбәк» романы авторы Фирдүс Гыймалетдиновка, өченче урын исә «Фәхрине үтереп ташладылар» романы өчен Равил Сабырга бирелде.

● 2 февральдә Казандагы «ИТ-Парк»та «Татмедиа»ның киңәйтелгән утырышы булды. Анда ТР Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров катнашты һәм чыгыш ясады.



● 3 февральдә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон Питрәч муниципаль районы башлыгы Илһам Кашапов белән очрашты.



● 5 февральдә танылган журналист, мөгаллим, күпләрнең остазы, Татарстанның Биектау районындагы Садилово авылы тумасы Константин Николаевич Куранов вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде Казанның Арча зиратында җирләнде.

● 7 февральдә «Татмедиа»да, каләм әһелләре һәм баш мөхәррирләр катнашында, Татарстан Язучылар берлегеннән Г.Тукай премиясенә кандидат итеп күрсәтелгән шагыйрә Флера Гыйззәтуллина һәм балалар язучысы Ләбиб Лерон иҗатлары тикшерелде.

● 8 февральдә «Татмедиа» бинасында «Татмедиа гаиләләре» дип исемләнгән

фотокүргәзмә (фотолар авторы – Анна Арахамия) эшли башлады.

● 9 февральдә Казанның Татар китабы йортында (Островский урамы, 15) «Идел» журналы һәм ТР Язучылар берлеге каршында оештырылган Татарстан Әдәби суды (казый – Р.Батулла, гаепләүчеләр – Р.Рахман, Л.Лерон, яклаучылар – Л.Әбүдәрова, Р.Латыйпов) яшь иҗатчылар – Айгөл Абдрахманова, Алинә Хәбибуллина, Ләйлә Фаяз һәм Эльвина Миңнуллинаның каһвә темасына язылган әсәрләрен тикшерде.



● 15 февральдә күренекле рәссам, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, ТР Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исемендәге премиясе лауреаты Зөфәр Гыймаев вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде Курган зиратында җирләнде.



● 15 февральдә Казанда бер төркем зыялылар, каһарман шагыйребез М.Җәлилне искә алу чарасында катнашып, аның һәйкәленә чәчәкләр салды.

● 16 февральдә балалар язучысы, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон Казандагы 37 нче гимназиядә укучылар белән очрашты.

● 16 февральдә Казанның Г.Тукай музеенда, галимнәр һәм каләм әһелләре катнашында, бөек шагыйрьнең үзе төзеп калдырган һәм 1914 елда басылган «Мәҗмугаи асаре» китабының кириллицага әйләндерелгән яңа басмасын (төзүчесе, кереш сүз авторы, аңлатмалар язучысы – Г.Төхвәтова) тәкъдим итү чарасы булып узды.

● 18 февральдә Түбән Каманың Г.Тукай исемендәге Үзәк китапханәсендә һәм Т.Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театрында Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Ркаил Зәйдуллага 60 яшь тулуга багышланган очрашу һәм кичә үтте. Әлеге чараларда әдипнең каләмдәшләре, әдәбият сөючеләр катнашты.

● 21 февральдә Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында, Халыкара туган тел көне кысаларында, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Л.Лерон студентлар белән очрашты. ■

МИРАСВОРД

- Язучы Тәүфикъ ...
- ...-мачта
- ... Арагон
- Болгар ханы Алмышның әтисе
- Вертолет маркасы
- Бәрү, сугу
- Сөт анасы
- Иван Крылов повесте
- Фәүзия Бәйрәмова повесте
- «... төбендә кояш» (Разим Вәлиуллин)
- Әтнә районындагы авыл
- Бал, кымыз әчетә торган кечкенә мичкә (диал.)
- Ашлык җилгәргәндә очкан чүп, кибәк, башак
- Борынгы сугыш коралы
- Рус рәссамы, Айвазовскийның укытучысы
- Тышкы сакчы (бор.)
- Гарәп язуында киләсе сузык авазның булмавын белдерә торган билге
- ... ат арымас
- Дөрес, хак
- Борынгы Грециядә барлыкка килгән кыллы уен коралы
- XIX гасыр француз язучысы
- Башкорт халык җыры
- Рафаил Төхфәтуллин повесте
- «...-егетләр» (Туфан Миңнуллин)
- Милек, байлык
- Кисәкчә
- ... Ганди
- Туфан, Сарьян
- Югары дәрәҗәле мөселман рухание
- Габәши, Шәмси
- ... Мирзаянов
- ... Минһаҗ (татар галиме)
- Монгол кылычы
- Бернигә дә бәйле булмаган, абсолют (иск.)
- Шекспир короле
- Аркылы борыс, киртә
- «...-дза-дза!» фильмы
- Йөк автомобиле
- Гаяз Исхакый повесте
- Гарәп хәрефе



2 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: кушу, ышна, тога, атчы, Якупов, дәхи, Кыямов, болытлы, Вера, ыгы, рун, көбә, әрем, Алиш, химаяче, фырт, мәхшәр, баск, юа, почык, ясак, «Ватан».
Өстән аска: ялбыр, бояр, го, «Зифа», утлык, мыскал, «Китап», Арк, октябрят, шыгавыл, ушат, Зыя, Рем, Әюпов, Давыдов, Ра, хао, әверелеш, Руми, ыра, ишан, ширек.

Рәис Габдулла төзеде.

Безнең мирас №3 март 2022

«Безнең мирас»
елъязмасы / март

«Меңьеллык паркы»нда Кол Галигә куелган һәйкәл. Казан.
Фото rasfokus.ru сайтыннан алынды.

790 ел элек (1232)

Кол Гали «Кыйссаи Йосыф» әсәрен язып тәмамлый.

675 ел элек (1347)

Венеция сенаты илчеләре Алтын Урдага килергә рөхсәт ала. Гөлстан каласында үзара солых төзелә. Үзбәк хан заманындагы тәртипләр торгызыла: ике як та бер-берсенең тауарларына 5 проценттан артык салым түләтмәскә дигән карар кыла. Татар дәүләтеннән чыккан тауарлардан тамга (таможня) салымын тотмаска килешенә.

115 ел элек (1907)

Ташкент шәһәрендә «Шөһрәт» дип аталган газета чыга башлый. Мөхәррире – Габдулла Уланов, төп авторы – Бозаулыктан татар мөгаллиме Әхмәтҗан Биктимеров. Газета 1908 елның февралендә, Төркестан губернаторы әмере белән, чыгудан туктатыла.

95 ел элек (1927)

19-20 нче мартта Казанда яңалифчеләрнең беренче җыены оештырыла. «Яңалиф» җәмгыятенең рәисе итеп Фатих Сәйфи Казанлы сайлана.

90 ел элек (1932)

1 мартта Ленинградта яңа оешкан Татар дәүләт театры үзенең эшен Һади Такташның «Камил» әсәрен сәхнәгә кую белән башлый.

ТАПП секретарияты утырышында Һади Такташның әдәби мирасын һәм архивын барлау мәсьәләсе тикшерелә.

80 ел элек (1942)

30 мартта шагыйрь Мифтах Вәдүт (1915-1942) гитлерчыларга каршы сугышта һәлак була.

«Совет әдәбияты» журналының март ае санында Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повесте басылып чыга.

60 ел элек (1962)

18 мартта язучы Габдрахман Әпсәләмов СССР Верховный Советына депутат итеп сайлана.

20 ел элек (2002)

15 мартта милли җәмәгатьчелек Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевне (1928-2002) соңгы юлга озата.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Содержание. Март 2022

И останется в мире слово моё...: Г.Ибрагимов.

Историческое наследие: «Почему татары так любят арбуз?»; «Киевская Русь или татаро-тюркский Киевский каганат?» А.Чанышев; «Ахмед бай». Р.Фахруддин; «Данис Шакиров: «Предпринимательство – основа и будущее татарских деревень»; «Рустам Шафигуллин: «Бурек (шапка) должна показать татарскую роскошь!»; «Мухамматзян Галиев и единственная татарская фирма по производству ичигей». Р.Шарафиева и Л.Губайдуллин; «Нагорная сторона». В.Данилов.

Литературное наследие: «Мауля Колый: история изучения и взгляды о его творчестве». Х.Миннегулов.

Татарский мир: «Ильгам Кашапов: «Сельский туризм сохранит нашу историю»; «Нумизматические памятники Пестречинского района». А.Бугарчев, О.Степанов; «Легендарный сын татарского народа». Р.Сагди.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Ислам. Религиозный словарь»; «Хадисы пророка Мухаммада (с.г.в.)». А.Рахими; «Уроки религии». С.Бикбулат.

В глубинах памяти: «Память о благотворителе Эдуард хаджи Ганиеве»; «Страна Айдар» или Татарский Жан Габен». Л.Лерон; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Природное наследие: «Можжевельник».

Алхәбәр:

Дилүс Ильясов әнисе Гөлсем, хатыны Флера Хәмитова, кызлары Айгөл һәм Чулпан белән. 1973 ел
(«Дилүс Ильясов». Әхтәм Зарипов)

Артист Айдар Хафизов — фотоларда

ТАССРның һәм РСФСРның халык артисты Ринат Таҗетдинов белән бергә бер сәхнәдә уйнаган чак

Айдар Хафизов олы кызы Ләйсән белән

А.Хафизов – Якуб Акчурин ролендә («Без китәбез, сез каласыз», Т.Миңнуллин)



Никах көненнән бер хатирә. Утырганнар (сулдан уңга): Фәридә Ибраһимова-Хафизова, Фирдәвес Хәйруллина; басканнар: Айдар Хафизов, Шамил Закиров. 1968 ел

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066
г. Казань, ул. Декабристов, 2.
ГРН 1071690057834

16+
Реклама